1895-нче елда 40 яшьлек Морад хәзрәт үзенең якын дусты, сәүдәгәр Габдрахман Җәдиднең сеңлесе – Тәтеш өязе Шәпбаш авылы кызы – Әсма Шаһмөхәммәд белән никахлаша. Бу никахтан тугыз бала туа, әмма ләкин шуларның дүртесе генә исән кала. Әлбәттә, чит-ят җирләрдә гыйлем иясенә тормышны алып бару җиңел булмый. Морад Рәмзигә ишле гаиләсен матди яктан тәэмин итүгә өстәмә чыганаклар эзләргә туры килә һәм ул байлар файдасына бәдәл хаҗлары кылырга мәҗбүр була. Ошбу кәсеп турында хәбәрләр Казанга да килеп ирешә дин әһелләренә, берьяклы тискәре караштa торучылар әлеге хәлне көлкеле, кызыклы «тема» дип тапканнардыр, мөгаен. Бу шаукымга Морад хәзрәтнең шәхси тормышыннан хәбәрдар булмаган һәм мәсьәләгә берьяклы караштa торган Габдулла Тукай да кушылган. «Авыл җырлары» дигән шәлкемдә аның Морад Рәмзигә карата чәнечкеле шигъри юллары очрый. «Ялт-йолт» мәҗәлләсенең 25-нче санында мондый ике юллыклар да пәйда була:

«Ике туры ат җиктердем, берсен сыңар тәртәгә,
Баш хәерче Мoратлары чыкмый ята Мәккәдә».

«Хәтфә калфак – киштәдә, эшләнүе бистәдә;
Морат кебек теләнчене күралмассың төштә дә».

Морад хәзрәтнең ни дәрәҗәдә авыр шартларда яшәвен күргәч, хаҗга килгән сәүдәгәр Йосыф бай Дибирдиев исә аңа Мәккәдә йорт сатып алып бүләк итә.

Морад хәзрәт Рәмзи туган иле белән араларны өзми, хаҗга килгән ватандашлары белән аралаша, ялгызы да, гаиләсе белән дә Русиягә кайтып-китеп йөри. Мәсәлән, ул 1896, 1902, 1904, 1907, 1909, 1914-нче елларда туган якларына кайтып, байтак вакытлар торып китә. Ошбу сәяхәтләре вакытында ул Русия, Төркестан буйлап сәфәр кыла.

1914-нче елның язында Морад хәзрәт гаиләсе белән соңгы тапкыр туган иленә кайта. Беренче империалистик сугыш башлануы аркасында алар кышны монда уздырырга мәҗбүр була. Хәзрәт, олы улын ияртеп, Төркестан якларын урап кайта. Русиянең Төркия белән араларында дипломатик мөнәсәбәтләр катлаулана төшүгә–ә Морад Рәмзи төрек ватандашы булуы сәбәпле–ялган паспорт белән йөрергә мәҗбүр була. Янә бер елдан ул улы Фәһми белән Иран аша Төркиягә качып чыгарга ниятли, әмма жандармнар кулына эләгә. Өч ай дәвамында Дүрткүл шәһәре төрмәсендә утырганнан соң, аны Себергә каторгага җибәрергә торган җиреннән якын дуслары, күренекле затлар (шул җөмләдән Муса Бигиев) кайгыртуы һәм булышлыгы белән азат итәләр һәм Оренбург губернасына гаиләсе янына полиция күзәтүенә җибәрәләр.

1908–1915-нче елларда Сарытау мәхкәмә пулатының карары белән, Морад Рәмзи өстендәге бөтен гаепләүләр юкка чыгарыла һәм галим Романовлар нәселенең олуг юбилее–300 еллыгы уңаеннан, амнистиягә эләгә. Февраль революциясенән соң Морад хәзрәт, Оренбург мөселман өммәте делегаты буларак, Казанда 1917-нче елның июлендә Бөтенрусия мөселман дин әһелләре съездында катнаша, шушы дәрәҗәле җыенның президиумына сайлана, ялкынланып, дулкынланып чыгышлар ясый.

Әмма Русиядәге вазгыять торган саен катлаулана бара, ватандашлар сугышы өермәсе гавамны чорнап ала һәм гыйфрит кеби бер гөнаһсыз корбаннар даулый. Морад бәй балаларын һәм гаиләсен саклап калу ниятеннән, вакыйгаларның кая таба барганын сизеп, гаиләсе белән янә Гарәбстанга китәргә карар кыла. Әмма бу вакытта Казанга фетнә күтәргән чех гаскәре бәреп керә. Хәзрәт Мәскәүдә төрек консулында паспортына визасын озайту турында билге салырга өлгерми кала. Авылдан-авылга күчә-күчә, урау юллар белән ул янә Оренбург ягындагы бер авылга кайтып, ике-өч ел мәдрәсәдә укытып йөрергә мәҗбүр була. 1919-нчы елның язында галим Уфага юнәлә, аннан Кызыл Яр *(Петропавловск),* Сими *(Җидепулат)* калалары аша Шәрык Төркестанындагы Чүгүчәк каласына килеп төшә. Биредәге татарлар, мөселман өммәте аны, имам һәм мөдәррис вазифаларын башкарырга үтенеп, төпләнеп

калырга өнди. Хәзрәт озаклап кыстатып тормастан, гаиләсе белән биредә тамыр җибәрергә карар кыла. Аңа яшәү өчен шартлар да тудырыла, иганәчеләр ярдәме белән яхшы гына йорт сатып алына. М. Рәмзи каланың Базар мәчете каршысында мәдрәсә оештырып, сабак бирә башлый. Мәдрәсә тиз арада халык арасында танылып китә. Дәресләргә мәхәллә халкыннан тыш каладагы байтак имамнар да килеп белем эсти. Морад хәзрәтнең Чүгүчәктәге беренче хөтбәсе дә саф татарча, җирле төрки халыкларга аңлаешлы итеп укыла. Имам биредәге төрки халыклардан казакъ, кыргыз, уйгырлардан кала, дин-Исламны тотучы кытай кавеме – дүнгәннәр арасында да зур абруй казана. Аңа кадәр ярым буш торган Базар мәчете гөрләтеп эшли башлый, җомга намазларында Аллаһ йорты гына түгел, хәтта аның ихатасы, тирә-юне мөселманнар белән тулы була. Шуңа да бөтен кеше имамның вәгазен ишетсен өчен, кышкы салкыннарда да мәчетнең ишеге ачык була. Халык арасында Морад Рәмзинең дәрәҗәсе торган саен үсә бара. Әлбәттә, җирле хакимият моңа битараф кала алмый һәм Чүгүчәк, Шәркый Төркестан идарәчеләре дә бу хәлләргә чик куярга карар кыла. Шәһәр башлыгы хәзрәткә төрек ватандашларына Кытайда яшәү хокукы булмавы турында хәбәр итә һәм тиз арада биредән китәргә тәкъдим ясый. Моны белеп алганнан соң, Чүгүчәк, Гөлҗа, Өремче һәм Мәгътабарани калалары халкы Морад хәзрәтне Кытайда калдыруны үтенеп мөрәҗәгать белән чыга. Кала хакимияте, хәзрәтнең документларын кайтарып бирүне кирәк санамастан, аңа Кытай ватандашлыгын кабул итү тәкъдимен җиткерә, әмма бер үк вакытта аңа илнең башка өлкәләренә чыгып, сәяхәт итүне тыя. Бу хәлләргә Морад Рәмзи Мәскәүдәге төрек илчелеге аша Әнкарага протест хаты юллый. Әмма Әнкарадан Нанкинга җибәрелгән җавапның нәтиҗәсе көтелгәннең нәкъ киресен бирә. Бу хатның эчтәлеге турында белеп алган җирле идарә галимгә карата каныгуны отыры көчәйтә. Хәзрәт теләр-теләмәс кенә Кытай ватандашлыгын алырга мәҗбүр була, шуннан соң аңа басым күпмедер дәрәҗәдә кими төшә.

Хәзрәтнең Төркестанда яшәгән чорындагы фәнни-иҗади эшчәнлеге турында мәгълүматлар күп түгел. Шулай да М. Рәмзинең җирле идарә тәкъдиме белән Коръән Шәрифне төркигә тәфсир кылуы билгеле. Ул үзе дә бу эшне хуп күреп, бөтен гыйлемен туплап башкарып чыга. Моннан тыш аның нәкъ менә Чүгүчәктә ике томлы «Талфик әл-әхбәр вә талких әл-әсәр фи вакаи Казан вә Болгар вә мүлүк ат-татар» хезмәтен төркигә тәрҗемә итүе фараз кылына. Кайбер галимнәр шушы әсәрнең татар теленә күчерелүен дә әйтәләр[1].

[1] Кызганыч, Коръән тәфсире дә, ике томлык хезмәтенең төрки телдәге версиясе дә әлегә табылмады (Ред.).

Шәркый Төркестанда милли-азатлык көрәше көчәйгән елларда Морад хәзрәт җирле төрки халыкларны һәм дүнгәннәрне бердәм көч булып тупланып көрәшергә, җирле администрация вәкилләре каршына уртак таләпләр куярга чакыра. 1933-нче елның октябрендә, Чүгүчәккә дүнгәннәр гаскәре һөҗүм иткән куркыныч мизгелләрдә, ул дин-кардәшләрен гыйсьянчылар белән бердәм булырга, аларга теләктәшлек кылырга өндәп чыгыш ясый һәм бу эштә максатына ирешә – мөселманнар дүнгәннәргә каршылык күрсәтми һәм, нәтиҗәдә, кан коелмый. Җирле татар байлары химаясе белән баш күтәрүчеләр тиешле матди ярдәм ала, ләкин берничә көннән Шенҗаң җирле мохтарият үзәге булган Өремче каласыннан кытайларга хезмәт итүче акгвардиячеләр гаскәре Чүгүчәкне басып ала һәм фетнәне күп кенә корбаннар бәрабәренә бастыра. Дүнгәннәрнең һәм мөселманнарның азатлык хәрәкәтенә чик куела. Җәмигъ мәчетенең ахуны Хәсән хәзрәт, татар байлары һәм аларның гаилә әгъзалары җәзалап үтерелә, аларның хосусый милке талана. Чүгүчәкнең дүрт мохтары *(сайлап куелган вәкиле),* татар мәхәлләләре имамнарыннан Хафиз Гәрәй, Морад Рәмзи һәм аның кодасы кулга алынып, үлемгә хөкем ителәләр. Әлеге карар игълан ителүгә, җирле халык дәррәү күтәрелеп протест белдерә, җәзалау гаскәре өркеп калып, тоткыннарны азат итәргә мәҗбүр була. Шушы вакыйгалардан соң Морад хәзрәт инде озак яшәми – вафат була.

***М. Рәмзи һәм Шиһабетдин хәзрәт***

Галим-энциклопедист, мәгърифәтче, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең (1818–1889) йөзьеллык юбилее алдыннан 1915-нче елда Казанда «Мәгариф» матбагасында нәшер ителгән 640 битле китап бар. Ошбу мәҗмугада галимнең тормыш юлы җентекләп тасвирланган, аның гыйльми хезмәтләре урын алган һәм Ш. Мәрҗани хакында мәкалә-хатирәләр бирелә. Аларның авторлары арасында Г. Баруди, Р. Фәхреддин, Й. Акчура, Ә. Максуди, Һ. Атласи, Ә. Вәлиди, Х. Габәшиләр белән беррәттән Морад Рәмзи мәкаләсе дә бар. Мәкаләнең күләме нибары ике бит ярым. Бу язмада Морад хәзрәт милләтебез хакына иҗтиһад кылган затларны хөрмәт белән яд итү турында искәртә. Бу кешеләрне милли горурлыгыбыз, дип атый. Әлегә кадәр мондый чараларның җитмәвенә, аларга багышлап хәйрия оешмалары төзелмәвенә, хезмәтләрен олылауга, нәшер итүгә әһәмият бирмәүгә игътибар итә. Боларның сәбәпләрен дә ача – «милли горурлыгыбыз кулыбыздан читләр кулына күчүенә» ризасызлык белдерә. Автор болай ди: «Һич булмаса мондый атаклы кешеләрнең тәрҗемәи хәлләрен язып, гомерләре буе кылган бу кадәр фидакярлекләре түгел, башка әхвәлләре, бәлки, үзләре юл туфрагына күмелеп, гофран булуларында исемнәре белән, үзләре белән бәрабәр туфракка күмелеп, онытылып киткән исемнәре белән безгә мә-

гълүм түгелдер. Бу исә никадәр рәхмәтсезлек вә вәгъдәсезлек, вә намуссызлык». Әлеге сүзләрдә Морад хәзрәт әүлиядай үзенә карата да нәкъ шундый ук мөнәсәбәт булуын алдан күргән, диярсең.

Бөек галимнең күпкырлы эшчәнлеген бәяләп, Морад Рәмзи болай ди: «Заманның олы галиме вә тарихның сирәк шәхесе, әйберләрнең асылын үзгәрешсез, замана вакыйгаларын ничек ирешкән, шулай сөйләүче, һәрнәрсәгә хакыйкать белән караучы вә һәрнәрсәне дөрес үлчәү белән үлчәүче, милләтне сөюче вә аларның тәрәккыятен теләүче, аларда булган тарлыкларны бетерүче вә, элек яшәгән галимнәрнең әсәрләрен мәйданга чыгарып, аны тергезү вә милләтебезне аларның яхшы мәсләкләреннән барырга кызыктыру вә өндәү бабында чиксез гайрәт күрсәтүче, бу бабта төрле фидакярлек күрсәтүче, кыенлыкларны чишү, вә гыйльми мәгълүматларны тикшерү бабында йәкәнә-и заман вә игътикад мәсьәләләрендә төпченү вә фикһ ысуллары турында бөтен заманнарда да бердәнбер булган вә һәр заманнарда да кабатланмас шәхес, олы галим тикшеренүче, вә төпченеп өйрәнүче галим булган зат, фазыйләтле зат иде». Нинди сокланулы вә искиткеч зур хөрмәт, югары бәя!

Шиһаб хәзрәт, – дип дәвам итә мәкалә авторы, – гаять күп әһәмиятле вә бәһаләп бетергесез әсәрләр калдырды һәм шуңа да «икенче мәгънәви тормыш белән» гел безнең арабызда, бертигез яшидер сыман». Үзенең язмасын Морад хәзрәт гарәп мәкале белән тәмамлый: *«Иннә әсәранә тәдүллү галәйнә Фәнзуру бәгъдәнә иләл-әсәр»*. Ягъни, «Хакыйкатьтә, әсәрләребез безнең турыда сөйли. Шулай булгач, бездән соң әсәрләребезгә карагыз». Бу сүзләрдә дә ниндидер хикмәт, тирән мәгънә яшеренгән кебек...

Әйе, Шиһаб хәзрәт аның өчен бөек галим, олуг шәхес вә хөрмәт иясе булуында шик юк! Чөнки, иң әүвәл, үсмерне 1873-нче елның язында туган авылыннан нәкъ менә «Мәрҗания» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Шиһабетдин-остазның үзенә хат белән мөрәҗәгать итүче дә, аның элеккеге шәкерте Хәсәнетдин – үсмернең анасы ягыннан абыйсы була, дидек. Әлбәттә инде, яшь шәкерт галимнең сабакларын йотлыгып тыңлаган, аның белән аралашмый калмаган. Икенчедән, аны мәшһүр тарихчылар рәтенә куйган ике томлы әсәре – «Талфик әл-әхбәр вә талких әл-әсәр фи вакаигъ Казан вә Болгар вә мүлүк ат-татар» *(Казанда, Болгарда булган вакыйгаларга һәм татар патшаларына бәйле хәбәрләр вә әсәрләр җыелмасы)*, Ш. Мәрҗанинең «Мөстафадел әхбары » белән аваздаш, аңа ияреп, аны тулыландырып торучы, тарих фәнен, бигрәк тә милләтебезгә баглы сәхифәләрне җанландыручы хезмәт. Шуны да онытмаска кирәк, ул – татар халкының тарихын яктыртучы, халкыбызны гарәп дөньясында танытучы мөкәммәл гарәп телендә язылып нәшер ителгән бердәнбер китап.

һәм, ниһаять, алдарак телгә алынган Мәрҗанинең йөзьеллыгына багышланган мәҗмугадагы кыска гына мәкалә әлеге тыгыз бергәлекне дәлилли бугай. Ләкин биредә күпмедер гыйльми карашлардагы төрлелек, үзара бәхәсле, четерекле урыннар турында да искәртеп, ачыклап китү урынлы булыр, дип саныйбыз.

Билгеле булганча, Морад Рәмзи иҗат иткән һәм 1908-нче елда, күренекле дин әһеле, атаклы Зәйнулла ишан Рәсүлинең матди ярдәме белән басылган китап, патша цензурасы тарафыннан тыела һәм конфискацияләнә. Әсәрнең күпмедер өлешен качырып саклап калуда да Зәйнулла ишанның өлеше бар. Автор исә чит илгә чыгып, кулга алынудан котыла. Галимне Русия тарихын бозып күрсәтүдә гаеплиләр. Баш цензор Казан император университетының төрек-татар телләре кафедрасы экстраординар профессоры, милләте буенча хакас (паспортында – «татар» дип күрсәтелгән була) Николай Федорович Катанов (1862–1922) тарихчыны тенденциозлыкта гаепли. Китапны укып чыккач ул: «Пристрастные и лживые суждения Рамзия», «книга крайне тенденциозная и лишена научного значения», дигән резолюция сала. Хәтта алдынгы карашлы татар галиме Газиз Гобәйдуллин да М. Рәмзине системасызлыкта, фанатизмда гаепләп чыга. Хезмәтнең компилятив характерда *(ягъни чыганакка әһәмият бирмәстән, башкаларның эзләнүләрен файдалану)* язылганлыгын, шул уңайдан Ш. Мәрҗанине кабатлавын ассызыклап күрсәтәләр тәнкыйтьчеләр.

Язучы һәм галим Адлер Тимергалинның «Миллият энциклопедиясе»ндә, Морад Рәмзи Мәрҗанигә тискәре караштa булган, дигән фикер дә чагылып китә [Тимергалин: 2016. Т. 2. ББ. 430–431]. Әлбәттә, югарыда тарихчы тарафыннан язылганнарны укыганнан соң, бу фикер белән килешүе кыен. Шиһабетдин хәзрәт беренче булып Казан мөселманнары – татарларның этрафлы, логик яктан мәгънәле, дәлилләргә таянып язылган тарихын иҗат иткән булса, Морад әфәнде нәкъ шул ук теманы төрки кавемнәр яссылыгына күтәрә, төрки дөньясының тарихын иҗат итә. Һәм иң мөһиме, ул Мәрҗанигә билгеле булмаган борынгы гарәп, фарсы, төрки, шул исәптән госманлы чыганакларын вә кулъязмаларга нигезләнеп, бер үк вакытта Европа һәм рус тарихчыларының хезмәтләрен дә файдалана.

Галим үзенең кабатланмас хезмәтендә көнбатышның яшәү рәвешен, анда хөкем сөргән яңа мөнәсәбәтләрне фаш итә. Әйтергә кирәк, заманында әлеге «яңа шаукым» ислам дөньясының байтак алдынгы фикер ияләренең йөрәкләрен җилкендерә, әсир итә. Тарихчы әлеге әсирлекнең асылын ачып сала. Хәер, Морад бәйнең бу фикерләре бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмаган. Ул кискен рәвештә көнбатыш кыйммәтләрен тәнкыйть

итеп чыга. Капиталистик җәмгыятьтәге әхлакый нормаларның түбән булуын, ерткычлыкны, рухи төшенкелекне, кешеләрнең берөзлексез узыша-узыша табыш артыннан кууын калку итеп күрсәтә. Аның фикеренчә, Европа мәдәнияте казанышлары Ислам мәдәниятенә нигезләнеп, шуңа таянып күтәрелеп киткән. Аның фикеренчә, европалылар цивилизация нигезләрен мөселман җәмгыятеннән отып, үзләренә күчереп алганнар, үсеш, алгарыш юлларын да алар мөселман-төрки кавемнәрдән үзләштергәннәр. Галим чиксез иркен сахраларда, күчмән тормыш белән яшәүче төрки кавемнәре Париж, Лондон яки Берлинда мәгыйшәт итүчеләрдән бер дә ким түгел, хәтта әхлаки, рухи яктан, сәламәтлек ягыннан күпкә өстен булуын исбатлый.

***Габдерәшит Ибраһимов М. Рәмзи турында***

Ошбу урында күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм сәяхәтче Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) Морад хәзрәт турында язганнары белән танышып китү урынлы булыр. 1879–1884-нче елларда хаҗ сәфәре вакытында Рәшит хәзрәт Мәдинә-и-Мөнәвәрәдә Морад Рәмзи белән очраша, аның өендә була, тормыш-көнкүреше белән кызыксына. Боларны барысын да ул бәйнә-бәйнә сәяхәтнамәсенең бер бүлегендә тасвирлый. Мөхәммәдморад әфәндене «хәзерге дәвернең иң күренекле галимнәреннән берсе», дип атый. Аның иң тирән эчтәлекле һәм иң олы хезмәтләре арасыннан «Талфик әл-Әхбар...»ны «иң мәшһүр, тиңе булмаган бөек әсәр», дип бәяли. Морад хәзрәтнең ярты гасырга якын вакыт Мәккә-и-Мөкәррәмәдә яшәп, Исламны өйрәнү вә тарату юнәлешендә армый-талмый эшләвен, байтак фәнни хезмәтләр язуын, фарсы, гарәп, төрек телләрен мөкәммәл рәвештә белүен искәртә. Аның ысул вә фөруг фәннәре әһеле, тәфсир вә хәдис фәннәре буенча олы белгеч булуын билгеләп, Шуның өстенә, Нәкышбәндийә тарикатенең олуг шәехе булуын да искәртә. «Әмма, шушы гыйлем иясенең, – дип яза Р. Ибраһимов, – кадере юк, аны тиешенчә бәяләү җитми һәм ул мохтаҗлыкта яшәргә мәҗбүр». Ул Мәккәдә татар хаҗилары тукталып яши торган мосафирханәдә бәүваб, ягъни хезмәткәр, ишек сакчысы, швейцар вазифасында хезмәт итеп гаиләсен, туганнарын тәэмин итәргә мәҗбүр. Рәшит Ибраһим фикеренчә, бу хәл – голямабыз, җәмәгатьчелек өчен хурлыклы гамәл. Дин галимен, күренекле шәхесне шундый кимсетүгә, түбәнчелеккә төшерү белән һич кенә килешеп булмый, ди ул [Ибраһим: 2011. ББ. 156–157].

***Тарихи хезмәт***

М. Рәмзи ватанына кайткан чакта китапханәләрдә, архивларда, шул исәптән Петербургтагы баш архивта да эшли. Әлбәттә, бу эзләнүләрнең максаты олуг галим Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең мәшһүр «Мөста-

фадел-әхбары» үрнәгендә татарның борынгы чорлардан алып үткәнен тасвирлау була. Морад Рәмзи, тарихи чыганаклардан тупланган мәгълүматларны, әйтелгәнчә, ике томга җыеп, «Тәлфик әл-Әхбәр вә талких әл-Әсар фи вакаигъ Казан вә Болгар вә мөлек ат-Татар» исемле әсәр яза. Унбиш ел дәвамында иҗат ителгән әлеге хезмәт авторга тарихчы-галим, киң карашлы гыйлем иясе данын китерә. Әмма ләкин китап 1908-нче елда Оренбургта дөнья күрү белән, коточкыч шау-шу куба. Әлеге хезмәттә патша цензурасы, югарыда күрсәтелгәнчә, крамола таба. Чынлыкта, автор озак еллар дәвамында рәсми хакимият тарафыннан мөселманнарга карата астыртын рәвештә алып барылган корткычлыкны фаш итә. Аны христиан диненә һәм, гомумән, рус хөкүмәте, Ислам дине әһелләренә карата нәфрәтле карашларны куертуын гаеп итеп, китапны конфискацияләп юк итергә карар чыгарыла. Нәтиҗәдә 3 мең тираж белән басылган китапның нибары 200 данәсе генә таралып өлгерә. Галимгә карата җинаять эше кузгатыла, әмма властьлар аны кулга алырга өлгермиләр, чөнки М. Рәмзи Русиядән качып китә. Бу хакта 1911-нче елның 18 мартында жандарм идарәсенә юлланган донесениедә әйтелә.

Безнең замандашыбыз, филология фәннәре докторы, тарихчы Марсель Әхмәтҗанов галимнең ошбу хезмәтен бәяләп, болай ди: «М. Рәмзи-Мәкки татар халкының тарихын яктыртуда батыр йөрәкле галим-тарихчы булуын, милли тарихыбыздагы «ак тапларны» ачыклауда кыю, ихластан хакыйкатькә омтылучан көрәшче, чын татар зыялысы, милләт күзлегеннән вә аның мәнфәгатьләреннән чыгып фикер йөртүче тарихчы, эзләнүче булуын күрсәтте».

Татар тарихындагы кыерсыту, җәберләүләр белән бәйле караңгы чорларга зур игътибар бирә галим. Мәсәлән, ул татарны хуҗасы таяк белән суктырылган эт белән чагыштыра. Хуҗасы никадәр каты итеп кыйнаса да, бичара маэмай, чарасызлыктан, барыбер аның каршына койрыгын болгап барырга мәҗбүр, чөнки башка җирдә сыенып һәм ризыкланыр урыны юк. Билгеле, татар үзенә карата мондый мөнәсәбәт белән бер дә разый түгел. Ул нәфрәтләнә, каршы чыга. Татар өчен хәтта «урыс» дигән сүз дә каты каргыш, әшәке сүз булып санала, ди. Кардәшләре берәрсен «урыс» дип үчекләсә, ул канга батып сугышачак, «эт» яки «дуңгыз» дип үртәсәләр дә моның кадәр нәфрәтләнмәс иде, дип искәртә тарихчы.

Икенче бер җирдә, Морад хәзрәт, татарга карата басым, кыерсытулар Аллаһ Тәгалә тарафыннан мәрхәмәт, әҗер-савап ул, шуңа да әлеге золымны Аллаһ Тәгаләгә рәхмәт укып кабул итәргә генә кала. Ни өчен? Чөнки шушы золым, дошманлык нәтиҗәсендә халкыбызда туган нәфрәтләнү «бөек милләтнең» әхлагына да, яшәү рәвешенә дә, гореф-гадәтенә дә тискәре мөнәсәбәт тудырып, алардан читләшүгә сәбәп иде, ди. Һәм,

киресенчә, моның урынына йомшаклык вә дустанә мөнәсәбәт булган тәкъдирдә, халкыбыз әллә кайчан урыслашып, чит кавем арасында эреп юкка чыгып беткән булыр иде, дип тә яза галим. «Димәк, Кодрәт Иясе, шулай теләгән!» – дигән нәтиҗәгә килә ул. Патша хөкүмәтенең милләтләргә карата алып барган мәкерле вә рәхимсез сәясәте башка диндәге халыкларга, милли азчылыкларга кагыла, алар барысы да нык цензура басымын тоеп гомер кичерә. Галим фикеренчә, бу халыкларның белем алу, мәгърифәткә, мәдәнияткә тартылулары да миссионерлар тарафыннан аяк астына салып таптала. Әлеге милли азчылыклар мәгариф өлкәсендә дә, китаплар, дәреслекләр белән тәэмин ителештә дә чикләүләргә дучар ителгән. Алар Европадан китап та кайтара алмый... [Шунда ук. Б. 359].

«Талфик»ның беренче томы Идел буе Болгар тарихына багышлана.

«Татарлар-сөнниләр, – дип яза галим, – гакыйдадә Матуриди мәзһабен тоталар, эш-гамәлләре әбү-Хәнифә мәзһабе буенча. Алар арасында бидгатьчеләр юк, гамәлләрне Аллаһны күргән кебек, Аллаһ каршында башкаргандай кылалар».

Болгар бабаларыбызның чыгышы турында М. Рәмзи: «Болгар халкы төрки кавемнәр, чуваш, чирмеш һәм арлар катнашмасыннан гыйбарәт иде һәм Мәрҗани ушбу нәтиҗәне чыгарырга батырчылык итмәгән», – дигән фикер әйтә. Дөрестән дә, Шиһаб хәзрәт бу мәсьәләгә төгәл җавап бирүдән читләшә. Гәрчә аның кулында булган мәгълүматларда казан татарларының этногенезына чуваш компоненты[1*] катнашуы турында хәбәр булса да.

Башка бер урында Рәмзи болай яза: «Мәрҗани хәзрәтләре максатына (милли тарихыбызны тасвирлауда) ирешә алмавын аңладым. Байтак урыннар төшеп калган. Бу халык турында билгелесе уннан бер өлеше дә сөйләнмәгән. Ә китерелгәннәренең байтагы чынбарлыкка туры килми. Әмма Мәрҗанинең хезмәте танылуга, рәхмәткә лаек. Чөнки ул башлап юл ярган, туган халкының муенына кодрәт һәм куәт муенсасы элгән, аның дәрәҗәсен тагы да күтәргән. Аллаһ аңа миһербанлы булсын, ул тасвирлап өлгерми калган әйберләрне кичерсен, чөнки әлеге халыкның тарихын ныклап өйрәнүдә бигрәк ул илләрдә (Русиядә) зур киртәләр, кыенлыклар бар».

### *М. Рәмзигә карата Зәки Вәлиди фикерләре*

Безнең тарафтан айлар буе алып барылган эзләнүләр бушка булмаган икән, ниһаять, 2018-нче елның 1 мартында университетның сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә Хаҗитарханда нәшер ителгән «Идел»

1 Чынлыкта, чувашлар үзләре бер өлешләре белән болгардан булганнар, шуңа да моны аңлаган Ш. Мәрҗани мәсьәләне куертмаган (Ред.).

гәзитенең тупланмасының 124-нче һәм 125-нче саннарында [Идел: 1909-а. 30 гыйнвар; Идел: 1909-б, 3 февраль] Әхмәд Зәки Вәлидинең «Морад әфәнде тарихы вә голәмаи Мәрҗани» дигән мәкаләсенә тап булдык. Бүгенге укучыга кыен аңлашыла торган гарәп-төрки шивәсендә язылган ушбу мәкалә галим һәм тарихчы Морад Рәмзинең «Талфик әл-Әхбәр» дигән ике томлы хезмәтенә карата рецензия буларак язылган. Автор беренче җөмләдән ук китапка һәм аны язган М. Рәмзигә карата кискен тәнкыйть уты ача. Ул Рәмзине хәтта «исламият һәм инсаният каршында гаять бөек гаепледер, гаепле генә түгел гөнаһлыдыр һәм дә гафу улынмаслык бөек гөнаһлыдыр», дип белдерә. Вәлиди фикеренчә, «Морад әфәнде иштә бу кадәр сүзләр, бу кадәр эшләр илә гаять бөек әдәпсезлекләр кылыр һәлә бөтен әһел тәсаувыф вә бәдәлгә тәгънәсилә Морад әфәнде кеби догаглара бөек җинаять идәр, имеш. Иштә никадәр бөек гаепләр! Тарих сәхифәләрендә куе кара илә язылачак бөек гөнаһлар. Никадәр бөек эшләр гаҗәп!» – дип кат-кат тәкрарлый. Гаепләүнең асылы бәдәлгә, олуг дин галимнәренә тиешле дәрәҗәдә хөрмәт күрсәтмәү, аларны олыламау, тарихчының тәкәбберлеген фаш итүгә кайтып кала. Мәкалә авторы галимне суфичылык тарафдары – зандик *(дәһри)* дип белдерә. Һәм иң зур гаеп – олуг галим Мәрҗанинең әсәрләренә тәнкыйть күзлегеннән карау. «Бу бөек милләтнең дүрт хөдүдендә иң бөек хезмәтләр күрсәткән, вөҗүде йөзләренчә түгел, мең сәнәләр эчендә фитратендә *(үткән вакытта)* ярым вәхшилектә яшәп килгән русия мөселманнарының иң бөек мөфхире *(горурлыгы)* булган бер фазыл галимнең йөзенә кара итеп ягарга тырышу. Аңа дуслык күрсәткән кеби итеп тырнак астындагы керләрен йөзенә сөртү – бөек гөнаһтыр, никадәр бөек җәримәдер *(җинаять)*». Рәмзи «үзенең язган тарихында Мәрҗани әсәрләреннән доһа *(акыллы)* күп әхаз *(алган)* хәлдә бу кадәр сүзләр сөйләү – һич гафу улынмаслык гөнаһтыр».

Буш гаепләүләр, буш мәкалә бүгенге тел белән әйткәндә «заказ» буенча язылган ахрысы. Шунысын да искәртеп үтик, ни гаҗәп, газета идарәсе дә аның мөхәррире, алдынгы карашлы галим, педагог дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдрахман Гомәри (1867–1933) моңа теләктәшлек белдерә. Вәлидинең язмасыннан соң, менә нинди анонс бирә: «Мөхтәрәм Вәлиди әфәндегә тәшәккүрмез бәгдендә бәдәлче Морад яки хаҗ сөмсәре *(арадашчы)* Мәрдәншаһ агайның кем идекене заман яхшы күрсәтте. Галимҗан *(Баруди)* хәзрәтнең тәлинкә вә сөякне ялаган вакытта аның мәдрәсәсен күккә очырган иде, соңра Галимҗан хәзрәтне сөер итмәгәч, аны вә мәдрәсәне сүгеп кем идекене галәмгә изһар *(белдерде)* итте вә моның тәфсилене *(җентекләп)* вакыт илә язармыз», – дип белдерә «Идел» гәзите идарәсе.

Хакыйкатьтә әлеге теманың дәвамы булганмы-юкмы? Янә бер сорау, ни сәбәпле Зәки Вәлиди язмасын Казанда, Өфедә яки Оренбурда бастыр-

мыйча, читтә, Хаҗитарханда игълан иткән? Әлбәттә, бу хакта эзләнүләр алып бару кирәк. «Шура», «Вакыт», «Йолдыз»да, гомумән, ул чордагы татар матбугатында, бу язмага мөнәсәбәт белдерү булганмы? Ә иң мөһиме – Морад хәзрәт үзе бу гаепләүләргә ни дип җавап бирде микән? Әлеге мәсьәләләргә алга таба ачыклык кертү сорала.

Ике арадагы каршылыклар турында Вәлиди үзенең «Хатирәләр»ендә дә искәртеп үтә. Авырып ятканда ул М. Рәмзинең ике томлык тарихи әсәре белән танышкан икән. «Русиянең исламга каршы рәнҗүле гамәлләре хакында кискен сүзләр белән ачынып язылганына күрә, – дип искәртә Вәлиди, – рус хөкүмәте ул китапны сатудан алган. Троицкиның Зәйнулла ишан китапны тентүдән яшереп калган нөсхәләренең бер өлешен безгә вә агама күндерде. Бу китапны тарату эше белән атам шөгыльләнде. Мин килешмәгән кайбер урыннары булса да, мине төрк кауменең тарихы белән тирән кызыксынуы илә мәшгуль булырга мәҗбүр иткән бу әсәрнең байтак урыннарына, патша хөкүмәтенең ачуын чыгарганга, мин кат-кат укыдым. Хаста килеш китап укып ятакта ятканымда, күзләрем бозылды».

Зәки үзенең Хаҗитарханга сәяхәте турында да язып китә. Сәфәргә дигән акчаны атасының ике атын сатуын, анасы да күпмедер мая бирүе хакында бәян итә. «Бу җәһәттән сәяхәт әйбәт булды», – ди Зәки. «Идел» гәзитенә мәкаләләр яздым», – дип дәвам итә Вәлиди, – болар, гәзит мәкаләсе булулары белән бергә, минем беренче фәнни хезмәтләрем иде. Иң башта мин Морад Рәмзинең әсәрен җентекләп өйрәнеп, тәнкыйть итеп, бер мәкалә бастырдым. Бу язучы Мәрҗанигә хаксыз ябырылган иде. Мин Мәрҗанине – алдынгы фикерле дин галиме, Морадны исә бер кадимче санаганыма күрә, Мәрҗанине бик каты якладым. Бу язмамны Мәрҗанинең шәкертләре вә дуслары бик яхшы каршылады». Истәлекләрдә шәһәр зыялыларының егетебезне әйбәтләп каршы алулары, кунактан-кунакка йөртүләре турында, мул табынлы мәҗлесләр оештырылуы турында да хәбәр ителә. Вәлиди яшь, чибәр егет, аны яңа гына оешкан «Мәгариф» журналына эшкә димлиләр. Ул гына түгел, бер бай нугай хаҗиенең өендә «мөкәммәл нугай милли ашлары» әзерләнә. Хуҗаның бик гүзәл бер кызы бар икән, кунак егетенә аңа да «игътибар» итәргә тәкъдим ясала. Кунак утырган өйнең ачык тәрәзәсе каршыннан ике тәгәрмәчле, өсте каплаулы «көймә» дип аталган, матур итеп бизәлгән арбадан милли нугай киемнәренә төренгән гаять чибәр бер кыз килеп чыккан. «Җанымны тартучы гүзәл бер кыз иде бу», – дип искәртә Вәлиди. Әмма, нindидер сәбәпләр аркасында, егет белән кыз кавышмый кала. Әстерханда төпләнеп калуны, яңа басманы җитәкләүне, гаилә коруны Вәлиди хуҗаларның боерыгы, фәрманы дип аңлый. Ахырдан әлеге тәкъдимнәрдән баш тарта һәм ике арада салкынлык урнаша. Нәтиҗәдә Зәки, Габдрахман хәзрәт

Гомәри өеннән китеп, кунакханәгә күченә. Хәзрәт хәтта кунакны пароходка билет алыштырырга да, озатып җибәрүгә дә катышмый. «Идел»дә чыккан мәкаләләре өчен дә бер тиен акча, «каләм суы» түләми.

Шунысы да бар: Вәлиди үзенең «Төрки татар тарихы»н китап итеп 1917-нче елда гына бастыра. Әлбәттә, аның ягыннан күпмедер дәрәҗәдә Морад Рәмзидән көнләшү, аны җәмәгатьчелек каршында начар итеп күрсәтү, хакимият алдында җаһилләнү дә булуы мөмкин.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**


1. «Идел» газетасы. Хаҗитархан, 1909-а. №124. 30 гыйнвар.
2. «Идел» газетасы. Хаҗитархан, 1909-б. №125. 3 февраль.
3. Габдерәшит Ибраһим. Казан: «Җыен», 2011.
4. Татарские интеллектуалы. Казан: «Мәгариф», 2005.
5. А. Тимергалин. Миллият сүзлеге. Т. 2. Казан: Тат. кит.нәшр., 2016.

*Д. Н. Таҗи*

# КАРМЫШ АВЫЛЫ МИСАЛЫНДА МӨСЕЛМАН МӘХӘЛЛӘЛӘРЕ ЯЗМЫШЫ

## *КАРМЫШ МӘЧЕТЕ*

Кармыш авылы (Чирмешән районы) Әлмәт районы чигендә урнашкан. Монда Болгар дәүләте чорында ук кешеләр яшәгәнлеге, болгарларның дошманнан саклану корылмалары, урлары (вал) булуы мәгълүм. XVIII гасырда Чирмешән районындагы авылларның, таш кирмәннәрнең төзелүе «Кама аръягын угры кешеләрдән, башкорт һәм калмыклардан саклау өчен» 1652 елларда Кама аръягы сызыгын булдыруга бәйле. Монда сүз Россиянең ныгытылган чик сызыгы турында бара. 1731–1736 елларда яңа чик сызыгын төзүдә патша бөтен булган мөмкинлекләрне файдалана. Нәкъ шул болгар урлары нигезеннән файдаланып, урыслар чик корылмаларын күтәргән, дигән фикер яшәп килә. Авылга XVIII гасыр башларында нигез салынган, дип китапларда язылса да, аның исеме Казан ханлыгы чорында ук яхшы билгеле булган. 1551-нче елда урыс хакимияте Касыйм ханлыгыннан Казан тәхетенә хыянәтче Шаһ-Галине хан итеп билгели. Ул ханлыкның бәйсезлеген яклаган 71 күренекле кешеләрне үтерттерә. Шулар арасында бик күп бай җирләрнең хуҗасы булган Карамыш оглан да һәлак ителә. Ул әсирлеккә төшкән, дип тә языла. Карамыш оглан атлы гаскәр башлыгы да булган, дигән хәбәрләр очрый. Хәзерге Кармыш авылы Карамыш огланның Кама арты биләмәләре, дип фараз кылына. Гамир Гарифуллин да үзенең мәкаләсендә [Ватаным Татарстан: 2010] бу авыл турында бик кызыклы мәгълүматлар китергән: «Яшь патша Иван IV Казанны алу өчен җиденче походка әзерләнә. Илбасарлар Казанны алырга ярдәм итәргә тиешле форпост төзү өчен урын эзли башлыйлар һәм Зөя елгасы тамагында бер биеклекне күреп алалар. Якынрак килсәләр, бер торак пунктка тап булалар. Бу Казан ханлыгының Олы Әмир дигән авылы була. Табигый ки, хәрби бәрелеш башлана. Нәтиҗәдә, күп санлы дошман басымы астында җирле халык туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр була (хәзерге вакытта аларның нәселләре Чирмешән районының Кармыш авылында көн күрә). Олы Әмир авылы зираты әле дә билгеле». Районда Әмир дигән авыл да бар әле, анысын да онытырга ярамый. Икенчеләре, авылны Казан губернасы Чабаксар өязендәге Кармыш-Янгильдино авылыннан күчеп китүчеләр нигезләгән, дип яза. Иң кызыгы тагын шунда: татар дөньясының илаһи бер заты Ризаэддин Фәхреддиннең борынгы бабасы Кармыш әл-Болгари бине Тансар булган. Кармыш

авылы (Чебоксар өязендәгесе) турындагы риваятьтә дә [Татар халык риваятьләре һәм легендалары: 2000. Б. 161] Кармыш баба искә алынган. Мөфти Ризаэддиннең туган авылы Кичүчатка һәм без телгә алган Кармышка бер чордарак чуваш ягы тарафыннан килеп урнашканнар. Ризаэддин хәзрәтнең борынгы бабалары хәзерге Яшел Үзән районындагы Шырдан авылында яшәгән булсалар, Чирмешән районындагы Кармышка килүчеләрнең күбесе шуннан ерак булмаган Кармыш-Янгильдинода яшәгән. Әлбәттә, мондый фаразлар һәм исемнәрнең уртаклыгы тарихчы галимнәребезнең тикшеренүләре белән ныгытылса, югалган тарихыбызның тагын бер бите ачылыр иде. Кызганыч ки, без Мәскәү архивларына сорау җибәрсәк тә, җавап килмәде. Авылыбызның тарих сандыгын кайдан табарга соң, дигән уй гел күңелдә йөрде.

Тарихчы Рәфыйк Насыйров янына киңәш сорап бардым. Рәфыйк хәзрәт Аксубай районы Түбән Майна авылында имам, мәктәп директоры, төбәгебез тарихын өйрәнә. Ул Мәскәү архивларында эшләп бик күп тарихи язулар җыеп кайтты. Безнең үтенеч белән «Кармышның башлангыч чоры» исемле мәкалә язды. Шул исем астындагы тарихи сәхифәне укысагыз, тарих киштәләрендә гасырлар буе яткан серләрнең шаһиты булырсыз, тарихыбызның никадәрле катлаулы, сикәлтәле һәм аянычлы булуына төшенерсез. Һәм иң аянычлысы: безнең төбәктә, ягъни Чистай өязендә, иң күп чукындырылган халык кармышлылар булганы ачыкланды. Мәшһүр Гаяз Исхакыйның үлемсез «Зөләйха» әсәре безнең авылдагы фаҗигале вакыйгалардан чыгып язылмадымы икән, дип, ирексездән уйлап куясың. Гаязетдин «әзи» үзе дә Чистай өязеннән, ата-бабасы Кармыштан ерак булмаган Лашман һәм Елховой авылларында имамлык кылып яшәгәннәр.

Үзебезнең язманы дәвам итәбез. Әлбәттә, бу эштә таба алган архив материалларына таянабыз.

Казан губернасы Чистай өязенә караган Кармыш авылы халкы бервакытта да рәхәт тормышта яшәмәгән. Элек тә һәм хәзер дә, үз-үзеңә генә ышанып яшәүне өстен күрә. Хакимиятнең берсе дә аңа мәрхәмәт күрсәтмәгән. Бу татар-мишәр авылы да патша салымнары, совет тәртибе белән изелгән, озак еллар чукындырулардан җәберләнгән, гел куркытылып торган, үзе иген үстерсә дә ипигә туена алмаган. Кармыш авылы татарлары дәүләт крәстиәннәре булып исәпләнгәннәр һәм урыс крәстиәннәре кебек үк үзләренә йөкләтелгән бөтен дәүләт салымнарын түләгәннәр («платящие оброчную подать»).

1780-нче елда Кармышта 39 мөселман татарлар белән 10 җан яңа керәшеннәр булган. Шуннан ерак түгел, Түбән Кармыш дигәнендә 25 йомышлы татар яшәгән [Корсаков: 1908. Т. 2]. 1795-нче елда теркәлгән ре-

визия язуы буенча Түбән Кармышта чукынган ясаклы – 13 йорт (60 кеше), чукындырылмаган ясаклы – 17 йорт (141 кеше), лашман йөкләмәсен башкаручы татарлар 30 йорт (98 кеше) яшәгән. Лашманчылар Казандагы Адмиралтействога кораблар төзү өчен урман кисеп ташыганнар. Ә хатын-кызлары кырда да һәм өйдә эшләгәннәр. Хәзерге Чирмешән районы авылларында алар һәр авылда диярлек булган. Лашман дигән авыл да шул урман кисүчеләргә бәйле. «Лашманс» немец теленнән урман кисүче дигәнне аңлата. Кайсы җирләрдәге урманнар киселде икән? 1812-нче елгы Ватан сугышына да шул гади кешеләрнең балаларын Наполеонга каршы җыеп киткәннәр. Ул гына да түгел әле, Россиянең көн саен диярлек алып барган империя сугышларында Кармыш яугирләре гел катнашып торган. 1816-нчы елда уздырылган ревизия язмаларында авылда 32 ясаклы татар һәм 18 керәшен гаиләсе яшәгән, диелә [НА РТ. Ф. 324. Оп. 740. Д. 348; Ф. 3. Оп. 2. Д. 600]. 1858 елда татарлар – 61 гаилә, керәшеннәр 21 гаилә исәпкә алынган [НА РТ. Ф. 3. Оп. 2. Д. 397]. Аларны чын керәшеннәр белән бутамаска кирәк. Бу керәшеннәр христианлыкны күңел белән кабул итә алмаганнар, чиркәү дә төзелмәгән. Шуның өчен дә эзәрлекләнгәннәр, мөселманлыктагы кардәшләре белән дә каршылыклар килеп чыккан. Керәшеннәрне мөселман зиратына күмдермәгәннәр, аларның аерым зиратлары булган, аларны тоту закон тарафыннан мәҗбүр ителгән. Әле узган гасыр уртасында керәшен зиратында сакланган буралы, чардуганлы каберлекләрдә Гыймран бабай Салаватов, Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешү өчен, әрвахлар рухына дога кылып йөргән. Кармышның 1854-нче елгы план-картасында мөселман һәм христиан зиратлары аермачык күрсәтелгән. Монда җирләнүчеләр үзләрен мөселманча күмүләрен ялварып сораганнар. 1858-нче елдан соң Кармыш керәшеннәрен «отпавшие в ислам» дип санасалар да, христиан миссионерлары һәм чиновниклар аларга 1905-нче елга кадәр тынгылык бирмәгәннәр. 1905-нче елда беренче урыс инкыйлабы шаукымы астында патша Николай II дин ирегe турында указ чыгара. Ә аннан соң, ягъни 1917-нче елдан башлап, яңа совет хөкүмәте ислам һәм христиан диннәрен бетереп, юкка чыгара.

Башкалабыздагы Милли архивта Казан губернасының губерна идарәсендәге «Мөхәммәдия» мәхәлләләре исемлегендә (1876–1897-нче еллар) Кармышта беренче мәхәлләнең кайсы елда оешуы һәм кайчан беренче җәмигъ мәчет салынуы билгесез, диелгән. Аксакаллар әйтүенчә, авылда 1760–1770-нче елда ук гади бер мәчет булган. Бишенче ревизия буенча, Түбән Кармыш дигәнендә 1795-нче елда агач мәчет эшләве билгеле [НА РТ. Ф. 324. Оп. 740. Д. 348]. Ул биш вакыт намаз уку өчен бер йорт булгандыр, мөгаен. Аның манарасы булу-булмавын да әйтә алмыйбыз. Кем белә, бәлки анда җомга намазлары гына укылгандыр. 1846-нчы елгы

бер документта мәчет «пятивременный», ә 1872-нче елда «соборная» дип язылган, бу елда авылда 362 ир-ат, 368 хатын-кыз яшәгән. Авылда яшәгән керәшеннәр аркасында рәсми мәчет төзү катгый тыелганын да беләсездер, безнекеләр, ничектер, үз мәчетләрен булдырганнар. Димәк, Кармыш әле 1870-нче елдан соң гына җәмигъ мәчетле булган. Татар авылларында һәр дүртпочмаклы йорт мәчет вазифасын башкара алган. «Әллә кайсы аның мәчет, белә алмыйбыз»,–дип тәре походы вәкилләре патша кәнсәләренә һәрдаим үзләренең елак шикаятьләрен язып торганнар. Кармышта бабаларыбыз 1870-нче елда тузып беткән мәчетне сүтеп, яңасын төзеп куялар. Моңа Казан губерна идарәсенең рөхсәт итү документы да юк. Ул елларда татарга рөхсәтсез бернәрсә дә эшләргә ярамаганын барыбыз да яхшы беләбез. Бу гамәл–тәвәккәллекнең бер мисалыдыр, мөгаен. Шул ук архив фондында губернаның төзү бүлегендә дә (1868–1870) Кармыш мәчетенең проект-рәсеме юк. Уфадагы тарих архивында Чистай өязенең метрикалары буенча, монда Мостафа улы Шаһиәхмәт 1829-нчы елда имам, Бурангол улы Нигъмәтулла (1799–1860) 1836-нчы елда имам, хатыны Мәхмүбә абыстай. 1858-нче елгы ревизия язуы буенча, 7 баласы булган, Шәрәфетдин исемлесен 1855-нче елда 12 елга патша хезмәтенә алып киткәннәр. Бурангол бабай якынча 1752–1811-нче елларда яшәгән. Габделҗәлил улы Габит 1846-нчы елдан имам [ЦИА РБ. Ф. И-295. Оп. 9. Д. 229, Д. 231, Д. 238]. Нигъмәтулла мулланың абыйсы Сәлимҗәгъфәр Буранголов улы Идиятулла (Һидаятулла) Сәлимов (1815 елгы) 1837-нче елдан азанчы һәм мәдрәсәдә укытучы, мәзинлеген 1890-нчы елга кадәр башкара. Без шуңа таянып, инде ул елларда ук авылда мәдрәсә эшләгән, дип әйтә алабыз. 1851–1874-нче елда мулла мөгаллим Фәтхулла Төхфәтуллин 70ләп ир бала укыткан, хатыны Фатыйма абыстай. Мөхәммәтсадыйк Бикмөхәммәтов мөгаллим һәм сабиан 1867-нче елда указ алган. Җәмигъ мәчеттә 1876–1899-нчы елларда Габид хәзрәт Хәмитов (метрикада Хәлилов дип тә языла, 1799–1899) имам-хатыйп һәм мөдәррис, 1841-нче елда указ алган. Биредә Фәтхулла хәзрәт вафатыннан соң, Спасс өязе Түбән Әлки волосте Иске Тяжбирде (Ташбилге) авылыныкы Мөхәммәтхафиз хәзрәт Мифтахетдинов (1847) имам җәмигъ, хатыйп һәм муллагалим булган. Дини эшчәнлеген 1875-нче елдан башлаган. Хафиз хәзрәт Чистай өязендәге Түбән Майна авылына күчеп киткәч, 1882–1912-нче елларда Габдрахман хәзрәт Әхмәтҗанов (1856 елгы) имам җәмигъ, хатыйп һәм муллагалимлек иткән. Ул Яңа Кади авылыныкы. Башта Уфа губернасы Бәләбәй өязе Иске Дөмәйле авылында Мөхәммәтсадыйк Габделхәлим хәзрәттә сабак алып, Казанда Апанай мәдрәсәсендә укыган, хәрби хезмәттә дә булган. 1912-нче елда мәрхүм, авыл зиратында кабер ташы яхшы сакланган. Ул Кармышка килгәндә Габид хәзрәтнең

күрү сәләтен югалтканлыгы, үзенә генә дини вазийфаларны башкаруы авыр булуын да язып куйганнар [НА РТ. Ф. 2 Оп. 2. Д. 894. ЛЛ. 61 об.–62; Д. 509. ЛЛ. 4–9; Д. 273. ЛЛ. 226–227; Д. 1076. ЛЛ. 112 об.–113; Д. 2598. ЛЛ. 104 об.–105; Д. 5568. ЛЛ. 309 об. 310; Д. 2258. ЛЛ. 6–9; Ф 204. Оп. 177. Д. 760. Л. 70 об.]. Казан губернасының мәчетләр саны һәм дин әһелләре исемнәре күрсәтелгән ведомостьларда авыл мәктәп-мәдрәсәсендә 1875-нче елда – 15 малай; 1895-нче елда – 90 малай, 42 кыз; 1906-нчы елда – 60 малай, 30 кыз; 1909-нчы елда 80 малай, 43 кыз укыган. 1880-нче елдан соң Кармышта зурайтылган мәдрәсә эшләгән, атасыз-анасыз калган яшь сабыйларны тәрбияләү өчен ятимнәр йорты ачыла (дом малолетних сирот, йорт саны 17, авылдагы йорт хуҗаларын күрсәткән 1886-нчы елгы исемлек [НА РТ. Ф. 81. Оп. 2. Д. 1094]).

Мәчет казнасына кергән сәдакаларның зур өлеше ятимнәрне карауга китә. Кызганычка каршы, без Казандагы милли архивтан Казан губернасында 1843–1913-нче еллардагы балалар приютлары һәм ятимнәрне асрау йортлары турындагы фондта Кармыштагы ятимнәр йорты хакында мәгълүмат таба алмадык. Авылның беренче мулласы халык хәтеренә Җәгъфәр Мөхәммәтшәриф улы исеме белән кереп калган. Аның Гобәйдулла (1785 елгы), Хәйбулла (1789 елгы), Хәмидулла (1791 елгы), Ибатулла (1799 елгы) исемле уллары Кармышта үз гаиләләре белән яшәгәнлекләре 1858-нче елгы ревизия язмалары белән раслана. Әшәлче поселогы имамы Нурулла хәзрәт әйтүенчә, шул нәселдән булса кирәк, әтисенең бабасы Хәмидне туганы, бәлки, улы Габид хәзрәт икән. Аның өстәрәк телгә алынган Габид Хәмитов икәнлегенә бернинди шик тә калмый. Бу исем Р. Фәхреддиннең “Асар” әсәренең икенче томында телгә алынган. Габид бине Габделҗәлил әл-Кармышый Чистай өязе Яңа Әлмәт авылы (хәзер Нурлат районы) имамы Нигъмәтулла (1771–1853) бине Гобәйдулла бине Җәгъфәр шәкерте булган. Аңарда кыйраәт һәм тарикать гыйлемен алган. Авылда болай дип сөйлиләр: «Имештер, Габид хәзрәт кыйраәт иясе икән, Кармышның Әшәлче болынына төшеп үсемлекләр, шомырт чәчәкләре, кошлар белән сөйләшкән. «Кизләү» мәдрәсәсендә укыган һәм укыткан». Укытучысы Нигъмәтулланың әтисе мәшһүр шәех Гобәйдулла (1751–1823) бине Җәгъфәр бине Ибраһим Нурлат ягындагы атаклы «Кизләү» мәдрәсәсен җитәкләгән, шул авылның имамы. Бу нәселдән бик күп күренекле муллалар, каллиграф Лотфулла Әлмәти (балалары булмаган), язучы Абдулла Алиш (1908–1944), тарихчы галим Сәлам Алишев (1929) чыккан. Әлеге нәселне Кармышның беренче имамы Җәгъфәр Мөхәммәдшәриф улы белән бутамаска кирәк һәм бу гаиләдән дә бик күп дин әһелләре туган. Авылда табылган кайбер истәлекләрдә, документлар белән расланмаса да, Җәгъфәр хәзрәтнең алты улы бар, диелә. Бер улы,

бәлки, оныгы Лотфулла хәзрәт, Чистай өязендә танылган укымышлы дин белгече, авыл мулласы, гарәпчә-татарча нәфис язучы, күңелләрне дәвалау дәрәҗәсендә телгә оста кеше булган. Хәтта Мисырда укыган, дигән хәбәрләр бар. Җәмәгате Чистай сәүдәгәре Мияссәр кызы да (исемен белә алмадык) – дини гыйлемле абыстай. Имештер, Казан нәшриятларында дини китапларны басмага әзерләгәндә кулъязмалардагы кимчелекләрне дөресләргә Лотфулла хәзрәтне гел дәшеп торганнар. Ике улы Мөхәммәтгали белән Габдрахман, күршедәге Бәркәтә авылында «Әхмәдия» мәдрәсәсендә укыганнар. Мәдрәсәнең җитәкчесе, үз заманының галиме, имам Әхмәтвәли бине Мөхәммәт Рахим әл-Бәркәтәи (1862) Казан вә Петербург шәһәрләрендә мөселман җәмәгатьчелеге белән аралашып торган, шуннан китаплар алып кайтып, төрле авылларга тараткан. Патша Николай турындагы имеш-мимешләрне беренче аңардан ишетеп белгәннәр. Әхмәтвәли хәзрәт (1861) 1893-нче елда Бәркәтә авылындагы өченче мәчеткә икенче имам булып килгән. Яңа Чишмә районы Чиртуш авылында туган. Соңыннан ахун дәрәҗәсе алуга ирешкән. Кулъязма китаплар язу белән дә шөгыльләнгән, гарәп, фарсы телләрен яхшы белгән, алты тапкыр хаҗга барган. 1903–1904-нче елларда Бәркәтәдә Равил бай ярдәме белән җәмигъ мәчет төзетә, мәдрәсәсендә төрле авыллардан килгән шәкертләрне укыта. Аның мәдрәсәсендә уку зур дәрәҗә саналган. Совет репрессиясе елларында – 1928-нче елда кулга алынып, 3 елга сөргенгә җибәрелгән. Соңгы көннәренә кадәр имам булып, 1953-нче елда авыл зиратына җирләнгән. Кабер ташы яхшы сакланган. 1912–1913-нче уку елында Кармыш егетләре Габделхәй Фәзулов, Мөхәммәтсафа Җиһаншин, Фатыйх Кәшәфетдинов, Хәбибулла Шәрәфетдиновлар аңарда укыган. Әхмәтвәли мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәтгали Мөхәммәтҗанов Киекле (Нурлат районы, Бурмәт авылы) авылына муллалыкка чакырсалар да, дәрәҗәгә кызыгып, Кармыштан аерыласы килмәгән. Муллалыкка указы булмаган изге җан Мөхәммәтгали хәзрәт Чистай жандармнарыннан керәшеннәрне исламга кайтарганы өчен «предупреждение» алса да, Ислам диненең кодрәтен арттырып, тәречеләр хәрәкәтеннән рухи зыян күреп рәнҗетелгән авылдашларын яклый, бергә җыеп җәмәгать, җомга, гает намазларын укыта, мәрхүмнәрне аерым зиратка мөселманча җирләп соңгы юлга озата. Мөселманлыкта калган кардәшләребезнең манарасыз гына гыйбадәт кылу йортлары булган. Ул йорт рәсми хөкүмәт чиновникларыннан сер итеп сакланган, дип тә сөйлиләр аксакаллар. Шул караңгы заманнарның истәлеге булган керәшен зираты әле дә бар. Аның тирәсенә чыршылар утыртып, тапталып кадерсезләнмәсен, дип, Ибненәгыйм бабай Миңнегулов (1912–1988) тимерчыбыклы кыршаулар куйдырып калдырган. Мөхәммәтгали озак яшәми, үзе, җәмәгате, кызы Җәлия 1908-нче

елда ваба зәхмәтеннән үлә. Җәлиянең ятим кызы Гарәфияне (1894–1975, Кармыш авылының Әшәлче поселогы имамы Нурулла хәзрәт әнисе), улы Әбелхарисне (1897–1941), этиләренең ир туганы Габдрахман һәм абыйлары Әхмәткәрим тәрбиягә ала. Әхмәткәрим бабай, Әбелхарисның сәләтле бала икәнен күреп, аны Әлмәт ягында Габдрахман әл-Тайсугани нигезләгән мәшһүр Тайсуган мәдрәсәсенә укырга алып бара, үзе дә шунда укый. Идел буе халыкларының, бигрәк тә татарларның милли баш күтәрүләреннән шүрләп, большевиклар махсус оештырган, дип фаразланган 1921 елгы ачлыкта һәм табигать алып килгән корылыкта Әбелхарис Себердәге Тубыл төбәге Алга (Уба) авылына барып урнаша. Чынлыкта Мәскәү кушуы буенча татар хөкүмәте башлыгы С.Сәетгалиев, халыктан разверстка ясап, бөтен булган тереклек итү продутларын талап алып, Мәскәүне ашатырга җибәрә. Әбелхарис Ватан сугышына киткәнче Убада яши. Нәселе, балалары анда. Алга авылы хәзер дә бар, ул–таралып, үлеп баручы татар авылларының берсе. Заманында бу авылны Чирмешән районыннан күчеп киткән мишәрләр нигезләгән, дип сөйлиләр.

Кармышта 1908-нче елда 1543 кеше яшәгән, 5 кибет, бөртек тарттыру тегермәне, мәктәп, 1200 дисәтинә чәчүлек җирләре, Сөлчә инеше һ.б. булган.

Җәгъфәр мулланы янә телгә алсак, аның оныклары күбесе мәдрәсәләрдә укыган булса да, дәһриләр төзегән Совет империясе аларның дини юлын кискән, шул рәвешле татарның милли яшәешен Иблис юлына, явызлык хакимлегенә кертеп җибәргән. Җәгъфәр мулла оныклары Бәдретдин Фәттәхетдинов, Әхмәткәрим (1891–1976) белән Әбелвафа (1895–1987) Вәлиевләр Тайсуган мәдрәсәсендә (хәзерге Әлмәт районы) Мостафа Габделганиев, Мөхәмммәттаһир Байтукалов хәзрәтләрдә, Вәгыйзь, Мәхмүт, Әхмәтгата Минаҗетдиновлар күрше Бәркәтәдәге “Әхмәдия” мәдрәсәсендә укыганнар. Шулай ук Талибетдин бине (1869–1921) Хәйретдин бине Фәхретдин бине Гобәйдулла Җәгъфәр Тайсуган мәдрәсәсендә казыйлык һәм хәлфәлек итә. 1895-нче елдан имам-хатыйп [Уфадагы тарих архивы. Ф.И-295. Оп.2. Д.5]. Кушаматы «Мишәр мулла». Соңыннан Сарман районы Рангазар авылында икенче мәхәлләдә имам, 40лап бала да укыткан, яңа мәдрәсә һәм яңа мәчет бинасы ачуны оештырган. Ул 1892-нче елда Кармыш авылында мәэзин дә булып торган. Әлбәттә, туган тиешле энеләрен Тайсуган мәдрәсәсенә урнаштырырга ярдәм итми калмагандыр. Талибетдин мулла балалары да совет тарафыннан җәберләнә, алар Кыям, Локман, Мәрьям, Хәсән, Хөршидә, төрле сәбәпләр белән, Ташкент якларына Маргеланга күчеп китәләр. Хөршидәнең кызы Гәүһәр Ниязовна Билалетдинова Советлар Союзы чорында Мәскәүдә «Женщина» журналында эшләгән. Кыям Җәгъфәров (1900–1967) Үз-

бәкстанда, Фирганә өлкәсе Маргелан авылында яшәгән. Дүрт баласы булган, элекеге кызылармияче, 263-нче укчы полкта хезмәт иткән. 1947-нче елда – ефәк комбинатында склад мөдире, шул елда кулга алынып, Казанга «черек күл» зинданына җибәрәләр. 1948-нче елда суд булып, 58-нче маддә белән 25 елга ирегеннән мәхрүм ителгән (24656 санлы җинаять эше). Атып үтерелүдән котылган кешеләрне әнә шулай озак елга төрмәгә утыртканнар. Ул сугыш вакытында әсирлектә немецлар ягында оештырылган «Идел-Татар» («Идел-Урал») легионында хезмәт иткән, легионерларга лекцияләр укыган. Шагыйрь Муса Җәлил белән аралашкан. «Туран кызы» дигән поэма авторы. Әсирлектә дә, туган иленә кайткач та бик күп җәфалар чиккән. Репрессия янамасын өчен хатыны һәм балалары, хәтта туганнары үзеннән ваз кичәргә мәҗбүр була. Шулай итмәсәләр, тормышларында югары дәрәҗәләргә ирешә алмаслар иде. 1956-нчы елга кадәр Караганда янындагы Карабаш лагеренда шахтада эшләп, бик каты авырып, амнистиягә эләккән. Бик соң гына, 2002-нче елда акланган. Кыямның оныгы Үзбәкстаннан Илдар Милушев бабасының нәселләре турында язылган көндәлекләре белән танышу өчен аларны миңа бирде. Кыям Җәгафәров көндәлекләрендә безнең тарихыбыз өчен кызыклы мондый юллар бар: «Ерак бабаларым Фәхретдин картның атасы Гобәйдулла, аның атасы Җәгъфәр исемле булып, шул ук Кармыш авылында дини җитәкче – мулла булып хезмәт итә. Бу елларда мөселманнарның Диния нәзарәте юк. Киресенчә, татарларны Ислам диненнән биздерү, аларны христиан диненә күчерү, чукындыру сәясәте алып барыла. Татар авылларына гаскәрләр белән поплар килеп, корал көче белән куркытып, көчләп халыкны чукындыралар. Кармыш авылы да шунда. Кармышның бер тәбәк халкы куркыту, җәзалау нәтиҗәсендә формально чукынган булалар. Кайберләре, урманнарга качып, Ислам динендә калалар. Бу озак елларга сузылган, урыс булмаган халыкларны изү, кимсетү, аларның мөстәкыйль кешелек тойгылырын богаулау өчен шундый кабахәт сәясәтне үткәзәләр. Шактый еллар узып, 1767-нче елда Казанга әби патша Екатерина килә. Әби патшаның Казанга килүен ишеткән һәм белгән халык, бигрәк тә чукындырылганнар, үзләренең моң-зарларын патшага җиткезергә һәм «гафу» сорарга баралар. Кармыш халкы да патша исеменә түбәнчелек белән гариза язып, Казанга кеше җибәрәләр. Алар үзләренә ата-баба динендә калырга рөхсәт сорыйлар. Шул вакытлардан алып Кармыш татарлары тагын мөселман булып китәләр. Җәгъфәр хәзрәт исә милли һәм дини иҗтимагый көрәшләрдә катнашып, милләт мәнфәгатьләрен кайгырта. Аерым агентларның доносы белән рус хөкүмәте кулга ала һәм ул шул китүеннән хәбәрсез югала». Кыямның энесе Хәсән 1990-нчы елда Кармышка җибәргән хатында: «Без, балалар, әтиебезнең туган авылы

Кармышны, аның туганнарын бик нык ярата идек. Борһан, Бәдретдин, Нуретдин, Фәттах абзыйлар Рангазарга кунакка еш киләләр иде», – ди. Җәгъфәр мулла нәселеннән 1895-нче елда Кыяметдин (1847) Җәләлетдинов, уллары Хөснелгата белән Әхмәдгатаны алып, бәхет эзләп Төркиягә китеп бара. Ике улы Кинҗәл белән Сөнгать Чистайда яшәп кала. Шактый җәфа чигеп, ике еллап барган ул солтан иленә. Барып төпләнгәч, барча туганнарын үз янына чакыру булган нияте. Туганнарын да китертә алмаган, бик тырышса да, үзе дә кайта алмаган. Безнең чорда улы Әхмәдгата (1885–1946) балалары һәм оныклары Кармышта яңа мәчет салырга матди ярдәм күрсәтте. Әхмәдгата Кыяметдиннең оныгы Бәһзәт Акташ Төркиядә, Искешәһәр янындагы Госмания исемле татар авылында туган. Улы Әмре Акташ (зәркәнче-сәнгать белгече), 2006-нчы елда Казан кызы Сәрия Нигъмәтуллина белән Кол Шәриф мәчетендә никахланып, бабаларының Ватанында төпләнеп калды. Кыяметдиннең энесе Әгъзаметдин хаҗи (1857) – Чирмешән районы Түбән Кәминкә авылы имамы. Ул дини гыйлемле, мөнәҗәтләр башкарырга оста кызы Җәүһәрияне (Җувәйрә, 1890–1982) Иске Кади авылы имамы Сәрвәретдин хаҗи Хәйретдиновка (1871) никахка бирә. Бу ике мулла – репрессия корбаннары. Гасыр башында Түбән Кәминкәдә өч мәчет, өч мәхәллә эшләп торган. Әгъзаметдин хаҗи беренче каты – таштан, икенче каты агач бурадан күтәрелгән йортта яшәгән. Беренче катында чүпрәк-чапрак белән сәүдә итеп, мануфактура тоткан. 1930-нчы елда мал-мөлкәтләрен колхозга тартып алып Әгъзаметдинне, җәмәгате Фатыйма абыстайны (1878), уллары Камилне (1912–1964) Магнитогорскига сөрәләр. Мулла бабай белән абыстайны чүплекләрдән әрчелгән бәрәңге кабыклары җыеп йөргәннәрен күргәннәр. Алар шунда, бер телем икмәккә тилмереп, урамда өшеп, ачлыктан үләләр. Уллары Камил авылдашлары ярдәме белән авылга әйләнеп кайта. Курск дугасында барган канлы сугышларда командирын коткарып, ике күзе дә сукырая. Гаилә 1992-нче елда акланган. Сәрвәр хәзрәткә килгәндә, ул – Бәркәтә авылы кешесе, өч мәчетле Иске Кади авылына имам итеп җибәрелгән, 1931-нче елда кулга алынып, ун елга хөкем ителгән, гаиләсе сөрелгән. Бәркәтәдә бай тормышта яшәгән дүрт балалы (абыйсы, дип уйлыйбыз) Кәшаф Хәйретдинов та (1869) 1930-нчы елда ун елга концлагерьга элэгә. Соңыннан икесе дә атылган, дигән хәбәрләр дә бар.

Кармышта туган тагын бер абруйлы имам – Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтулла улы Мансуровны Чистай муллалары хөрмәт иткән. Ул 1863 елдан Бигәш авылында беренче җәмигъ мәчеттә имам. Аның турында Сарманда яшәүче тарихчы Дамир Гарифуллин «Герәнтау итәгендә» (2007) китабында кызыклы мәгълүматлар китерә. Ул аны Чистай өязе Карамалы авылында 1830-нчы елда туган, дип яза. Безнең эзләнүләр бу-

енча, Мотыйгулла хәзрәт Кармыш авылында туган. Аның 1858-нче елгы ревизия язмалары буенча, Чистай өязендәге Кармышта абыйсы мулла Фәтхулла Төхфәтуллин гаиләсендә яшәгәнлеген белдек. Бу вакытта аңа 27 яшь булган. Аксакалларның бу кеше безнең авылдан чыккан, дип әйтүе дә очраклы сүз түгелдер, мөгаен. «Западные башкиры» китабында да (Уфа. «Хан» нәшр., 2010) ул Кармыш авылыныкы итеп бирелә. Мотыйгулла хәзрәт уллары Әбелкасыйм белән Мәүләви-Шәриф Чистай шәһәрендә Закир хәзрәт Ваһһапов мәдрәсәсендә, Казанда Габдулла Апанаев мәдрәсәсендә укыганнар. Әтиләре һәм ике улы Бигәш авылында мулла булып торганнр. Бигәш 1960-нчы елларда Әлмәт шәһәре биләмәсе эчендә калды. Әбелкасыйм 1905-нче елдан ахун дәрәҗәсен алуга ирешкән. Ике хатын белән яши. Икенчесе, мөфти Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936) сеңелесе Маһирә (1878–1915). Балалары совет властеннан кимсетелеп яши. Энесе Мәүләви-Шәриф хатыны Галимә абыстай вакытсыз дөнья куйгач, үзеннән 26 яшькә яшьрәк, Мөхәммәтҗан бай кызы Өммегөлсемгә (1904) өйләнә. Алты кыз балалары туа. 1930-нчы елда Мәүләвине совет хакимияте авылдан сөрә. Йортлары талап алына.

Егерменче гасыр башында Кармыш авылында ике указлы мулла Ярулла Гатауллин (1871) һәм Габдрахман Бикколов (1885) дини мәгърифәтчелек кылган. Ярулла хәзрәт Уфа губернасы Минзәлә өязе Ерсубай волосте Туймәт авылыннан. 1899-нчы елда Тәтеш өязе училищесында урыс теленнән имтихан тапшырган. Чөнки 1887-нче елдан хөкүмәт: «Барлык муллалар урыс теле буенча имтихан бирергә тиешләр», – дигән указ чыгара. Халыкның бу указга каршы чыгып тавыш күтәрүе дә тарихта билгеле. Ярулла шул ук 1899-нчы елда мөселманнарның Уфадагы Диния нәзарәтеннән имам-хатыйп һәм мөгаллимлеккә шаһәдәтнамә ала [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 6065. Л. 3–22]. Ярулла Норлат янындагы Кизләү мәдрәсәсендә атаклы шәех Гобәйдулланың оныгы Әхмәт хәзрәт Мөхәммәт улында, Казанда Апанай мәдрәсәсендә укыган, армиядә патшага хезмәт итәргә дә өлгергән. Инде тәмам чиккә җитеп картайган вә сукырайган Габит хәзрәт үзенең урынына беренче имам вазифасына Ярулланы куюны сораган, авыл җыены (сельский сход) аның фикерен хуплап, тавыш бирә. Сукыр мулла белән эшләве Габдрахман хәзрәт Әхмәтҗановка җиңел булмаган, күп мәшәкатьләрне үз җилкәсендә тарткан. Габит хәзрәтнең әле 1882-нче елда ук сукыр булуын әйткән идек. Бу кеше тумыштан ук сукыр булмадымы икән дигән уебыз да бар. Ул авыл халкы асрамасында яшәгән булса кирәк. 101-нче яшендә вафат булган. Мулланың кошлар, шомырт чәчкәләре белән сөйләшә алган, дип сөйләүләре дә сукырларга хас нәрсә кебек. Сукыр икенче төрле, күңел күзе белән күрә, диләр түгелме? Сукыр булуына карамастан, указлы мулла булып

озак еллар халыкка хезмәт иткән, изгеләр рәтенә кергән һәм вакытлар узу белән исеме шулай да онытылган. Адашы Габдрахман вафатыннан соң яңа килгән икенче Габдрахман исә Ерсубай волостена кергән Бәркәтә авылыныкы, Мөхәммәди мулла улы. Башлангыч дини гыйлемне әтисеннән һәм үз авылында «Әхмәдия» мәдрәсәсендә алган. 1910-нчы елда Минзәләдә дүрт сыйныфлы училищеда урыс теле буенча сынау уза, 1912-нче елда Уфада имам-хатыйп, мөдәррислеккә шаһадәтнамә алып, шәкертләрне җәдитчә укыта [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 8980. Л. 6–19]. Тәртип бозучы шәкертләрен мәдрәсә буйлап нәзек чыбык тотып куып йөргүен бабайлар мәзәк итеп сөйләгәннәр. Совет чорында Ярулла һәм Габдрахман муллалар гаиләләре белән авылдан сөрелгәннәр. Казанда чыккан «Крәстиән гәзите»ндә [1929 ел, 23 август саны] Габдрахман Биккулов муллалыгын ташлавын белдерә. Элек дин әһелләрен мәчетләргә сайлап кую авыл җыеннарында хәл ителгән, приговор дигән документ тутырылып, шунда ук сайлаучыларның исемнәрен теркәп куйганнар. 1890-нчы елда азанчы Һидаятулла Сәлимҗәгъфәр улы вафатыннан соң, авылда 10 еллап рәсми билгеләнгән азанчы булмаган. 1900-нчы елда халык җыенында аның улы Мостафа, әгәр ризалык бирсәләр әтисе урнына килергә, Уфага барып мәзинлеккә имтихан тапшырырга әзер булуын әйтә. 124 кеше яклап тавыш бирә. Приговорга авыл старостасы Госман Миңнегулов, Күтәмә волость старшинасы Барабашкин мөһер сукканнар, хәтта күрше Әккәрәйдән пүнәтәйләр (понятые) чакыртып, документның юридик көчен арттырганнар. Мостафа, Уфага барып, шаһәдәтнамә алып кайта. Документка мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов, казый Риза Фәхреддин кул куйганнар. Шулай итеп, 1901-нче елдан мәзинлек Мостафа хәзрәткә күчә [НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 6430. Л. 2–10]. Бурадан күтәрелгән бердәнбер мәчеттә чиратлашып намаз укыталар, дин эшләрен бергә башкаралар. Мәчетне, Чистай сәүдәгәрләре Егор һәм Никита Чукашевлардан агач сатып алып, бөтен мәхәллә белән төзекләндергәннәр. Хөрмәтле авылдашыбыз Нариман ага Кәримов үзенең «Кармышым» исемле китабында [Казан, РИО ГБУ «РЦМКО», 2012] без белмәгән һәм әле архивта да табылмаган хәбәрләр җиткерә. Ул бик кызыклы, аннан өзек китерәбез: «Авылның зур мәчетен төзүдә күп матди өлеш кертүче һәм төзелешне оештыручы минем бабам Әхмәткәрим Миңлегали улы исәпләнә. Ул заманында патша армиясендә зур дәрәҗәдәге офицерның кучеры булып хезмәт иткән һәм аннан күп акча алып кайткан, ди. Шул акчага үзенә алтыпочмаклы өй салдырган, таш кибет төзеткән. Калган акчасын халыктан җыйган акчага кушып, яңа зур мәчетне төзиләр. Әхмәткәрим бабай үз акчасына мәчет идәннәренә яхшы сыйфатлы келәмнәр җәйдергән, мәчетне җылытырга утын, яктыртырга керосин белән тәэмин итеп торган».

Кармыш мәчетенең манарасын 1931-нче елда төнлә кисеп төшереп, совет клубы ачалар. Соңыннан авылның денсез коммунистлары, «бер ашар өчен чиркәү башына менәргә әзер» торган кайбер бәндәләр, алданган халык мәчетнең нигез ташына кадәр сүтеп, урлап бетерәләр. Элекеге мәчет хәзерге Мәдәният йорты нигезендә торган. Мостафа мәэзин улы Харрас Һидаятуллин (1891–1978) авылның беренче совет укытучысы булса да, башка иптәшләреннән аермалы буларак, дингә пычрак атып, ата-баба әманәтенә хыянәт итми, иманлы, зыялы кеше булып кала. 1948-нче елда Кармыш җидееллык мәктәбен оештыра. Районда 1950-нче елда Ленин ордены белән бүләкләнүчеләрнең беренчесе. Әтисе Мостафа бабай урынына бераз мәэзин булып та тора, мәдрәсәдә дә укыган. Совет укытучысына мәэзин булырга ярамый бит, бу вазифасын калдырырга мәҗбүр була. Шулай да, Тайсуганда бергә укыган дуслары Әхмәткәрим белән Әбелвафа Вәлиевләрдә бергә җыелып яшерен генә Коръән уку мәҗлесләре, Корбан гаете бәйрәмнәрен оештырып, дөнья хәлләре турында фикер алышканнар. Харрас абый 1920-нче елда Аксубай районы Иске Ибрай авылында укытканда Кармышка ялга кайткач, февраль аенда, хәзерге Әлмәт районы Дальняя Ивановка һәм Яңа Елань авылыннан (сәнәкчеләр штабы) килгән фетнәче сәнәкчеләргә эләгә. Совет укытучысын, кул-аякларын бәйләп, инештәге бәкегә батырмакчылар, йә бастырып атмакчы булалар. Аны һәм совет хезмәткәрләрен элек кайчандыр авыл старостасы булган Госман Миңнегулов (1872), үз өстенә зур җаваплылык алып, үлемнән коткара, мәктәп тә яндырылмый. Укытучы Харрасның әтисе Мостафа мәэзин белән Госман бабабыз троюродный братлар икән бит (1858 елгы ревизия язуларын кара). Сәнәкчеләрнең күбесе аны электән үк күреп белгән, хөрмәт иткән. Авылда кан түгелмәүдә, кармышлыларның фетнәчеләргә теләктәшлек күрсәтеп сугышка кушылмауларында, фетнә бастырылгач авылдан беркемнең дә җәзага тартылмавында аның роле зур. «Сәнәкчеләр Кармышка кермәгән», – дип яза «Кармышым» китабында Н. Кәримов. Моның белән килешәсе килми. Чөнки милли архивта сакланган «Беренче май» райисполкомы, Чистай кантисполкомы документлары буенча, Татарстаннан 1930-нчы елда сөрелергә тиешле гаиләләр исемлегендә, кулакларның 1930-нчы елгы шәхси карточкаларында, шулай ук 1932-нче елда сайлау хокукыннан мәхрүм ителүчеләр исемлегендә дә Миңнегулов бу фетнәдә актив катнашкан, авылда оештыручы һәм комендант булган, дип язылган [НА РТ. Ф.Р-2757. Оп. 3. Д. 46. Л. 16 об.; Оп. 5. Д. 8. ЛЛ. 16–18; Ф. Р-2027. Оп. 16. Д. 5. ЛЛ. 20, 98–102]. Халык хәтерендә сакланып килгәнне сызып ташлау – Н. Кәримовның хәленнән килә торган эш түгел. Авылда фетнәнең тыныч узып китүе аркасында гына ул документларга теркәлмичә калгандыр. Ул вакытта,

авыллар буйлап чапкан совет җәза отрядларына «бездә дә сәнәкчеләр бар», дип әйтергә беркемнең дә башына тай типмәгән. Харрас бабай да үзен коткаручыларны сатмаган, теләсә нәрсә сөйләнеп тә йөрмәгән. Җәза отрядлары фетнәчеләрне яклаучы авылларда гаеплеләрне дә, гаепсезләрне дә, хәтта өендә өстәл каршында ашап утырган бер гөнаһсыз кешеләрне атып үтергәннәр. Бары тик соңыннан гына, авыл куштаннары бу хәлләрне совет түрәләренә әләкләгәннәр. Сугыш ветераны Мохиббулла Касыймуллин (1923–2012) сөйләгәннәрдән: «Әтиебез Касыймулланың йорты совет правлениесе булып торган. Монда Госман бабай сәнәкчеләр белән җитди сөйләшүләр алып барган, дип сөйләгәннәрен яхшы хәтерлим. Бу йортта сәнәкчеләр кайдандыр атка бәйләп алып килгән хөкүмәт яклы кешене ябып тотканнар. Аны коткару мөмкинлеге булмагач, һич югында, советчыны авылда үтермәгез, дип сораганнар. Соңыннан бу бичараны Кармыш белән Әккәрәй авыллары арасында җәзалап үтергәннәр». Бу вакытта авылга терәлеп торган чуваш Әккәрәй авылында 12 кешенең үтерелүен, ахырдан сәнәкчеләрнең үзләрен дә судсыз-нисез юк итүләрен искә төшерсәң, Миңнегуловның зирәклегенә, каһарманлыгына тагын бер кат инанасың. Госман бабай Кармышта җире аз хуҗалыкларга Күтәмә урысларыннан җир алып бирүдә, юридик мәсьәләләрдә бик булышкан. Мондый кешене совет органнары вәкилләре дә бик тиз күреп, үзләренең кара эшләрендә файдаланмакчы булалар. Чистай совет милициясеннән җитәкче урын тәкъдим итсәләр дә кызыкмаган, «динемнән язып, халыктан каргыш алып Коръән таптап йөрисем килми, мин бит мөселман», дип, җавап бирә. 1921-нче елгы ачлыкта күрше Әккәрәйдә кешеләр бер-берсен суеп ашаганнар, дип сөйлиләр. Ачлыктан үлгән 889 кешенең итле урыннары кисеп алынуы тикшерү протоколына теркәлгән. Шундый хәлләрне Кармышта да булдырмас өчен Госман бабай халыкны сабырлыкка өндәп йөргән, күзәтү, кизү оештырган, ачлыктан котылу чараларын бергәләшеп эзләргә чакырган, диләр. Шулай да Кармышта кеше ашауның бер очрагы билгеле. Ике айлык баланы ашаганнар. Аның авыл мулласы Ярулла хәзрәт белән мөнәсәбәте бер дә мактанырлык булмаганлыгы да билгеле. Госман бабайның 1905-нче елда мулла өстеннән мөфтияткә язган шикаяте Уфадагы Үзәк дәүләт тарих архивында әле бүген дә саклана [ЦИА РБ. И-295, Оп.6. Д.855. Л.10–10 об]. Мәхәллә имамы Ярулла хәзрәт, дин эшләреннән читләшеп, төрле сәүдә эшләре белән шөгыльләнә икән. Сәүдә итү документларын хатыны Мәгъсүмә Габитова (беренче хатыны) исеме аша йөртә, үз вазифасын калдырып еш кына Чистайга, йә Казанга бара. Ярулла хәзрәт үзенең аңлатмасында сәүдәчелек белән шөгыльләнмәвен, хатынының гына сату итүе, мәхәлләне калдырып, теләсә кая китмәве, үзен җәмәгатьчелекнең хөрмәт итүе, 70 кыз бала һәм 80 ир

бала укытуы турында акланып яза. Мөфтият әлеге шикаятьне нигезсез гаепләү, дип таба. Анда тагын ике кармышлының Ярулла турында шикаяте бар.

1930-нчы елларда авылдан 7 хуҗалык сөргенгә куылган, тагын 15 хуҗалык кулаклар исемлегенә кертелә, дигән исемлек Татарстан милли архивында бар. Авылда 1928–1930-нчы елда оешкан беренче башкарма комитеты рәисе Миржаҗан Хәйдәров (1892–1982) совет власте, партия кушкан бөтен явыз таләпләрне бер карусыз чын күңелдән башкара. Авылдашларын йортларыннан кудырып, бар мөлкәтләрен колхозга дип талап ала, гаиләләрне Себергә озата, кайберләрен төрмәләрдә черетә. Яңа колхозлар оештырабыз, дигән сылтау белән авылның ярты халкын каторгага җибәрү белән куркытып, Саклык һәм Әшәлче поселокларына нигез салдырып, шунда мәҗбүри күчерттерә. Миржаҗан компроматлар, шикаятьләр язуы һәм буш сүзне дә күпертә алуы, мәчетне яптыруы белән яманаты чыккан, дип сөйлиләр. Мактаулы хезмәте өчен «КПСС сафларында 50 ел» дигән абруйлы билгегә лаек булган. Ул Ватан сугышы ахырына кадәр авылда совет хакимлеге өчен тырышып эшләгән. Сәркатибе Гыйльфан Маннанов та аннан калышмаган. Авылдашлары сәүдәгәр Гайса Гыйбадуллин, Габдрахман хәзрәт Бикколов, Ярулла хәзрәт Гатауллин, Сибгат Гыйззәтуллин, Кәшәф Җәләев, Фатыйх Кашаповлар, йортларыннан куылып, сөргендә җан газабы кичерә. Сәнәкчеләр фетнәсендә катнашкан Исмәгыйль Ибраһимов 1932-нче елда дәүләткә ашлык тапшырмаган өчен 5 елга хөкем ителгән, Госман Миңнегуловның Рәбига исемле кызы белән яшәгән. Госман бабайны беренче мәртәбә кулга алырга килгәч, халык бирми. Авылда яңа власть өчен иң куркыныч кеше ул булган. Чөнки халыкның күпчелеге нәрсәдер өмет итеп, аның янына тупланган, киңәш сораган, аңа авыл башлыгы итеп караган. Берникадәр вакыттан соң, караңгы төннәрнең берсендә, коралланган бер дистә кызылармиячеләр, Кармышка килеп, аның үзен, хатыны Хәнифә (1880), улы Салих (1907), килене Минсорур (1910), кызы Фәһимә (1912), уллары Хәмит (1918) белән Мосавирны (1919) бергә алып, Красноярск краендагы Удерейский районы Мотыгино авылына сөрәләр [НА РТ. ФР-2027. Оп. 16. Д. 5. ЛЛ. 20, 98–102]. Госман бабайның хатыны 3–4 булып, нәселе бик күп таралган. Документларда татар исемнәрен гел бозып, белер-белмәс язганнар. Бу мәкаләдә исемнәр дөресләп язылды. Гаилә 1998-нче елда гына акланган. Алар сөргендә урман кисү, шахтада күмер чабу кебек иң авыр хезмәткә йөргәнннәр. Гаилә башлыгын зобанилар монда да иркенләп яшәтмиләр, шымчылар һәр адымын күзәтеп, сөйләгәннәрен әләкләп торалар. Красноярск шәһәренең Федераль Дәүләт Куркынычсызлыгы идарәсенә хат юллап, эзсез югалган авылдашыбызның язмышын ачы-

клый алдык. Мондагы архивта аның һәм башкаларның П-7925 номерлы җинаять эше [Архив УФСБ России по Красноярскому краю. Ф.7, Т.2. Л.Д.121–126, 142, 178, 179; Т.3. Л.Д.357, 372, 380, 381, 387, 389] саклана. Госман бабайны, алтмыш алты яшьлек «аз грамоталы» картны советка каршы баш күтәрүчеләрнең контрреволюцион оешмасында катнашкан, сәнәкчеләр фетнәсендә командир булган, хөкүмәткә каршы агитация алып барган, дигән яла ягып, 1938-нче елның 13 маенда эштән кайтып ашап утырганда кулга алалар. Өендә тентү ясап, татар телендәге бер китап белән бер хатны да үзләре белән алып китәләр. Коточкыч җәзалап, булмаган гаебен таныырга мәҗбүр итәләр. Җавап алу протоколыннан күренгәнчә, аңа: «Сез сәнәкчеләр фетнәсендә рота командиры булгансыз», – диләр. Ул: «Мин бу фетнәдә катнаштым, анда командир булып йөрмәдем», – дип җавап бирә. Аның ничек итеп фетнәчеләрдән совет укытучысын үлемнән йолып калуы да протоколга махсус кертелми. Коммунист авылдашлары да бу батырлыкны күрмәмешкә салышкан. НКВД җанкисәренең мондый сорау бирүе дә урынсыз булмагандыр, мөгаен. Чөнки 1920-нче елда коммунистларның азык-төлек талавына каршы баш күтәрүчеләр һәр авылда үзләренең «бишлекләр»ен, «өчлекләр»ен оештырганнар, ягъни болар авылның биш-алты кешелек яңа җитәкчеләре, булачак рота һәм взвод командирлары. Сәнәкчеләр нәкъ менә шундый бер вазифаны Госман бабайга йөкләгәннәрдер һәм ул авылны афәттән саклап калу өчен ирексездән моңа риза булгандыр. Фетнәчеләр сөңгеләр, сәнәкләр һәм сирәк кенә винтовкалар белән коралланып, авылдан-авылга йөреп, халык җыеннары уздырып, беркатлылык белән: «Яшәсен совет власте, бетсен коммунистлар!», – дип кычкырып йөргәннәр. Аның белән бер үк вакытта кулга алынган якташы Уткин Евдоким Ефимовичны да сәнәкчеләр фетнәсендә катнашканын исенә төшерәләр. Ул Госман Миңнегуловны Себердәге милли баш күтәрүчеләр төркеменә алдым, дип җавап бирергә мәҗбүр була, ягъни алдан язып куелган ялганга кул куя. Ә Госман бабайдан исә мине төркемгә Уткин кушылырга чакырды, татарлар арасында советка каршы эш алып барырга кушты, дип әйттерәләр. Уткин (1872) Аксубай районы Иске Илтерәк авылыннан гаиләсе белән 1930-нчы елларда сөрелгән. Протоколда Шаһиев Әхмәтвәли (1878), Идрисов Сәетгәрәй (1886), Калтанов Әхләф (?), Батыршин Закир (1880, 1872. П-7924 җинаять эше) кебек татар исемнәре дә очрый. Соңгысы «Хәтер Китабы» (19-нчы том) буенча Аксубай районы Иске Кыязлы авылы кешесе булырга тиеш. Ат караучы Закир бу төркемнән ниндидер могҗиза белән гаепләүдән котылган. Мәкаләдә телгә алынган контр оешма эше буенча 62 кеше кулга алынган. Шуларның 53се – Татарстаннан сөрелгән кулаклар. Калганнары – төрле республикалардан куып китерелгән милләттәшләребез. Шу-

нысы кызганыч, аларның кабаттан репрессияләнүе, зинданда атылуы турында, нишләптер, «Хәтер Китап»ларында да хәбәрләр очрамады. Бу кешеләр кемнәр, кайсы авыллардан булдылар икән? «Хәтер Китабы» редакциясе, безнең үтенеч белән, Красноярскига сорау җибәрде. Китапның мөхәррире урынбасары Н. Габдрахманова безгә түбәндәге җавапны юллады: «Красноярск краеннан П-7924 һәм П-7925 эшләре буенча кулга алынган 53 якташыбыз турында мәгълүмат җибәрделәр. 53 кешенең 34е турында бездә бөтенләй мәгълүмат булмаган, тагын 5 кешенең сөргенгә җибәрелгәннән соңгы язмышлары билгесез иде. Бу 39 кеше исеме «Хәтер Китабы»ның өстәмә томына кертеләчәк. Сезгә моның өчен аерата рәхмәт җиткерәсе килә. 53 кешенең 50се атып үтерелгән, берсе буенча эш туктатылган, 2 кеше 10 елга лагерьларга озатылган». Әлеге оешмага карата чыгарылган гаепләү нәтиҗәсе (15473-нче тикшерү эше) укучыга да кызыклы булыр, дип, аны тәрҗемә итмичә генә урысча бирәбез: *«В 3-й отдел УНКВД по КК поступили сведения о том, что кулацкая ссылка, состоящая в своем большинстве из татар, высланных из Татреспублики, среди населения Удерейского района проводит контрреволюционную агитацию, направленную против Соввласти и проводимых ею мероприятий, распространяет разного рода провокационные вымыслы и клевету на политику ВКП(б). Произведенным по данному делу расследованием установлено, что в Удерейском районе существовала контрреволюционная националистическо-повстанческая организация, в состав который входили кулаки-спецпереселенцы татары и частью русские, высланные из ТАССР. Указанная выше контрреволюционная националистическая повстанческая организация, созданная по заданию Турецкой разведки – спецпереселенцем муллой... Халилом, широко развернула среди кулацкой ссылки из татар к-р работу: вела антисоветскую агитацию против проводимых мероприятий партии и правительства, против политики ВКП(б) и Соввласти, распространяла контрреволюционную клевету и разного рода антисоветские вымыслы на руководителей партии Советского государства, озлобляла население против коммунистов, призывал к террору над коммунистами и вооруженному восстанию в военное время, с целью свержения Соввласти».*

Красноярск крае УНКВД өчлеге Госман бабайны атарга хөкем итә. Бу вәхши карар 1938-нче елның 8-нче сентябрендә Енисейск шәһәрендә җиренә җиткерелә. Татарстаннан сөрелеп Мотыгино бистәсендә яшәгән якташлары – Е. Уткин, Ә. Шаһиев, С. Идрисовлар да (П-7925 җинаять эше) шул көндә атып үтерелгән. Шунда ук Удерейск районының башка бистәләреннән кулга алынган Шиһап Хәсәншин (1878, Чирмешән районы Урманасты Үтәмеш авылы), Михаил Пильщиков (1903, Әлмәт районы

Яңа Никольск авылы), Гаҗи Нәгыймов (1883, Азнакай районы Тымытык авылы), Бәдретдин Садретдинов (1884, Сарман районы Кәүҗияк авылы) һәм башкаларның җанын ерткычларча кыялар. «Башлыклары» укымышлы имам Хәлил Солтанбәковны (1879, Зәй районы Бигеш авылы) 1938-нче елның 22 ноябрендә Красноярск шәһәрендә атып үтерәләр. «Асар» китабының икенче томы буенча, әтисе ахун Солтанбәк бине Сагындык – Бигеш авылы имам мөхтәсибе. Хәлил хәзрәт Кукмара районы Ядегәр авылында яшәгән, 8 баласы булган, мулла һәм мөхтәсиб. 1929-нчы елда кулга алынып, 3 елга Балахна лагерена җибәрелгән. Тарихчы Булат Солтанбәков – шул нәселдән, дип ишеткәнебез бар. Атылганнар арасында чуваш, удмурт милләт халыклары дә бар. Барысы да 1956-нчы елда реабилитацияләнгән. Госманның улы Салих 1943-нчы елда сугышта хәбәрсез югала. Аның хатыны Минсорур апа, 1946-нчы елда, ике баласы Солтан белән Зөләйханы алып, Кармышка кайта. Солтан (1940-нчы елгы) Әшәлче поселогында яши. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән хезмәт ветераны.

Кармышның иң дәрәҗәле кешеләрен, советка каршы баручылар, дип, мәгълүм 58-нче маддә нигезендә иген игүче Нурулла Әбделхәеровны (1874) 1937-нче елда кулга алып – 5 елга, Госман Миннегуловның улы, район хәзерләүләр комитеты вәкиле Исрафил Усмановны (1908) 1941-нче елда кулга алып, мөлкәтен конфискацияләп (баштан үлем җәзасы каралган була) – 8 елга, сугыш ветераны тракторчы Кәрам Исмәгыйлевне (1924) 1950-нче елда кулга алып 8 елга лагерьга җибәрелергә хөкем ителгәннәр. Соңыннан барысы да аклана. Әле сугыштан соң да, Кармыштан МТСка мәҗбүри барудан качкан яшьләрне өч-дүрт айга төрмәләргә утырткannар. Мәсәлән, шундыйларның берсе – Габдулла Таҗиев.

Авылда кырчылык бригадиры булып эшләгән өч балалы Гөлем Нуретдиновның (1901-нче елгы) язмышы да фаҗигале. Ул да – Җәгъфәр нәселеннән. Талибетдин мулла, әтисенең бертуганы. Гөлем абзыйны 1941-нче елның апрелендә (республика ФСБ архивындагы тикшерү эше 2–16846) кулга алалар. Дин әһелләренә теләктәшлек күрсәткән, Себердә җәфа чигүче мулла гаиләләренә сохари, чабаталар тутырып посылкалар җибәргән, мулла малаен кунакка чакырган, мәчетне төзекләндерергә акча җыярга кирәк, халыкның икмәген талыйлар, ачлык була, дип хәбәрләр тараткан. Хәтта мәчет китапханәсен, метрикә дәфтәрләрен, төрле тарихи документларны үзендә яшереп саклаган икән. Имештер, ул болай дигән: «Кызыл гаскәриләр шәрә килеш кайталар, чөнки армиядә үк бөтен кием-салымнарын салдырып алып калалар. Күрәмсең, Финляндия белән сугышканда бөтен запаслары да беткән. Финляндия җиңсә дә, безгә барыбер. Совет власте тел белән генә сөйли, чынлыкта – бернәрсәсе дә юк.

Колхозчының бөтен икмәген тартып алалар». Колхоз җитәкчеләре җиде авылдаштан чеп-чи ялган кәгазь яздырып, беркемгә дә зыян салмаган кыр эшләре бригадирын төрмәгә утырта. Һәр авылдашның бер ялганы, аның бер ел гомерен кискән, җиде авылдаш әлеге – җиде ел гомердән мәхрүм иткән. Бу кешеләр соңыннан булса да вөҗдан газабы кичерделәрме, зинданда, һавасыз пычрак бүлмәдә ачлыктан, үпкәсе шешенүдән, авылдашларына рәнҗеп үлгән Гөлем абзый рухына дога кылып, Аллаһыдан гафу сорарга өлгерделәр микән? Ул кыйналуларга да карамастан түзгән, үзенә тагылган ялганны танымаган. Ватан сугышының икенче көнендә, 23 июньдә суд булып, аны бер гаепсезгә 7 елга хөкем итәләр. 1943-нче елда ТАССРда, 9-нчы колониядә вафат. 1989-нчы елда акланган. Оныгы Наил Гөлемов сөйләгәннәрдән: «Әле бүген дә олы кешеләр әйтә, элек резина алу өчен күксагыз чәчә торган булганнар. Бабам әйтә торган булган: «Берзаман резина белән дөнья тулыр, барыбыз да резина галошлар киярбез», – диеп. Әйе, ул заманда резина галошлар хыялда гына булган, ләкин киләчәкне күз алдына китерүче кешеләр халыкны рухландырып эшләтә белгәннәр. Бабайның җәмәгате Мингаян (1909) Мингалим кызы өч баланы берүзе тәрбияли».

Совет чорында дин эшләрен Җәгъфәр мулла нәселеннән төрле мәдрәсәләрдә укыган Мәсгуть Сәләхов (1883–1973) башкарды. Тәравих, гает, җомга намазларын аның өендә укыдылар. Ул зират тирәсен карап, төзекләндереп торды. Бу эштә Шәриза Сәлманов, Әгъзәметдин Ногмановлар бик күп булышалар иде. Мәсгуть бабайның этисе Сәләхетдин (1856) Җәләлетдинов. Җәләлетдиннең (1833) этисе Хәмидулла (1791) бине Җәгъфәр. Авылда Фәссахетдин Җәләев, Харрас Һидаятуллин, Кираметдин Нуретдинов, Ләбип Сәхапов, Шәйхелислам Габдрахманов, Әхмәтгата Минһаҗев, Минталип Шаһиев, Габдрәшит Габбасовлар һ.б. динне алып барды.

Бүген Кармыш мәчете Чирмешән районында иң биек манаралы, иң мәгърур мәчет. Урыны да бик отышлы, ул нәкъ авыл уртасында, биеклектә тора. 1993-нче елда нигезе салына. Иң күп ярдәм авыл халкыннан җыела. Ташкентта яшәгән Мәсгуть Җиһаншин, Төркиядә яшәүче авылдашы Әхмәд Кыяметдин балалары белән сөйләшеп, кардәшләренә ярдәмгә килә. Ата-анасы 1930-нчы елларда авылдан күчеп китәргә мәҗбүр булган. Әтисе – Түбән Кәминкә авылыннан Мәгъсүм Шәйхелислам улы, әнисе Мөзәянә – Кармышныкы, авылдан сөрелгән Кәшәфетдин Җәләев кызы. Мәчет төзелешенә иске акча белән 45 миллион сум бирә. 1997-нче елда ачылган бу мәчеткә әнисе Кәшәфетдин кызы Мөзәянә (1907–1946) исеме бирелде. Мәчеткә авылның мәгълүм беренче мулласы Җәгъфәр хәзрәт исеме бирелсә дә, бик дөрес булыр иде. Авылның бер урамына

аның исемен бирүне җыенда күтәреп чыгу да мөмкин эш. Гыйбадәтханәне төзүдә «Бугульмаремстрой» директоры Җәгъфәр мулла оныгы Әбелвафа улы Локман Вәлиев, Түбән Камадан Исмәгыйль Хафизов, Кармыштан Шәүкәт Гатин, Наил Гөлемов, Төркиядән Әхмәдгата Кыяметдин балалары (20 миллион) һ.б. үзләреннән зур өлеш кертләннәр. Хәзерге имамнары – Габдрәшит хәзрәт Габбасов.

Кармыш авылыннан Миңнегалим хаҗи Мәгъсүмов (1934–2013) Әлмәттәге «Аксу» мәчете мәэзине иде. Кәшиф Гатин, Әлмәттәге Урсала бистәсе мөселманнары мәхәлләсен оештырып, Урсала мәчетенә нигез салдырды. Кармыш авылының Саклык поселогыннан сугыш ветераны Газимҗан Шәрәпов (1921–2011) Урсалыда үз йортында ун елдан артык җомга намазлары укытты. Совет чорында оешкан Саклык (1928) авылында (ул инде таралып бетте) дин эшләрен Ситдыйк бабай Гыйниятуллин (1879–1966), Фәйруша Шәрәпов (1891–1960), Габдулла Галәүтдинов (Лотфуллин) (1909–1965) башкарды. Шул ук Саклыктан Камил Галәүтдинов – Әлмәттәге Тихоновка бистәсендә дини дәгъватчы. Илнар Малик улы Шәмгунов, Р.Фәхреддин исемендәге Әлмәт Ислам дине мәдрәсәсен уңышлы тәмамлап, Мисырда Әл-Әзһәр Ислам университетында укый.

## Әдәбият


1. «Ватаным Татарстан» газетасы. 2 апрель, 2010 ел.
2. Корсаков Д.А. Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке. Т. 2. Казань, 1908.
3. Татар халык риваятьләре һәм легендалары. Казан: «Раннур» нәшрияты, 2000.
4. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 273.
5. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 509.
6. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 894.
7. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 1076.
8. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 2258.
9. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 2598.
10. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 5568.
11. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 6065.
12. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 6430.
13. НА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 8980.
14. НА РТ. Ф. 3. Оп. 2. Д. 397.
15. НА РТ. Ф. 3. Оп. 2. Д. 600.
16. НА РТ. Ф. 81. Оп. 2. Д. 1094.
17. НА РТ. Ф. 204. Оп. 177. Д. 760.
18. НА РТ. Ф. 324. Оп. 740. Д. 348.

19. НА Ф. Р-2757. Оп. 3. Д. 46.
20. НА Ф.Р-2757. Оп. 5. Д. 8.
21. НА Ф.Р-2027. Оп. 16. Д. 5.
22. НА Ф.Р-2027. Оп. 16. Д. 5.
23. Башкортостан Республикасы архивы. Ф.И-295. Оп. 9. Д. 229.
24. Башкортостан Республикасы архивы. Ф.И-295. Оп. 9. Д. 231.
25. Башкортостан Республикасы архивы. Ф.И-295. Оп. 9. Д. 238.
26. ЦИА РБ. Ф.И-295. Оп. 2. Д. 5
27. ЦИА РБ. Ф.И-295, Оп. 6. Д. 855.
28. Архив УФСБ России по Красноярскому краю. Ф. 7. Т. 2. Л.Д. 121–126, 142, 178, 179.
29. Архив УФСБ России по Красноярскому краю. Ф. 7. Т. 3. Л.Д. 357, 372, 380, 381, 387, 389.

*(Дәвамы бар)*

*Ркаил Зәйдулла*

## САХА УЧАГЫНЫҢ ҖЫЛЫСЫ

Балачактан ук миңа саха-якут иле әллә кайда җир читендә булып тоела иде. Исең китәр, Рәсәй, дошманнан саклана-саклана, шунда кадәр барып җиткән бит! Төрки дөньядан еракта үз асылын фидакярләрчә саклый белгән саха кардәшләр дә миңа әкияттәге серле халык сыман күз алдына килә иде. Гаҗәеп мавыктыргыч, фәлсәфи эчтәлекле, ерак бабаларының искиткеч батырлыгына дан җырлаган олонһолар (дастаннар) иҗат иткән, ят дингә мәҗбүри күчеп тә үз йолаларын, яшәү рәвешен күз карасыдай саклаган кавемгә ничек сокланмыйсың?!

1990 елның көзендә СССРның төрки халыкларыннан берәр шагыйрьне Ташкентка чакырдылар. Киләсе елга Алишир Нәваинең тууына 550 ел тулачак, шул бәйрәмгә багышлап, аның ун газәлен һәркем үз теленә тәрҗемә итәргә тиеш иде. Үзбәк язучыларының иҗат йорты Ташкент читендәге Дүрмән бистәсендә, без дә шунда килеп урнаштык. Төркиләрдән башка, әлбәттә, ул заман таләпләренә хас булганча, урыс, украин, белорус шагыйрьләре дә килгән иде. Нәваи бөек төрк шагыйре, шул заманда чагатай дип аталган телдә иҗат иткән. Хәзерге татар әдәби теленә шул иске чагатай теленең йогынтысы әле дә сакланганга, миңа аны үз телебезгә аудару әллә ни кыен булмады. Әмма якут шагыйре Семен Руфовка шактый интегергә туры килде. Чөнки саха теле гомум төрки телдән шактый ерак, аннары аларда безнең шигъриятне борын-борыннан тукландырып, тәэсир итеп торган Ислам диненең йогынтысы бөтенләй юк. Ә Семен агай, татар әйтмешли, «бет тунаган» кеше булып чыкты: газәлләрнең бөтен мәгънә төсмерләрен аңлап, шул борынгы заманның сулышын саха телендә укучысына китереп җиткермәкче. Нишләптер, шул максатына ирешер өчен мине сайлады. Шулчакта без аның белән бик якынаеп киттек – ул сорау бирә, мин җавап табарга тырышам. Үзем дә аңлап бетермәгәнне үзбәкнең чал шагыйрьләреннән ачыклыйм. Аларның татарга мөнәсәбәте аерым, алар мине бөек мәдәниятнең бер вәкиле итеп кабул итә; дәрәҗә үземә лаек түгел, хәтта үзбәкнең олы түрәләре җыелган зур мәҗлесләрдә иң беренчеләрдән булып миңа сүз бирәләр. Бәлки мин шунда халкымның әле кайчан гына нинди югарылыкта булганын беренче мәртәбә аңлаганмындыр. Үзбәк әкәләрнең кайсылары Тукайны сәгатьләр буе яттан сөйли ала иде.

Семен Руфов аркасында мин шул вакыттан ук саха халкының тарихы, әдәбияты белән кызыксына башладым. Ул мине күренекле археолог һәм этнограф А. Окладниковның борынгы якут тарихына багышланган хезмәтләре белән таныштырды. Аның бер китабы С. Руфов култамгасы

белән әле дә миндә саклана. Ексөкүләх (А. Кулаковский) һәм П. Ойунский иҗатлары белән дә мин шул вакытта кызыксына башладым.

Без мәктәптә укыганда кайсыдыр сыйныфның урыс әдәбияты дәреслегендә Россия Федерациясендә яшәгән гайре урыс халыклары әдәбиятыннан да кайбер үрнәкләр бар иде. Кайсын Кулиев, Рәсүл Гамзатов, Мостай Кәрим шигырьләре белән бергә анда күренекле якут шагыйре Семен Даниловның да бер-ике шигыре урнаштырылган. Берсе «Русский язык» дип атала иде бугай. Соң инде... Күп еллар үтәр дә, Даниловның туган авылында булырмын, андагы яңа Мәдәният йортында шагыйрьнең «Кар» дигән шигырен татар теленә үз тәрҗемәмдә укырмын, дип кем уйлаган?! Белмим, совет чорында саха язучылары белән элемтә булдымы икән, туксанынчы елларда булган бәйләнешләр дә шартлап өзелде, без кардәш халыкларның да хәл-әхвәленнән хәбәребез юк иде. Сахаларга килгәндә исә, алар белән араны соңгы елларда безнең яшьрәк буын язучыларыбыз җайлады. Бу табигый да – алар тизрәк кузгала, җиңел аралаша. Өстәвенә, Саха язучылар берлегендә рәис урынбасары булып аларның буындашы, булдыклы җитәкче, әйбәт шагыйрь Гаврил Андросов эшли икән. Ул, берлек рәисе Наталья Харлампиева кебек үк, саха әдәбиятын дөньяга таныту өчен тырыша, башка әдәбият вәкилләре белән хезмәттәшлек урнаштыруда да аның өлеше зур. Һәм менә Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Рөстәм Галиуллин кебек шагыйрь-язучыларыбыз бер-бер артлы Саха республикасында булып кайтты. Чит җирләр күрү, төрле җирләрдән җыелган каләмдәшләр белән аралашу иҗат кешесенә бик зарур. Тәэсирләре шагыйрьләрнең шигырьләрендә чагылды, Рөстәм исә якутлар арасында яшәп, анда азатлык өчен көрәшкән баһадир, сахаларның милли каһарманы буларак тарихка кереп калган татар кешесе Гыйззәтулла Рәхмәтуллин турында «Боссообко» дигән бәян дә язды. Аны якутлар «Большойка» мәгънәсендә шулай атаганнар икән. Сахалар тиз арада аны үз телләренә тәрҗемә итеп, әдәби журналларында бастырып та чыгардылар.

Чыңгыз хан заманы, һуннар тормышы турында романнар авторы Н. Лугинов, Саха республикасының халык шагыйре, Саха Язучылар берлеге рәисе Н. Харлампиева кебек күренекле әдипләр дә соңгы елларда безнең әдәби бәйрәмнәрдә катнашты.

Шушы аралашуның нәтиҗәсе буларак, саха кардәшләребез бераздан үз телләрендә хәзерге татар шагыйрьләренең шигырьләреннән тупланган җыентык нәшер итте. Аны нәни генә антология дип тә атарлык. Шигырьләрне тәрҗемә итәргә өлкән буыннан алып яшьләргә кадәр танылган шагыйрьләр җәлеп ителгән.

Газинур Морат белән икебез саха кардәшләр тарафыннан «Олы кар бәрәкәте» («Благодать большого снега») дигән шигърият фестиваленә

чакырылгач, без, әлбәттә, анда булып кайткан яшьләрнең безгә юллама бирүен аңладык. Рәхмәт аларга да, хуҗаларга да! Яшьләр салган сукмактан да атлавы рәхәт. Саха кебек олы кар дөньясында сукмакларның әһәмияте исә тагын да зур.

Безне иң беренче нәүбәттә Саха республикасы җитәкчеләренең үз әдәбиятларына яхшы мөнәсәбәте, кайгыртучанлыгы сокландырды. Төрле яклардан килгән шагыйрьләрне беренче көнне үк республика башлыгы үзе кабул итте. Мәдәният министры әлеге очрашуларда бездән аерылмады. Төрле очрашуларда аның очкынланып китеп саха телендә яттан шигырьләр укуын ничек онытасың?! Без шаккаттык, тик саха язучыларына бу хәл гадәти иде, ахрысы. Түрәләргә мөкиббән китү юк монда. «Элеккесе әйбәтрәк иде», – дип кайсыдыр сукранып та алды.

Мәктәпләргә таралдык. Милли телләргә каршы һөҗүмнең кыравы аларга да тигән, билгеле. Әмма Казан белән чагыштырганда кечкенә генә Якутскида бишме-алтымы милли гимназия эшли, барлык фәннәрне дә сахача укыйлар. Мин барган гимназиянең уку-укыту эшләре мөдире булып, республикада танылган шагыйрь Рөстәм Канженкин эшли иде. Яше утыздан әле генә ашкан, көче ташып тора. Укучыларның бер-бер артлы чыгып үз шигырьләрен укуында Рөстәмнең (сахалар да бу исемне кушалар икән!) өлеше, һичшиксез, зур.

Мәктәптәге бер зал нәкъ якутларның элеккеге тирмәсен хәтерләтә, анда этнографик әсбаплар; гөмбәзе каядыр өскә, җиде кат күккә ашкына, керүгә үк Саха иленең тарихи һавасы сине урап ала. Сахалар үзләренең тарихларына шулкадәр игътибарлы, мөкиббән, сакчыл; алар өчен ул үткәннәр генә түгел, бүгенге чынбарлык та. Менә кинәт дөмбәренә сугып озын чәчле кам безне алышка чакырыр сыман. Шигъри алышка инде, әлбәттә! Бераздан без аның камлавын ишеттек тә. Тамак төбе белән җырлауны да тыңладык. Саха шигъриятен чын-чынлап тәмен тойыйм, дисәң, сахаларның ватанын – кар дөньясын, кодрәтле Лена елгасын, иксез-чиксез тундраны, боланнар көтүен, төньяк котыпны күрергә кирәк. Шулчагында гына әлеге шигъриятнең якалары чишүле иркенлеген, кар сагышын, ярларны тутырып аккан гайрәтен аңлап буладыр.

Саха шигърияте самими, ихлас, монда артык бизәкләү, купшылык юк. Төньяк табигатенең кырыслыгы да хас аңа. Лирика эпик вакыйгалар белән үрелеп бара. Болар барысы да халык авыз иҗатыннан, үлемсез олонһолардан килә. Әлбәттә, саха шагыйрьләре дөнья әдәбиятының казанышларын да яратып куллана, ләкин ул казанышлар, сурәтләү чаралары, эверелеш кичереп, карларга төренеп, нәкъ сахача яңгырый башлый.

Тамырлар нык. Кырыс җирдә үскән каен монда артык зифа булмаска да мөмкин, ләкин тамырының һәр тармагы газиз туфрагына шундый

береккән, суырып кара! Билгә каганнар, Күлтәгиннәр, Чыңгызлар, бүгенге саха яшәешенең тәңреләре булып, янәшәдә яши, тормышның һәр өлкәсенә тәэсир итә. Алар ничек шигырьгә күчми калсын? Бигрәк тә яңа буынның иҗатында алар өскә чыга – милли горурлыкны тарихи мифларсыз уятып булмый, күрәсең.

Әлбәттә, саха да шәһәр тормышына күчкәч, берничә буыннан соң үзгәрә, күбесе башка мәдәният ятьмәсенә эләгә. Ничә гасырлар дәвамында аларны балык белән туендырган ятьмә түгел бу. Анда күңелне алдый торган башка ризыклар. Тозаклар да гомер-гомергә урман җәнлекләренә куелган капкын-фәлән түгел, бөтенләй башка тозак. Ләкин табигать үз баласының асылын саклап калырга теләп тартыша, карыша...

Басым зур, глобаль дөнья капшавычлары монда да корбан кармалый. «Без һәрвакыт сезгә карыйбыз, – диде түрәләрнең берсе, – татарлар югары мөнбәрдән үз сүзен әйтсә, без сезне сүз белән дә, эш белән дә һәрвакыт хупларга әзер. Аркадаш халыклар без!»[1] Әйе, сахада аркага пычак кадау гадәте юк. Тыл өчен борчылмаска була. Түрәнең сүзе хак: милли мәгарифне, милли мәдәниятне кысуга каршы Татарстан үз сүзен әйткәндә, безнең күрше тугандаш халыклар авыз йомып торганда, саха-якутлар һәрвакыт безнең белән бер сүздә булды.

Семен Даниловның туган авылыннан кузгалганда, караңгы төшкән иде инде. Чибәр саха кызлары милли киемнәрдә безне озатып калды. Кул болгыйлар, җырлыйлар. Үзәкләрне өзәрлек моң, безнең төрки күңелне назлый торган сүз агышы. Әйтелеше үзгә, әмма якын ул, яхшылап колак салсаң, аңлашыла да сыман. Хәер, аны аңлар өчен төрки телләрнең чагыштырма грамматикасын белү кирәк түгел, болай да аңлашыла – туганлык турында бу җыр, кардәшлек турында...

Еракта каралып урман күренде дә акрын гына офыкка кереп югалды. Ботакларына чүпрәк тасмалар бәйләнгән ялгыз агач, изгелеген сакларга теләпме, әллә аерылу сагышыннанмы, юл читендә моңсуланып йөзен каплады. Кичке караңгыда да аклыгын җуймаган кырда бер учак кабынды. Нәни генә учак югыйсә, ә үзе шушы караңгыда җир белән күкне тоташтырып тора.

Өмет бар әле, утыбыз сүнмәгән...

Автобуста сахача шигырьләр яңгырый. Без аларны күңелебезгә салып, Казанга алып кайтачакбыз. Саха учагының җылысы, ылыс исе, төньяк елгасының сулышы аларда.

[1] Кайбер галимнәрнең фаразлаулары буенча, борынгы саха-якутларның бабалары татарлар белән туган булганнар (Редакция искәрмәсе).

***И.Г. Закирова***

## ӘСТЕРХАН КӨНДӘЛЕГЕ

*Әстерханда минем булганын юк иде. Шулай да мин бу шәһәр турында үземне белә башлаганнан бирле ишетеп үстем. Дәү әтинең атасы Закир бабай Идел буенча Әстерханга товар–Кама Тамагының алма бакчаларында, үз бакчаларында үскән алма китергән. Икенчесе, дәү әниемнең атасы Гыйлметдин бабай, үзенең кибетләренә биредән кипкән балык, прессланган йөзем кебек товар алып кайткан. Димәк, Әстерхан белән аралар, ерак булуга карамастан, якын булган.*

*Бала чакта дәү әнием белән дәү әтием сөйләгән Әстерхан, аны бездә «Әчтерхан» диләр, миңа бөтен җирендә әчтерхан чикләвеге үсә торган урын булып тоела иде. Бөтен җирендә булмаса да, үсә икән биредә әчтерхан чикләвеге. Иң затлы бәйрәм ризыгы–пәхләвә да шул чикләвекне мул итеп салып әзерләнә.*

*Әстерхан белән бәйле икенче балачак хатирәсе–ул җәй көне Әчтерханнан кунаклар кайту. Алар кемгә генә кайтсалар да, бөтен авылның кунакларына әйләнәләр, өйдән өйгә чәйгә алыналар. Кич утырып Әстерхандагы тормышны, андагы бакчаларны сөйлиләр. Бер ел эчендә булган яңалыкларны барлыйлар. Кем килгән, кем киткәнне барлаудан башлана ул кич утырулар. Аннан сүз яңа өйләнешүчеләргә күчәләр. Кем йорт салган, кем башка чыккан? Аннан ничә бәти туганына, көтү чиратының бәясенә вакыт җитә. Шулай итеп, берьеллык Әстерхан тормышына да, авыл тормышына да күзәтү ясала. Берәр ай кунак булган Әстерхан кунаклары бер ел буе хат язышып, җәйгә кадәр көннәрне санап, сагынып яшәр өчен китеп бара.*

Татар халкының бер үзенчәлеге бар. Ул кайда гына яшәсә дә, тупланып, фәндә кабул ителгәнчә әйтсәк, компактлы булып яши. Әстерхан өлкәсендә дә татарлар компактлы булып, Приволжск һәм Нариманов районнарында урнашкан авылларда яшиләр. Октябрь революциясенә кадәр татарлар Әстерхан шәһәренең Тияк дигән урынында көн күргән. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының чираттагы экспедициясе, биредә яшәүче милләттәшләребезнең милли-мәдәни мирасын барлау һәм өйрәнү максаты белән, Әстерханга юл тотты.

«Әстерхан татарларының мәдәниятен үстерү һәм саклау ассоциациясе» җитәкчесе Ильмира Үтәлиева ярдәме белән алдан ук маршрут билгеләнгән иде. Ул халыкның йола иҗатын, фольклорын яхшы белгән, һәрьяктан мәгълүматлы информантларны безнең белән очрашуга барлап куйган.

Әстерханны, бу шәһәрдәге тарихи урыннарны яхшы белгән Наилә ханым Патеева күрсәтте. Лаеклы ялга чыкканчы нейрохирург булып эшләгән Наилә ханым Әстерхан татарларының тарихын өйрәнә, рухи мәдәниятен барлый, атаклы шәхесләр, тарихи урыннар турында мәгълүмат туплый. Наилә ханым Әстерхан шәһәренең татар халкы белән бәйле тарихи биналарын, татарлар яшәгән Тиякне, шәһәрнең күп санлы мәчетләрен күрсәтте, аларның һәрберсе белән бәйле тарихларны бәян итте.

Әстерханда татар халкының мәшһүр шәхесләре белән бәйле биналар да шактый икән. Мәсәлән, Сәгыйть Рәмиев чакыруы буенча 1911 елның язында Әстерханга Габдулла Тукай килә. Шагыйрьнең төп максаты үпкәләрен дәвалау булса да, ул Әстерхан татарларының рухи дөньясыннан читтә кала алмый. Тукай әдипләр һәм журналистлар, үзенең иҗатын, татар шигъриятен сөючеләр белән аралаша. Мәсәлән, Тияк бистәсендә Габдулла Тукай иҗатына багышланган кичә оештырыла. Шул чорның танылган табибы һәм җәмәгать эшлеклесе Нариман Нариманов белән очраша, табиб бөек шагыйрьгә кымыз белән дәваланырга киңәш бирә.



*Информантлар сөйләве буенча, Г. Тукай шушы йортта тукталган булган*

Әстерханда Г. Тукай башта «Люкс» кунакханәсендә туктала, соңрак үзенең дусты Сәгыйть Рәмиевтә кунак була, биредә чакта кымыз эчеп дәвалану өчен Калмык базары дигән авылда яши. Габдулла Тукай Әстерханда 29 апрельдән 6 июньгә кадәр була. Әстерхандагы дуслары аңа

кымызның файдасы булуын, шагыйрьнең яхшы якка үзгәрүен, тазарып китүен әйтәләр.

Сәгыйть Рәмиев Әстерханга 1910 елда килә, ул биредә «Идел» дигән газета редакциясенә эшкә чакырыла, соңрак башка нәшриятка күчә.

Наилә ханым әйтүенчә, Габдулла Тукай яшәгән йорт Татар-базардан ерак түгел урнашкан. Ике катлы кечкенә генә бу йорт хәзерге вакытта ярым җимерек хәлдә, шулай да анда берничә гаилә яши. Әлбәттә, бу хәлендә булган бинага «монда Г.Тукай тукталган» дигән язу элү мөмкин түгел.

Әстерханда татар халкының атаклы шагыйре Һади Такташ да булган. Тияк бистәсе халкы шунда урнашкан Шәрык клубында Һади Такташны сәхнәдән төшермичә шигырь тыңлаган, Такташ төн буе шигырь укыган.

Шушы кешеләрнең эзен саклаган, төннәр буе шигырь тыңлаган халык яшәгән Тияк бистәсе хәзерге вакытта татар бистәсе булудан туктаган, ул ярым җимерек, ярым ташландык хәлдә. Кайчандыр аның Әстерханның кайнап торган татар мәдәнияте үзәге булганлыгына ышануы да кыен. Ара-тирә очраган матур, төзек йортлар гына, биредә әле дә татар гаиләләре яшәвен искәртеп тора.

Тиякнең атаклы Яшел мәчете дә хәрабәләр хәлендә. Аның нинди булганын диварына эленгән рәсем генә искәртә.

Татар халкы кайда гына яшәвенә карамастан, матур, мул тормышта яшәргә омтыла. Әстерхан өлкәсендә дә татар авылларында халык бай һәм матур яши. Әлбәттә, бу – хезмәт сөю, зур тырышлык нәтиҗәсе. Йорт яны бакчасында помидор, тәмләткеч үләннәр үстерәләр. Помидорны рассадаларга чәчү көздән үк башлана. Аларны теплицаларга күчерәләр. Икенче өлешен соңрак чәчеп, ул үсентеләрне ачык җиргә утырталар. Һәр көн сугару, чүп утау, бутау – помидор өлгереп базарга чыкканчы күп хезмәт сорый. Помидорны биредә «мадур» диләр. Помидор үстерүнең девизы да бар – «Акша-бакша, товар-базар», диләр авыр хезмәтнең нәтиҗәсе турында. Ягъни, акча-бакча. «Ч» авазы күп сүзләрдә «ш» авазы белән алыштырыла.

Татар халкының хезмәт сөючәнлеге, тырышлыгы нәтиҗәсе буларак, Совет дәверендә күп кенә татарлар яшәгән колхозлар «миллионер колхоз» булган. Аларның шаулап торган чагы хәзер саргайган фоторәсемнәрдә генә сакланган.

Йорт яны бакчаларында шәфталу, өрек, әстерхан чикләвеге агачлары үсә. Аларны үстерү шактый хезмәт сорый. Салкынга түзмиләр, шуңа күрә һәр агачны кышка киендереп, камыш белән төреп бәйләп калдыралар икән. Иң әрсез агачлар – тут агачлары. Алар бөтен җирдә үсә. Сары яки кара төстәге җимешләре коелып утыра. Ишегалларында тут агачы

күләгәсенә сәкеләр куеп, ял итү урыннары булдырылган. Виноград та бөтен кешенең бакчасында үстерелә.

Авылларда йортлар зур, төрле төсләргә буялган, йорт кыйгачларына пар карлыгач бизәкләр төшерелгән. Ике катлы йортлар да еш очрый. Беренче каты җиргә иңдереп салынган. Бу эссе җәйләрдә эсседән котылу өчен шулай эшләнә икән. Ара-тирә камыштан үреп, өстән балчык белән сылап ясалган өйләр – мазанкалар да сакланган. Тормыш авыр чакта шул рәвешле йорт салырга ирешү күпләргә үз почмагын булдыру мөмкинлеге биргән. Аларны хәзер дә, җәйге өй буларак ясыйлар икән. Яшәешнең бу күренеше дә – камыштан өй-мазанкалар салу җырларда чагылган:

«Өйләр салдым камыштан,
Башым салдым сагыштан.
Моңлы туган, дип белмәгез,
Моңлы булдым язмыштан».

Камыш бөтен җирдә үсә. Кеше белән камыш арасында өзлексез көрәш бара. Бераз гына каралмый торса, бакчаларны камыш басып ала. Бер үсә башласа, аннан котылу җиңел түгел.

Халык кунакчыл, юмарт, ачык йөзле. Әстерхан татарларының кунакчыллыгы һәм алар әзерләгән ашлар турында аерым китап язарга мөмкиндер. Милли кухня камыр ризыкларына бай. Нугай бәлеш, пәхләвә, бадәмгөл, шикәргөл, катланчык, катланчык пәрәмәч, күз бүрәк, лаксалба, бавырсак һәрбер бәйрәм өстәленә куела. Һәрбер бәйрәмгә пылау әзерләнә. Пылау пешергәндә казан төбенә башта кабак тезәләр. Бу ризык шуның белән, без белгән пылаудан аерыла.

Экспедиция вакытында Әстерхан татарларының фольклорына караган бай материал тупланды. Шунысы күзгә ташлана: татар халкы кайда гына яшәсә дә, бер үк җырларны җырлый, сөйләмен бер үк мәкаль-әйтемнәр белән бизи, бер үк бәйрәмнәрдә күңел ача.

Кыска җырлар турында аерып әйтмичә булмый. Экспедиция вакытында 500гә якын кыска җыр тексты язып алынды. Дүрт юлдан торган һәм иң кечкенә күләмле жанрларга кертелә торган бу әсәрләрнең гаять зур миссиясе бар. Алар безнең кайда яшәвебезгә карамастан, бер халык булуыбызны исбатлап торалар. Бу кадерле мирас әби-бабайдан, ата-анадан балага күчә бара. Халык, тормышының иң әһәмиятле борылышларында, бәйрәмнәрендә туган телендә җырлый. Шул рәвешле үзенең тамырлары белән, туганнары белән бәйләнешне ныгыта. Шушы җырлар аша халык киләчәгенең бәхетле булуына тәэсир итәргә омтыла. Әби-бабалар җырлаган җырларны җырлау кешегә буыннар бәйләнешен тоярга да ярдәм итә. Алар аша еракта калган әби-бабаларыбызның

рухын тоябыз. Кеше телдән әйтеп бирә алмаган хисләрен җыр белән белдерә. Әстерхан өлкәсендә үткән экспедиция вакытында хат җырлары һәм истәлек дәфтәрләре җырлары да язып алынды. Җырларның кайберләрен «минем әниемнең җыры», «минем әбием шушы җырны гел җырлый иде», дип җырлап күрсәттеләр. Бу текстлар Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондында саклана. «Сак-Сок» бәетенең вариантларын, халыкка яхшы таныш мөнәҗәтләрне, башка бәетләрне дә бу мәкаләгә кертмичә, Әстерханда яшәүче татарларның тарихи риваятьләренә, легендаларга, үзенчәлекле фольклорына, йолаларына тукталып, сезне алар белән таныштырып китәргә телибез.

## Идел Буе (Приволжский) районы 12.06.2013

### ***Киләче авылы***

Экспедиция эшчәнлеген Идел буе (Приволжский) районында урнашкан Киләче авылында башлады. Киләче авылында 900 хуҗалык, 16 милләткә караган 4000гә якын кеше яши. Авыл тарихы Екатерина II заманында башлана. Халык телендә сакланган истәлекләр буенча, авылга нигез салучылар Казачий бугор ягындагы Мошаик авылыннан күчеп килгән. Риваятьләр авылга нигез салынуны түбәндәгечә бәян итәләр: Әстерхан морзасы Абыз-морза Ямгурчеев Екатерина II, ягъни әби патша вакытында Бөтенроссия дворяннары утырышына делегат итеп җибәрелә. Кире Мошаикка кайткач, крестьяннар нәрсә алып кайтуын сорыйлар. Ирекме яки коллыкмы? Абыз-Морза: «Императрица Екатерина II сезнең барыгызны да миңа крепостнойлар итеп бирде»,–ди. Бу сүзләрне ишеткән крестьяннар Абыз-Морзаны тотып алып Байган ильмененә батыралар. Шуннан соң җәзадан куркып күчеп китәләр һәм хәзерге Киләче авылына килеп нигез салалар.

Киләче авылында беренче информантыбыз ***Ядгирова Римма Хәмит кызы*** (1939 елгы), хәзерге вакытта лаеклы ялда. Римма апа җырларга ярата. Элек авылда «Яшьлек» дигән халык ансамбле булган. Ул шушы ансамбльдә җырлаган. Татар халык җырларын да, татар композиторларының популяр җырларын да яратып башкара. Римма апа безгә дә «Үтте дә китте яшьлегем», «Олы юлның тузаны» һәм башка җырларны башкарды. Римма ападан шактый гына риваятьләр, сөйләкләр, мифологик затлар турында хикәятләр, йолалар турында материал, кыска җырлар язып алдык.

***Киләче авылы.*** *Баллы буена бер кеше килеп урнашкан да, халыкны «Киләче, киләче», дип, ягъни «килегез әле», дип Баллы буена чакырган. Шуннан авылны Киләче дип атаганннар.*

***Баллы елгасына** мал төягән баржалар күп килгән. Бер бал төяп килгән баржа крушениегә эләгеп, бал суга тарала. Шуннан бу елга суы баллы булып, елганы да Баллы дип атый башлыйлар. Баллыны ахырда Балду, аннары Балды дип атый башлыйлар.*

*Элек авылга Баллы елгасы буйлап иртә-кич пароход килә иде, автобус урынына. Элек күпер юк иде.*

***Су анасы** су килгән, су кайткан вакытта күренә. Төнлә чәчен озын итеп чыгарып, чәчен тарарга утыра. Балаларга: «Барма, Су анасы алыр», – диләр. Су анасы өйлә вакытында, акшам вакытында чәчен тарый, диләр.*

*Яңа өй салып күченгәндә үзең белән **өй иясен** дә чакырырга кирәк. «Әйдә-әйдә безнең белән бергә бар», – диләр, өй иясенә яңа өйгә күченгән вакытта. Төп йорттан башка чыкканда өй иясенең баласын чакырасы.*

***Әүлиялар** күп. Алар – Аллаһның әмере белән килгән кешеләр. Алар күзгә күренми торган кешеләр.*

*Совет заманында **бәйрәмнәр** бик күңелле уза иде. Машиналарга төялеп йөри идек. Иң зур бәйрәмнәр 9 май – Җиңү бәйрәме һәм 7 ноябрь – Октябрь бәйрәме. Октябрь бәйрәмендә халык мәйданга чыга, төрле уеннар уйный, ярышларда катнаша. Бу бәйрәмне мәйдан дип атыйлар.*

***Кайтым** булган әниләрнең яшь вакытында. Әниләр-каенаналар далага чыкканнар. Мал суеп, су-елга буенда бөек казаннарда пешергәннәр. Бөтен кешене сыйлаганнар. Ул – яңгыр булмаса, корт басса, сәдака бирү, кешеләрне, ятимнәрне сөендерү, илдән дога алу йоласы. Ул бәйрәмнәрне **Кайтым** дип әйтәләр. Ураза беткәч тә, корбаннан соң да уздырыла. Чәчү беткәннән соң да, «кайтым итик, сәдака бирик», дип сөйләшәләр.*

*Элекке аулак өйләрне безнең заманда **вечер** дип атыйлар иде. Егетләр армиягә киткәндә, авылга берәр кунак кыз яки егет килсә, вечер уйный идек.*

Кайвакыт авыл халкы, берәр сүзгә оста, мәгълүматлы әби яки бабайның күптән түгел генә вафат булуын искә төшереп: «менә ул исән булса!», – дип уфтанып куя. Киләче авылында шундый Зөлхәбирә әби булган, ул гомере буе халык иҗатына битараф булмаган, кешедән ишеткән һәм үзе башкарган җырларны, бәет-мөнәҗәтләрне дәфтәренә теркәп барган. Зөлхәбирә әби үзе дә бәетләр, шигырьләр иҗат иткән. Зөлхәбирә әбинең дәфтәрендә «Сак-Сок» бәетенең бер варианты да теркәлгән. «Сак-Сок» бәете – татар халкының иң мәгълүм бәете, халык, кайда гына яшәсә дә, аны яхшы белә. Ул безнең яшәү урыны кайда гына булуга карамастан, бер халык булуыбызны исбатлап тора. Икенче яктан, әлеге бәет татар халкы өчен символик мәгънәгә дә ия. Эш эзләп, чукындырылудан качып,

ачлыктан качып туган җирләрен калдырып дөнья буйлап таралган халык озак еллар туган җирен, туганнарын сагынып яшәгән. Бу сагыну буыннан-буынга күчеп, татарда аны аңлаткан сүз дә туган, «җирсү», диләр аны. Сак-Сок кебек язмыш тарафыннан аерылган, бүлгәләнгән, әмма бер булуын онытмаган, җанында җирсүен йөрткән халыкның бәете, аның рухи халәтенә аваздаш бәет ул «Сак-Сок».

Без ***Абдуллаева Зөлхәбирә Әүбәкер кызының*** (1929–2012) дәфтәреннән шактый гына материаллар күчереп алдык.

***Фәрештәләр турында***. *Җәбраил – Алламның әмер вә тыюларын пәйгамбәрләргә китерә торган фәрештә. Аллаһ белән пәйгамбәр арасындагы илче. Микаил – табигать эшләре белән җитәкчелек итә итә торган фәрештә. Яңгыр, җил, һәм табигатьтәге ризык эшләре белән җитәкчелек итә торган вазифалы фәрештә.*

Зөлхәбирә әбинең дәфтәрендә күп кенә мөнәҗәтләр, бәетләр теркәлгән. Бу дәфтәрдә «Егет бәете» дигән текст та бар. Без аны экспедиция вакытында тагын берничә тапкыр «Гомәр бәете» исеме белән язып алдык.

**Киләче авылында** урнашкан рус совет шагыйре Михаил Кузьмич Луконин музее белән (1948 елгы, «Яшьлек» ансамбле баянчысы) таныштык. Киләче авылына шагыйрь Муса Җәлилнең килүе турындагы истәлекләр искә төшерелде.

***Муса Җәлил турында***. *1933 елда Киләче авылына «Ялкын» журналы редакторы Шакир Мөслимович Фәтхуллин белән атаклы шагыйрь Муса Җәлил килә. Ул вакытта колхоз рәисе Ибраһим Мәхмүдов була. Мәхмүдовлар өендә шагыйрь йоклаган кровать озак еллар шул урында тора. Хуҗалар анда бер кешене дә утыртмый.*

*Муса Җәлил авылда 11 көн яши, Киләче халкына уңыш җыярга булыша. Шагыйрь «Җиһан» поэмасын Киләче авылында булганнан соң яза. Поэмада Киләче авылының уңыш җыйган вакыты тасвирлана.*

*Муса Җәлил Киләчедә булып киткәннән соң, авылда алган тәэсирләр «Күк юрга», «Колхозчы кыз», «Балыкчы кыз җыры» һәм башка әсәрләрендә чагылыш таба.*

***Алтын кабак***. *Көзен Октябрь бәйрәмендә мәйданда төрле уеннар оештырыла иде. Ирләр «Алтын кабак» атышалар. Баганага ат кылына тәңкә асыла. Шул тәңкәгә аталар. Элек ул алтын тәңкә булган. Мин ул бәйрәмнең баштагы исеме «Алтынга бак» булырга тиеш, дип уйлыйм.*

***Әхмәтова Люция Әбдрәшит кызы*** *(1960 елгы), җирле үзидарә башлыгы, авыл тарихына һәм фольклорга караган кызыклы материаллар белән уртаклашты:*

***Киләче авылы Баллы, яки Болды суы*** *буенда урнашкан. Киләче авылы янында Каспий диңгезенә бара торган бал тутырган мичкәләр төягән*

*баржа баткан. Авылда күчмәләр яшәгән. Узган ел авылга 225 ел булды (2012дә). Бирегә беренче күчеп килүчеләр Казачий Бугор авылыннан була.*

*Бал түягән мичкәләр батканны күрүчеләр, башкаларны «монда килегез, килегез», «киләче», дип чакырганнар.*

*Киләче авылы өч авылдан торган – Аргы, Бирге, Бөгәҗел, ягъни Урта авыл. Авылда 3 мәчет була.*

***Әүлиялар**. Безнең Бабай түбә дигән җиребез бар. Авыл түбәсендә дүрт әүлия җирләнгән – Нургали ата, Гайшә хан, Фатима әүлия. Берсенең исемен белмим. Алар өстендә өй кебек эшләнгән. Өстенә унбер ак байрак куелган. Ул зиратның уртасында урнашкан. Аларны Нәсимә апа ел саен яңартып тора. Гайшә хан, Фатима әүлия – караучы яки дәвалаучы әүлиялар булган.*

***Су анасы**. Су килгәндә һәм су киткәндә су анасы кеше ала. Су туктаганда гына су керегә ярый.*

*10 августтан соң су коеныргa ярамый. Илья суга сиеп китә. Су гөлләнә. Бака юрган ябына. 10 августтан соң судан төрле чирләр ияртергә мөмкин.*

**Җәмәл авылында** 600 тирәсе хуҗалык бар. Авыл исеменең килеп чыгуын гарәп теленнән кергән, авыл халкы дөя дигән сүздән дип тә, гүзәл, матур дигән сүздән дип тә аңлата. Авыл халкының сөйләме әдәби телгә якын. Урта диалект үзенчәлекләре сизелә. Күпчелек халкы 1920-нче елгы ачлыктан качып, Казан ягыннан күчеп килгәннәрдән. Халык сөйләгән истәлекләргә караганда, авылга Кавказ якларыннан да, монгол халыклары да күчеп килгән. Төрле халыклар кушылган. Җирле үзидарә башлыгы Рамазан Мөхәрәмов – милли рухлы кеше, ул авылда гына түгел, район, өлкә масштабында үткәрелгән милли чараларда да башлап йөрүчеләрнең берсе.

Җырчы ***Идиятуллина Румия Усман кызы*** да Җәмәл авылында яши, аның концертлары еш була. Ул халык җырларын башкара, әнисеннән өйрәнгән бәет-мөнәҗәтләрне әйбәт белә. Әтисенең әкиятләр күп белүен, балаларга әкиятләр сөйләвен әйтте. Румия Усман кызы кыска җырлар да, сюжетлы җырлар да, бәетләр дә яздырды. «Картка бирелгән кыз бәете» – татар халкында шактый мәгълүм бәетләр рәтеннән.

***Картка бирелгән кыз бәете***

Татар аулында урам гизгәндә
Очырадым татар туена.
Туй туйлаганда,кыз елаганда
Утырдым да калдым бер уйга.
Ишек ачылды, халык тын калды.
Никахка муллалар керделәр.

Аңладым шунда кызның елавын–
Бичараны картка бирәләр.
Әнкәсенә әйтә шушы кыз бала:
«Нигә мине картка бирәсез?
Мин–бичараны, яшь кыз баланы
Карт бабайга әрәм итәсез».
«Шуңа бирәмен, кыз балакаем,
Акчасы күп ул карт бабайның.
Акчасын санап, сакалын тарап,
Бабай белән гомер итәрсең.
Яхшы атларда, ефәк фаэтонда
Бабай белән кодрып йөрерсең».
«Бармыйм, әнкәем, бармыйм, бәгырем,
Барасым килмидер бабайга.
Әйдә, бир мине, газиз әнкәем,
Теләнеп йөрегән малайга».
Кызның янына җиңгәсе керә:
«Тукта бер сүз әйтәем.
Син–бичараны, яшь кыз баланы
Сөйгәненә алып китәем.
Тиз-тиз киенеп, тизрәк җыенып,
Әйберләрен төенгә бәйләп,
Эзләмә юкка, калсын карт бабай,
Шул аңарга минем бүләгем».
Кызны алырга карт бабай килә,
Кыз урынында, эзләмә юкка.
«Ах, сез аларны, качып киткәннәр.
Акча бирүем чыкты юкка.
Алтын шикелле малларымны мин
Барысын да сатып бетердем.
Көмеш шикелле сакалымны мин
Барысын да йолкып бетердем».

***Гомәрова Мәйсәрә Хәким кызының*** (1936 елгы) җиде буыны да шушы авылдан. Ул үзе–күп талантларга ия кеше. Шигырьләр дә яза, ата-бабалардан калган мәдәни һәм рухи мирасны барлап, өендә этнография музее булдырган. Мәйсәрә апа үзенең йорт-музее белән таныштырган арада фольклор буенча да шактый гына материал яздырып өлгерде.

***Җыен агасы***. *Туй булсынмы, аулак өйдәме, алып баручы була, тамада кебек, тамаданы башкача да әйтәләр иде. «Җыен агасы», диләр. Күңел ачканда «Җыен агасына дүрт кыз», дип әйтәләр. Җыен агасы чыгып*

*уртага баса. Ул яулыклар әзерләп килә. Дүрт кызга икешәр яулык бирә. Дүрт кыз чыгып уртага дүрт яктан баса. Җыен агасы бии. Аның бии торган үзенең көе була. Бөтен кеше бер көйгә биеми. Уйнаучы белә кемнең нинди көйгә биегәнен. Ул шул көйне уйный. Дүрт кыз шул көйгә такмак әйтәләр. Такмак әйтеп, чәпәнәй кагып торалар. Кул чабуны бездә «чәпәнәй кагу», диләр.*

«Ике кул яулыгыңа,
Башыңның саулыгына», – дип берсе әйтә.
Икенчесе әйтә:
«Бас идәннең уртасына,
Дошманнан куркасыңмы?»

*Шулай җыен агасына көч бирәләр. Ул аның саен дәртләнеп бии. Менә шундый такмаклар да бар:*

«Әйлән, түгәрәк,
Син булырсың күбәләк.
Кульяулыгың читенә,
Гөлләр үссен битенә».

*Туйда һәр кешенең якын кешесе була. Шул җыен агасы була инде. Дүрт кыз җыен агасы белән уртада бии. Аннары ул кызлар кулларындагы яулыкларны биреп башкаларны уртага чакыралар. Биергә чакырганнан соң, ике яулык бирәләр. Чакырылмаган кеше үзлегеннән чыгып биеми. Уртада һәрвакыт биш кеше була.*

**Колакау авылында** информантларыбыз ***Шамгунова Ажмангул Садыйк кызы*** (1930 елгы), ***Гобәйдуллина Гөлсинә Гаяз кызы*** (1954 елгы) һәм ***Шабанова Гөлмира Әдһәм кызы*** (1968 елгы) йола фольклоры, туй йолалары турында мәгълүмат бирде.

***Кызны ярәшәләр***. *Киләләр яучылар. Мәсәлән, әнисе, ике сестрасы. Китерәләр бүләк: конфет, шоколад бер подноста. Материаллар – әнисенә, әтисенә – күлмәк, кызга – алтын йөзек. Шуннан ярәшәләр, бу ярәшү була.*

***Әбиләр туе***. *Бу туйга хатын-кызлар гына килә. Кызга киемнәр китерәләр. Бу «Тугыз» була. «Тугыз» китерәләр бүләккә. Алтын, киемнәр китерәләр, зур поднос татлылар белән: шоколад, конфет һ.б. Зур бантик бәйлиләр подносны җыеп бәйләп.*

***Сөт хакы***. *Сөт хакы – бер куй, 16 килограмм дөге. 5–10 мең акча. Егетнең туганнары кызның ата-анасына бирәләр.*

*Әбиләр туена пылау пешерәләр. Аракысыз уза. Пәхләвә белән чәй эчәләр.*

*Саз уйныйлар (гармун), кавал сугалар (бубен сугалар). Сазчылар, кавалчылар килә. Уйныйлар, бииләр.*

*Туйга килгән һәр кешегә бүләк бирәләр. Материал, тастымал, сөлге бирәләр.*

*Кодагыйлар килә. Егет яктан, кыз биткә бүләкләр китерә. Кыз бит тә бүләк бирә.*

*Бер мамай (муллабикә) дога укый. Аннары теләк телиләр. Бәхетле булсын, каенана-каенатасының сүзен тыңласын, диләр.*

***Кияү сый–яшьләрнең кичке туе***

*Кияү сыйда мәҗлесне кызның әти-әнисе башлап җибәрә. Кичен кияү сый мәҗлесе уза. Кияүнең туганнары, дуслары, егетләр авыл читендә машиналардан төшеп, җәяү киләләр. Алар кавыллар кагып, саз уйнап, җырлап-биеп киләләр. Кияү туй шатерына кермәскә тырыша, киреләнә, ялындыра. Аны күтәреп алып керәләр.*

***Кияү-аракы**. Туй уртасында «кияү-аракы» алалар. Ул аракыны башта өстәл астына яшерәләр. Кыз бит сорый. Кыз ягы җырлый-бии, аларга җырлаган-биегән өчен аракы бүләк итәләр. 12 бутылка. Аннары ул 12 шешәне өстәлгә куялар. Алар кызыл бантиклар белән бизәлгән. Бу аракыны эчеп бетерәләр. Ул ленталарны һәркем алырга тырыша. Үз балаларына да шундый туй насыйп булсын, дип, һәркем тизрәк чишеп алырга тырыша.*

*Аннары бер атнадан кызга придан бирелә, йорт җиһазлары–диван, башкалар.*

*Регистрациядән соң шатерда егет ягында туй була. Башта «Бит күрен». Кыз шатерда, әбиләр туенда һәр мамайның кулын алып чыга. Килен, алдында егетнең җиңгәсе, артында кызның җиңгәсе. Мамайлар: «Хәерле булсын!»–диләр. Шунда акча чәчәләр. Өстәлдә тугызны күрсәтәләр. Җыелган халык акчаны җыя. Йөргән балалар җыя.*

Исеме хушавазларга кергән **Ярлы Түбә** авылында 980 хуҗалык, 3500дән артык кеше яши. Төп халкы–татарлар. Руслар, казакълар, нугайлар да яши.

Авыл халкының төп шөгыле–яшелчәчелек. Авыл исемен Яр Түбә дигән сүздән дип аңлаттылар. Яр өстендә, тау өстендә утырган авыл булганга шулай аталган. Авыл янында Царев елгасы ага. Моннан Петр I су буйлап Каспийга үткән. Царев елгасын татарча Ярлы Түбә ягасы дип атаганнар. Ярлы Түбә авылы апалары, бергә җыелып килеп, китапханәдә сөйләшеп утырдык. Җырлап-биеп күрсәттеләр, төрле ышанулар, ырымнар белән дә таныштык.

***Ышанулар**. Аяк тырнагы белән кул тырнагын бер көндә алу ярамый. Яхшылык белән яманлык бергә килә, диләр иде.*

*Вторник көнне кер юарга, су түгәргә ярамый. Кабереңә су коярлар, теге дөньяда.*

*Җомга көн кер юарга ярамый. Әгәр бай булып, байлыгыңны кая куяргa белмәсәң, кульяулыгыңны булса да ю, диләр.*

*Вторник көнне су коярга, кер юарга ярамый. Ул көнне аккан су, кан булып агар, ди. Ул пәйгамбәрнең туган көне икән.*

*Тырнакны җомга көн төштән соң кисәргә ярый. Ял көннәре ярамый.*

***Бала янына** Коръән, кайчы, пычак саласың, җен-пәри килмәсен, дип.*

***Өй иясе**. Яңа йорт салгач, яңа өйгә өй иясен дә күчерәләр. «Мин китәм яңа йортка, әйдә бергә киттек!»–дип, күсәнкәгә утыртып алып китәләр.*

***Шайтан**. Бар ул. Ул–кызың, улың булып кычкыра, әгәр чыксаң, алыштыра икән. Тыңлап торырга, икенче, өченче тапкыр кычкырганын көтәргә.*

***Туй йолалары**. Бездә туйлар берничә этаптан тора. «Кияү сый»–кыз ягында, «Тугыз туй» егет ягында уза. «Бит күрен» дә кыз күрешә.*

*Никахта кыз аерым утыра. Аның чәчен тарыйлар. Егет никахка яулык, тарак, пыяла (көзге) китерә. Чәчен дуслары тарый.*

*Егет кызга тугыз бирә.*

*Чатырда бер очыннан икенчесенә җеп эләләр. Анда бүләкләр эленә. Егет 16 кило дөге, бер куй, конфет һәм башка бүләкләр, кызның әти-әнисенә бүләк бирә. 12 шешә «Кияү аракысы» китерәләр.*

*Кияү чатырга керми, аяк терәп каршы тора. Аны күтәреп кертәләр.*

*Кияүгә туйда «кием» бүләк бирелә.*

*Кияүне ашаткач-сыйлагач, инде безнең сый бетте, хәзер кияү сыен күрик, диләр. Кияү ягы кыз ягына җәза бирә–җырларга-биергә куша. Шуннан аракы бирәләр.*

*Туй өчен алдан ук балкуас куялар.*

**Кызан авылы** беренче тапкыр тарихи документларда 1614 елда искә алына. Элек авылда дүрт мәхәллә булган. Хәзерге вакытта 2500 тирәсе халык яши. Авыл тирәсендә археологик һәйкәлләр шактый. Мансур ата һәм Куганны әүлиялар күмелгән урыннар халык тарафыннан олылана.

***Исхакова Баузия Нәҗметдин кызы*** (1928 елгы), бик күп җырлар белә, җырларны кая барса, кайда ишетсә, шунда отып ала, өйрәнә. Казаннан килгән пластинкалардан да бик күп җырлар өйрәнгән. Шушы авылның җырларын да, нугай халык җырларын да башкара. Гомер буе сәхнәдән дә җырлаган, җыр конкурсларында катнашкан. «Сакмар буе», «Урман кызы» һәм башка җырларны яратып җырлый. Бәетләр-мөнәҗәтләр дә белә. Буш вакытында чигү чигә.

Календарь йолалардан бу якта иң популяр бәйрәм төрки һәм фарсы халыкларының Яңа елны каршы алу йоласы–Нәүрүз. Ул язгы көн белән төн тигезләшкән көнне 21 мартта бәйрәм ителә. Бу көннән Яңа ел

башлана. Татар халкында Нәүрүз бәйрәмен уздыру XX йөз башларына кадәр дәвам итә. Бу көнне яшьләр, шәкертләр, авыл буенча һәр өйгә кереп, «Нәүрүз әйтеп» йөргәннәр. Нәүрүз такмакларында өй хуҗаларына яхшы теләкләр, бәхет-шатлык, уңышлар теләгәннәр, шуның өчен хуҗалар нәүрүзчеләргә бүләк биргән. Нәүрүзнең татар халкында икенче исеме Әмәл яки Амил.

***Амил бәйрәме***. *Һәрбер авылда да амил булган. Чит авыллардан арбага утырып, тамакларын төяп килә торган булганнар. Кунакларга кабак бүрәк, куз бүрәк пешергәннәр. Үзләре дә пешереп алып килгәннәр.*

***Нәүрүз яки Амил бәйрәме котлаулары***

*1.* Яз килде яппан,
Тегелде кара чапан.
Инде килде яз заман.
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.
*2.* Кара тавык какылдап,
Патлык теләп торады.
Яшь чәүкәләр шакылдап,
Яулык сорап торады.
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.
*3.* Тор-тор, анай, тор, анай,
Төлке туның ки, анай.
Безгә яулык бир, анай,
Шабдин-шабдин,
Азан-азан,
Инде килде Мүбәрәк.

*Элек* ***Кызан авыл*** *дүрт өлештән торган. Дүрт мәхәллә. Һәрберсенең исеме булган. Дүрт мәчет булган. Мин өчесен хәтерлим әле. Һәрбер мәхәлләнең байлары үзләре салдырган мәчетне. Курнап, Базар авыл мәчете, Кинәгәч мәчете. Хуҗа авыл мәчетен хәтерләмим. Ураза вакытында балалар мәчеттән «Авыз ачылды», дип йөгереп өйләренә кайтып әйтәләр иде.*

Нугай тарихчысы ***Джуманов Равил Үтәмөхәммәд улы*** (1937 елгы), халык тарихын яхшы белә, халык иҗаты белән кызыксына. Үзе дә кешеләрдән фольклор әсәрләре җыйган. Равил абый ике хушаваз тексты, легенда-риваятьләр яздырды.

***Сөннәт туй***

Әй, әссаламәгаләйкүм, аманмысыз, муллатай,
Өндәү чакырып туй итепсез атраптан калдырмай.
Ай, күп халык килеп те, атраптан калдырмай.
Җигеп килгән арбасын әүләгә сыйдыралмай.
Уртада бер зат тора, елтыраган алтындай.
Аны барып карасам, ул да икән бажаклай.
Капкадан чыгып китте, тратайка тырылдай.
Астында тимер күчәр, таз тимердәй зыңгырдай.
Ай да хөрмәт итепсез, рәхмәт яусын, муллатай.
Ай да хөрмәт итепсез, рәхмәт яусын, муллатай!

* * *

Айтип-айтип юралар, куймыйсыз мине кыстай.
Мин түгелмен Фәхретдин, янәшәдә Сыдык бай.
Әмма дуслар хакы өчен, кыйммәтен җиргә куймай.
Бер-ике авыз әйтәем, шул булып утыр тыннай,
Бер-ике авыз әйтәем, шул булып утыр тыннай.
Ярты Түбә, Җәмиле җайлы икән кыдырмага,
Ярты Түбә, Җәмиле җайлы икән кыдырмага.
Кызан, Каргалык, Майлы Күл җыелып килер Кыра Калага.
Сәмигъ авыл, Колакау мисле утырган батага,
Киләчеләр кире халык керешмәсен арага.
Каңга дигән каңгыз калк, кыңгырып китсен далага.
Айрин әйт тә, берин әйт, аспалы күпер, агым су
Җан-Тияктән сәдака.

Бу хушавазда ыру-кабилә, авыллар арасындагы туганлык мөнәсәбәтләре сизелә. Ярты Түбә, Җәмәле кунакка йөрешү, күңел ачу өчен яхшы, Кызан, Каргалык, Майлы Күл бергә җыелып калага килә, алар Татар-базарга товар китерә. Сәмигъ авыл Колакау ватагага (балык тота торган судно) утырган кебек. Киләчеләр кире халык – нигәдер, аларны өнәп бетермиләр. Анда бик күп милләт яши. Канга күчмәчелекне озак саклаган. Тияк – Царев, Әстерхан шәһәрендә татарлар яшәгән җир. Соңгы татар ханнары шунда яши.

***Кызана (легенда)***

*Шушы җирдә күчеп йөргән татарлардамы, нугайлардамы бер кыз булган. Үзе ыспае булган. Шул кызны егете алдаган. Ул йөкле булган. Ул вакытта шәригать буенча, халык гадәте буенча андый хатын-кызларны куалар ырудан. Шул мескен, баласын табып, түбәгә килгән. Шунда*

*землянка казып, шунда яшәгән. Шунда күчеп йөрергә маллары булмаган ярлы халык килеп урнашкан. Алар кызны кыз ана дип атаганнар. Шушы халыктан авыл башланып киткән.*

Кызан мәктәбенең тарих укытучысы ***Мусаев Әмир Дамир улы*** (1971 елгы), иң яшь информантларыбызның берсе. Ул Кызан авылы турында тарихи мәгълүматлар һәм риваять, легендалар белән таныштырды..

***Кызан авыл***

*Авылның исеме – Кызан авыл. Документлар буенча, авылның исеме бу авылга нигез салган сугышчы Йыла Кизан исеменнән килеп чыккан, дип санала. Кизан ыру-кабилә атамасы булырга мөмкин. Мангышлакта да Кизан атамасы торак пунктка бирелүе мәгълүм. Төркмәннәрдә Гизан атамасы бар.*

*Йорт татарларында торак җирләрне нигез салучыларның исеме белән бәйләү еш очрый. Сәмигъ авылга нигезне баһадир Сәмигъ Арслан сала. Күрше Яксатово авылына Яксат исемле кеше нигез сала. Җәмәле авылының килеп чыгуы Җума яки Җуман исеме белән бәйле. Җума яки Җуман табунный голова була. Киләнчи авылына нигез салучы да – Киләш исемле табунный голова. Шәһәр янында Мышаек бар, аны татарча Каза-выл, диләр. Аның исеме Казыйдан – мөселман башлыгыннан килеп чыккан.*

*Авыл тарихы белән бәйле легенда бар. Хәзер инде мәрхүм булган Бикмөхәммәт Исаев исемле кеше миңа ул легенданы сөйләгән иде.*

***Кызана (легенда)***. *Кызана – кыз ана, кияүгә чыкмый бала тапкан кыз.*

*Урта хәлле генә бер гаиләдә бик чибәр кыз үскән. Исеме Өммегөлсем була. Өммегөлсемнең яратып йөргән егете дә була. Кызга бер бай малае да күз төшереп йөри. Кызның ата-анасы бай җибәргән яучыларга кыз-ларын бирергә ризалык бирә. Әмма кыз бу язмыш белән килешергә теләми. Ул бу җаны теләмәгән никахтан ничек котылып буласын озак уйлый. Аннары үзе турында, имеш, авырлы икән, дигән сүз тарата. Бай кода-лар, бу сүз килеп ирешүгә, кыздан баш тарталар. Кемгә авырлы кәләш кирәк булсын.*

*Ул заманда, кануннар буенча, никахсыз балага узган кызларга кара-та ике төрле чара кулланырга мөмкин булган. Беренчесе – ташлар белән бәреп үтерү, икенчесе – илдән-ырудан куу. Бу очракта икенче юлны сай-лыйлар.*

*Аны шәһәрдән куалар. Ул килеп шушы җирләрдә урнаша. Ашан тау түбәгә, авылга беренче нигез салынган җиргә килеп урнаша. Бу урынны Кызана дип атый башлыйлар. Күпмедер вакыттан бу сүз кыскарып Кы-зан булып китә.*

**Майлы Күл** авылының исеме җиренең майлы кебек әйбәт булуыннан килеп чыккан, дип аңлаттылар информантларыбыз. Җирләребез майлы

кебек әйбәт, кара туфрак. Русча исеме «Яхшы авыл» дигән сүздән, яхшы авыл дигәннәр, шуннан Яксатово килеп чыккан. Биредә соңгы 5–6 елда яңа бәйрәм – Авыл бәйрәме уздырыла башлаган. Ул уңыш җыеп алынгач, октябрь башларында, айның беренче атнасында уздырыла. Бәйрәмгә бөтен авыл халкы җыела, кунаклар кайта, концертлар килә, төрле ярышлар уздырыла. «Алтын кабак», ат чабышы, йомырка кабып йөгерү кебек ярышлар бәйрәмнең бизәгенә әйләнгән. Көрәштә җиңүчегә куй бирәләр.

Майлы Күл авылындагы информантларыбыз ***Айбәкерова Халидә Касим кызы*** (1941 елгы), ***Абдулгазизова Фәридә Абдулгалим кызы*** (1941 елгы) һәм ***Мохтарова Фәридә Ибраһим кызы*** (1948 елгы) яшь вакытларында өчесе дә үз авылларының җыр ансамблендә җырлаган. Конкурсларда катнашканнар.

***Ураза гаете, Корбан гаете***. *Ирләр гаеткә мәчеткә баралар. Алар мәчеттән туры зиратка бара. Анда дога укып кайталар. Алар кайткач, бәйрәм башлана. Аннары туганнарга, күршеләргә кыдырып йөриләр. «Кул алырга» керәләр, «кул алып чыгалар». Олы кешеләрнең кулын алып чыгалар, өлкәннәр белән күрешәләр. Күчтәнәчләр алып керәләр. Гадәттә, өйдән пешкән әйберләр алып керәләр.*

*Авыл балалары берәм-берәм, икәү-өчәү дә өйдән-өйгә кереп: «Бәйрәм хәерле булсын!» – дип гает белән котлыйлар. «Кул алалар». Чәй эчерәбез аларга. Аларга күчтәнәчләр әзерләп куябыз, сәдака бирәбез.*

*Корбан гаетендә гаеттән соң зиратка баралар ирләр. Кайткач, куй суялар. Сыер булса, биш яки җиде кеше пайга керәләр. Аннары җиде өйгә тараталар. Ярлыракларга, ир баласы булмаганнарга, ялгызларга тараталар.*

*Кадер кичәсендә мәчеткә баралар.*

***Әүлия түбәсе***. *Икенче төрле «Кыдыр бабай түбәсе» дип тә әйтәләр. Анда Кыдыр бабайның кабере бар. Ул үләчәктә арбага утырган да күрше авылларга чыгып киткән. Бу түбәдә үлгән.*

*Хәзерге вакытта ул түбәдә өй салдылар. Анда илтеп сәдакалар салалар. Бездә сәдака суялар. Халык акча җыеп, мәчет әүләсында яки Кыдыр бабай әүләсына мал алалар. Сыер яки куйларны суеп, җиде казан асып, аш-шурпа пешерәләр. Килмәгәннәргә дә өлеш җибәрәләр. Коръән укыйлар. Сәдака салалар.*

*Ул түбәдә ак байраклар куелган. Ак яулыклар бәйлиләр. Без юлга чыкканда анда барабыз – юлга чыкканда, ният салып китәләр. Кабер түгәрәгендә җиде тапкыр әйләнеп чыгабыз, теләк теләү бу.*

*Кыдыру, кыдырып китү – сәяхәт, кунакка бару, ялга китү, имин йөреп кайту, кунакка барганда, ерак юлга чыкканда теләк теләү.*

*Кыдыр бабай догалары авылны бәла-казалардан саклый. Әстерханда әүлиялар күп, алар бу җирне саклыйлар. Олы бәла-казалар булмый бездә.*

***Максудова Нурия Гәрәй кызы*** (1947 елгы) лаеклы ялга чыкканчы укытучы булып эшләгән. Нурия апа халык тарихы белән кызыксына. Үзләренең ыру тарихын да каенанасыннан, туганнарыннан сорашып өйрәнгән.

***Хуҗалар ыруы***. *Безнең ыруыбыз–хуҗалар ыруы. Бервакыт ак тәтәм миңа әйтә: «Без торганбыз хуҗалар әүләсында. Әтиемнең әүләсы. Каргалыктан булган әтием тумышы белән. Менә безнең карт бабабыз булган, ди. Ул күптән-күптән килгән. Аны беренче булып күмгәннәр, ди зиратка. Ул зират хәзер кала эчендә калды. Шуның исеменнән безнең ыруыбыз да, әүләбыз дә «хуҗалар әүләсы» булып киткән»,–ди.*

*Торганнар болар Кирит дигән җирдә. Авыл ике өлештән тора. Бер кисәге–Кирит, бер кисәге–Кымшак. Кымшак–ул половцы. Кирит-ләр–кири дигән төрки кабилә булган, дүртенче гасырлардан. Калабиткә якынрак ягы–Кирит ягы. Икенче ягы–Кымшак ягы. Ике якның да үзенең мәчете булган. Әүлиясы–Сарыхуҗа әүлия. Икенче төрле–Фаяз әүлия, дип тә әйтәләр.*

***Без–татарлар. Алтын Урданың уртасында утырып, без татар булмасак, кем татар ул вакыт!***

***Амил***. *Амил беренче марттан башлана. Ул элек Тияктә башланган. Тияк–төбәк сүзеннән. Анда ат ярышлары, көрәш, «алтын кабак» уеннары оештырылган.*

*Бездә иң популяр уен да–«Алтын кабак». Төз атуга корылган.*

*«Алтын кабак» ярышында баганага алтын балдак яки көмеш тәңкә элгәннәр. Аны атып төшергәннәр. Бу төз ату ярышы. «Алтын кабак» ярышында җиңүчегә иң зур приз бирелә.*

*Көрәшкә куй бирелгән. Халык бәйрәмгә бүләкләрне алдан җыйган. Пылау пешерергә ярма, дөге дә җыйганнар. Хәзер бу бәйрәм уеннары, ярышлары көзге авыл бәйрәмендә оештырыла.*

*Беренче март–Тияктә.*

*Икенче көн–2 (15) март Амил бәйрәме Казавылга, безнеңчә Казый авылына күчә (Казачий берег). Хәзер ул кала эчендә калды.*

*Өченче көн тагын берәр авыл.*

*10–11 мартта–Кызан, Каргалык, Майлы Күлдә. Кышлар салкын булган. Бозлар ышанычлы булса, боз аша берсе икенчесенә чыгып, ике яки өч авыл кушылып уздырган. Егетләр-кызлар танышалар. Ата-аналар туганнарының хәлен беләләр. Туйлар көне билгеләнә. Олы туганнар кул алыша, күрешә.*

*Хатын-кызлар амилгә архалык кигәннәр. Ул–билендә бер генә төймәле кием. Күлмәк өстеннән кигәннәр. Тәңкәләр тегелә алдына, изүенә. Тәңкәләрнең исемнәре–тугызлык ( бер тәңкә), егерме бишлек булган.*

*Амилдә хушавазлар әйтелә торган булган. Сәдага, дип әйтелә. Сәдака түгел.*

*Амил дини бәйрәм түгел. Шулай да муллалар шәкертләргә Ша'диван әйттергәннәр. Алдан ук өйрәткәннәр. Алар җыелып йөриләр икән. Иң матур тавышлы шәкерт тарафыннан көйләп башкарылган. Аннары хор белән ша'диван дигәннәр. Бу такмакларны ша'диван дип атыйлар. Ша'диван язылган кәгазьләр булган. Агачларга беркетелгән бөтерелгән кәгазьләр.*

Кыш китте,
Яз килде.
Үрдәк белән каз килде.
Корткалар да язылды.
Ша'диван!
Тор-тор, бикәм,
Тор, бикәм!
Төлке туның сал, бикәм!
Безгә акча бир, бикәм.
Ша'диван!

*Амилгә кабак ашау тиеш булган. Һәр өстәлдә кабак ризыклары булган.*

*Бәрәңге кергәнче кабак төп ризык булган.*

*Бездә иң таралган ризык–пылау, пылау белән кабак. Амилдә көн буе өстәлдә ризык җыелмый. Кабак бүрәген тезеп сала, шикәргөлме, бадәмгөлме, барысын да. «Кул алырга» кергән кешеләрне чәй эчерәбез. Амилгә кабак бүрәген чүпрәсез камыр белән пешерәбез. Камырын нечкә генә җәеп, күп итеп кабак салып пешерәбез.*

*Амилдән соң кабак ашаган кешенең колагы саңгырау була. Марттан соң эчендә орлык ата. Аның файдасы калмый. Колак югары кан басымыннан саңгырау була. Кабак давлениене тигезләп бара, төшереп бара. Шифа юлы инде ул.*

***Әүлиялар каберләре**. Әстерханны кырык әүлия саклый. Әстерханга сугыш җитмәде, шул әүлиялар саклады, дип әйтәләр. Һәрбер авылның үз әүлиясы бар. Әстерханда да әүлиялар бар.*

*Совет районында Әстерханның Баку урамы бар. Анда Владимирский собор урнашкан. Бу урыннар элек «Кала тияге» дип аталган. Элек анда татарлар яшәгән. Владимирский соборны салганда мөселманнар да бик күп акча биргән. Анда–Газиз әүлия.*

*Каенанам дога кылганда: «Крепость астында яткан әүлияларның да рухы шат булсын»,–дип дога кыла иде. Әстерхан крепостеның астында–әүлиялар. Ул бит Хаҗи-Тархан урыны.*

*Татар-базар янындагы чиркәү эчендә дә әүлияларның кабере бар. Златоуст чиркәве әүлияларның кабере өстенә салынган. Әүлиялары: Фатыйма һәм Унбер Әхмәт әүлиялар. Чиркәүгә кергәч, күрсәтәләр ул җирне: «Здесь находится могила вашего святого», – дип. Анда сандык кебек җир. Шул җирне күрсәтәләр. Хөрмәт белән карыйлар.*

*Каргалыда – Сары Хуҗа әүлия.*

*Майлы Күлдә – Ак Барак әүлия. Ул изге кеше Сүләнкәдә (Солянка) торган. «Мин үлгәч, юып ат-арбага салыгыз, – ди. – Ат кайда туктый, шунда җирләгез», – ди. Аның кабере өстендә һәрвакыт ак байраклар тора.*

*Кызанбиктә Хан Түбә дигән җир, анда да әүлия, диләр.*

Экспедиция вакытында Әстерхан татарларының фольклорына, тел үзенчәлекләренә, традицион мәдәниятенә караган бай материал тупладык, кунакчыл милләттәшләребез белән аралашып, табигатенә сокланып, яңадан күрешү-очрашуларга өметләнеп кайттык. Кайда гына яшәсә дә, татар халкының тормышы һәрьяклап соклануга лаек. Тырыш, булдыклы халык яши биредә дә.

*Р. Р. Аскаров*

# КИГИНСКИЕ ТЕРЕГУЛОВЫ

*(Окончание. Начало в № 4, 2019)*

## *Ценный вклад в башкирскую филологию*

Рауза Низаметдиновна Терегулова (1910–1994) – старшая дочь четы Терегуловых. В 1932 г. окончила литературный факультет Башкирского государственного педагогического института. В течение пяти лет она преподавала русский язык и литературу в Уфимском педагогическом рабфаке, а затем ее назначили заведующей отделом Уфимского горкома комсомола.

В 1936 г. Наркомат просвещения БАССР направил молодого специалиста в аспирантуру Московского научно-исследовательского института национальностей. В связи с реорганизацией этого института, Наркомат просвещения РСФСР перевел ее в аспирантуру Московского государственного педагогического института им. В. И. Ленина.

Трудовая биография Раузы Низаметдиновны в высшей школе начинается в качестве исполняющей обязанности доцента Ивановского государственного педагогического института. В 1939 г. по семейным обстоятельствам (муж в то время работал в Тамбове) она перевелась на педагогическую работу в Тамбовский государственный педагогический институт, где читала курсы лекций на литературном факультете и на факультете иностранных языков по дисциплинам «Введение в языкознание» и «Современный русский язык».

В военном 1942 г. Рауза Терегулова возвратилась в Уфу. Она работала в Совнаркоме БАССР консультантом по культуре, позже заведующей сектором культуры Совета Народных Комиссаров. 6 июня 1945 г. ее наградили медалью «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.».

Рауза Низаметдиновна хотя и работала на партийно-советских должностях, но душа ее все время тяготела к педагогике. В 1944 г. она перевелась старшим научным сотрудником в Башкирский научно-исследовательский институт истории, языка и литературы имени М. Гафури. В 1946 г. Р. Н. Терегулова защитила кандидатскую диссертацию на тему «Словарный состав «Хождения Афанасия Никитина»» в Казанском государственном университете имени В. И. Ульянова-Ленина.

За время работы в системе Башкирского филиала АН СССР Терегулова показала себя как способный научный работник. В ее характеристике

отмечается, что все работы Терегуловой имеют научную и практическую ценность.

Особенно большое значение имеет её книга «Сравнительная грамматика русского и башкирского языков» как первое учебное пособие такого рода для педагогических институтов Республики, после введения в них курса сравнительной грамматики русского и башкирского языков. Она вела исследования по одному из актуальных вопросов советского языкознания о влиянии русского языка на развитие башкирского.

Научная деятельность Р.Н. Терегуловой определяется своеобразной направленностью, характеризующейся исследованиями взаимовлияния, сравнения и сопоставления грамматических систем, русского, башкирского и тюркских языков, что является особенно важным в национальных республиках, в которых кадры специалистов, имеющих двойную квалификацию (в области русской и восточной филологии) еще совершенно недостаточно.

Р.Н. Терегулова являлась автором многочисленных научных трудов. Совместно с профессором Николаем Дмитриевым были подготовлены башкирско-русский и русско-башкирский словари.

Она умело сочетала научную работу с общественной деятельностью. Была пропагандистом, избиралась в комсомольские и партийные руководящие органы, была депутатом Уфимского горсовета. Ее трудовая деятельность была оценена медалью «За трудовую доблесть» и многочисленными почетными грамотами. В начале 1960-х гг. она тяжело заболела и была признана инвалидом II группы. В декабре 1965 г. Р.Н. Терегулова ушла на заслуженный отдых.

По стопам своей матери пошла ее дочь Римма Амировна. Ее отцом был известный башкирский писатель Амир Чаныш. Сын Раузы Низаметдиновны – Рустэм Нурович Чураев – крупный ученый генетик, доктор биологических наук. Р.Н. Чураев родился в 1947 г. в Казани. С детства увлекался биологией. Сохранилось письмо из города Новосибирска от 3 декабря 1962 г., написанное Созоненко по поручению профессора А.А. Ляпунова следующего содержания: *«Профессор А.А. Ляпунов познакомился с Вашей рукописью, которая произвела на него хорошее впечатление. Правда, то, о чем Вы пишите, в основном, уже известно, но мысли дельные и ценные. Если бы Вы смогли приехать сюда в какие-нибудь каникулы или после окончания учебного года, то Алексей Андреевич охотно бы с Вами встретился».*

В 1970 г. он окончил Новосибирский государственный университет по специальности «Генетика, математическая биология». В 1976 г. защитил кандидатскую диссертацию, в 1988 г. – докторскую. С 1970 до 1983 гг. ра-

ботал в Институте цитологии и генетики Сибирского отделения АН СССР. В 1983–1986 гг. заведовал лабораторией в отделе биохимии и цитохимии Башкирского филиала АН СССР. С 1986 г. по настоящее время является директором Института биологии УНЦ РАН. В 2000 г. группа ученых Института биологии Уфимского научного центра Российской академии наук сделала сенсационное научное открытие. «Отец» данного открытия Рустэм Нурович Чураев в одном из интервью дал такое разъяснение: «В этом году было много шума по поводу «расшифровки» генома человека. Но это не совсем так, точнее, не так вовсе. Сегодня можно говорить лишь об одном из этапов работы, когда выписана первичная последовательность ДНК. Ген – это часть ДНК, отвечающая за синтез определенного белка. Существует два способа хранения любой информации: структурный (например, буквами) и динамический. Так, в русском языке 33 буквы, а в ДНК «четыре»: аденин, тимин, гуанин, цитозин – они чередуются и кодируют структуру белков. Динамический способ хранения информации – это когда в некой циклической системе информация просто циркулирует. Что такое эпиген? Идея его родилась в Институте цитологии и генетики Сибирского отделения АН СССР более четверти века назад. В 1978 г. вышла англоязычная работа, а тремя годами раньше увидела свет работа на русском языке «Гипотеза об эпигене». Эпигеном тогда была названа циклическая система генов, которая имеет не менее двух режимов функционирования, причем каждый из них может наследоваться в ряде последовательных генераций. Ген может быть включен или выключен. Если мы, предположим, включили (выключили) ген, входящий в эту систему, а потом убрали включивший (выключивший) его сигнал, и если при этом состояние гена будет передаваться – это и будет эпиген.

Допустим, взято два гена: один – от вируса, другой – от бактерии. Белок, вырабатываемый одним геном, подавляет активность другого гена. Эпигенная система, состоящая из генов, получает дополнительные свойства: часть наследуемой информации может передаваться потомству. Мы получили управляемую наследственную единицу более высокого ранга, чем ген, как бы надген. Это искусственная генная сеть с наперед заданными наследуемыми свойствами.

В чем же прикладное значение открытия? Существует генная инженерия, теперь можно говорить и об эпигенной инженерии, когда возможно создание управляемых эпигенов с заданными свойствами. Работая с объектами в нанометровом диапазоне, ученые подбираются к ДНК – нанотехнологиям».

Некоторые ученики Р. Н. Чураева трудятся в США. Молодежь активно идет в науку. Только в 2000 г. были защищены 13 кандидатских и одна

докторская диссертации. Словом, ученые Башкортостана остаются востребованными.

Таков он, Рустэм Нурович Чураев, человек-ученый – сын Раузы Низаметдиновны Терегуловой и почетного гражданина Уфы Нура Сахаутдиновича Чураева.

***Делать жизнь с кого...***

Райля Низаметдиновна Терегулова (Ибрагимова) (1912–1998).

До 12 лет жила в родном Еланлы, где окончила начальную школу. Затем продолжила учебу в семилетней школе Сатки Уральской обл. (ныне Челябинская обл.). В 1927–1930 гг. училась в Башкирском Областном педагогическом техникуме Уфы, по окончании которого была направлена в Хайбуллинский район БАССР в качестве дошкольного работника. Семнадцатилетней учительницей сельской школы начала свою работу Райля Низаметдиновна Терегулова. Дочь учителя, она тоже посвятила себя педагогике.

В 1932 г. ее перевели в Уфу, в научно-исследовательский институт педагогики. Одновременно преподавала в дошкольном педтехникуме. Затем она училась на педагогическом факультете Московского государственного педагогического института имени В. И. Ленина. Получив высшее образование, Райля Терегулова работала в различных учреждениях системы министерства просвещения БАССР: инспектором дошкольного отдела Министерства, методистом и заведующей областным дошкольным методкабинетом, заведующей дошкольным отделением министерства, завучем педагогического училища, а также преподавателем дошкольной педагогики и детской психологии.

В октябре 1940 г. Райля Терегулова поступила в аспирантуру Московского государственного педагогического института им. В. И. Ленина. Однако война прервала ее учебу, и она вернулась в Уфу. Два года работала директором Башкирского дошкольного педагогического училища.

В июле 1943 г. Райля Низаметдиновна Терегулова по семейным обстоятельствам переехала в Казань. Здесь она четыре года работала в аппарате Совета Министров Татарской АССР в должности помощника заместителя председателя Совмина по вопросам просвещения и культуры. Начиная с 1947 г. более 20 лет вела преподавательскую деятельность в Казанском государственном педагогическом институте, прервав ее на три года, так как ее пригласили заведовать отделом школ и наук в обком КПСС Татарской АССР.

В Москве Райля Терегулова-Ибрагимова успешно защитила кандидатскую диссертацию, опубликовала свои первые научные труды, руководила группой по проблемам нравственного воспитания. С первых дней

в институте она зарекомендовала себя как знающий, тонкий педагог-мастер. Высокая идейная целеустремленность, научная глубина, педагогическая направленность, яркость изложения отличали ее лекции.

Воспитанники Райли Низаметдиновны успешно трудятся на ниве народного просвещения в разных уголках нашей страны. Многие из них продолжают подготовку будущих учителей в стенах родного института.

Богат и разнообразен вклад Р.Н. Терегуловой-Ибрагимовой в психолого-педагогическую науку. Начав с проблем формирования чувства долга и ответственности у детей, она постепенно перешла к изучению проблем нравственного воспитания школьников. Под ее научной редакцией были выпущены сборники «Вопросы нравственного воспитания», «Вопросы патриотического воспитания» и др. Исследования Р.Н. Терегуловой-Ибрагимовой получили высокую оценку в печати и приобрели широкую известность. Ее исследования всегда были созвучны времени, актуальны и до сих пор не утратили своего научного значения.

Всю жизнь Райля Низаметдиновна находилась в центре общественных дел: секретарь комитета ВЛКСМ, член партбюро, секретарь парторганизации педагогического факультета и факультета физвоспитания и спорта, член совета ветеранов. Сочетание высокой принципиальности, требовательности к себе и людям с чуткостью, внимательностью и культурой общения характеризовало Райлю Низаметдиновну как человека, преподавателя. Нельзя без волнений читать воспоминания ее дочери Райсы Махмудовны о маме: «Она увлекала студентов и преподавателей проблемами нравственного воспитания, вела большую экспериментально-опытную работу в школах города и Республики. Ее яркие, содержательные лекции по психологии, практические занятия до сих пор помнят ее бывшие ученики, а в настоящее время профессора, деканы и заведующие кафедрами педагогического университета Казани.

Уже после ее смерти, перебирая папки с лекциями, я поражалась той ответственности, с которой моя мама относилась к работе. На полях ее рукописных и отпечатанных лекций множество пометок следующего содержания: «В этом месте слушали не очень внимательно, пересмотреть изложение материала», или «здесь усилить такой-то момент» и т.д. И это – на всех текстах лекций! Вот такой внимательной, вдумчивой и требовательной к себе она была. И такой осталась навсегда. Вот почему ее помнят и восхищаются ею!».

У Райли и Махмуда Ибрагимовых родились и выросли две дочери. Старшая дочь – Райса Махмудовна окончила в 1967 г. историко-филологический факультет Казанского государственного университета. С 1967 по 1976 гг. она работала в ветеринарном институте, заведовала лаборато-

рией программного обучения и преподавала студентам нерусской национальности русский язык.

Более двадцати пяти лет она работает в Казанском государственном педагогическом университете старшим преподавателем кафедры психологии. Ее сын – Олег Евгеньевич окончил Казанский авиационный институт. В настоящее время руководит фирмой.

Младшая – Наиля Махмудовна после окончания средней школы поступила учиться в Ленинградскую академию художеств по специальности – искусствовед. В настоящее время преподает в инженерно-строительном институте историю искусств. До этого она много лет руководила детской художественной школой, работала в Совете Министров Татарской АССР и в художественном училище. У нее два сына: Ноэль живет в Иерусалиме, преподает в университете, он – физик-теоретик, а Орест – кандидат медицинских наук, руководит региональным медицинским центром, ведет научно-преподавательскую работу в государственной академии усовершенствования врачей Республики Татарстан.

***Они защищали Родину***

Четверо Терегуловых стали участниками Великой Отечественной войны.

Фарид Низаметдинович Терегулов (1915–1977). Окончив Еланлинскую начальную школу, Фарид продолжил учебу в Кигинской, а затем в Айлинской школах крестьянской молодежи (ШКМ). В 1928 г. поступил в Месягутовский татаро-башкирский педагогический техникум. После смерти Низаметдина Фасхетдиновича семья переехала в Уфу. Тяжелое материальное положение, создавшееся после смерти отца, временно оторвало Фарида от учебы.

В начале 1930-х гг. были организованы кружки по изучению башкирского языка в госучреждениях. В то время Ф. Терегулов преподавал сначала в научно-исследовательском институте реконструкции сельского хозяйства, потом в Башконторах «Сельхозснабжение» и «Сельхозснабремонт». Только в 1934 г. осуществилась его мечта – он стал студентом факультета русского языка и литературы Башкирского государственного педагогического института.

После успешного завершения вуза Фарид Низаметдинович работал преподавателем в Темясовском и Уфимском дошкольном педагогическом училищах.

Когда грянула Великая Отечественная война Фарид Терегулов с первых ее дней встал в ряды защитников родной страны от немецко-фашистских захватчиков. Рядовой Терегулов воевал в составе 1200 стрелкового полка 361 стрелковой дивизии, участвовал в боях на подступах к Ржеву. В феврале 1942 г. был тяжело ранен, лечился в Осташковском и Фрунзен-

ском военных госпиталях. В августе 1942 г. после вторичного ранения и выздоровления, он был направлен на хозяйственную службу в полевой подвижный хирургический госпиталь, где находился до конца ноября 1945 г. В составе 43-й армии I Прибалтийского фронта прошел через Восточную Пруссию и Польшу, дошел до Берлина. Его грудь украсили медали «За боевые заслуги», «За взятие Кенигсберга», «За победу над Германией» и др.

Вернувшись в Уфу, Фарид Низаметдинович восстановился на преподавательской работе в педучилище. Имея большой жизненный и педагогический опыт, он решил поступить в аспирантуру. В 1947–1951 гг. учится в аспирантуре научно-исследовательского института методов обучения Академии педагогических наук РСФСР, затем в институте национальных школ Академии педагогических наук РСФСР.

Начиная с 1952 г. до последних дней своей жизни Фарид Низаметдинович Терегулов преподавал русский язык в Башкирском педагогическом институте, преобразованном в 1957 г. в Башкирский государственный университет.

Его учителями были известные ученые-профессора Н. Дмитриев, Ф. Советкин, В. Чистяков. Фарид Терегулов стал крупным специалистом по методике преподавания русского языка в национальной школе. Он подготовил и опубликовал десятки научных статей, участвовал в повышении квалификации учителей, выезжал и читал лекции учителям-языковедам в города и районы Республики. Свою преподавательскую и научную деятельность он умело сочетал с общественной работой.

Ф. Н. Терегулов работал над кандидатской диссертацией по теме «Изучение грамматических категорий рода русского языка в башкирской школе», но работа затянулась на долгие годы. Тема диссертации была актуальной как в теоретическом, так и в практическом плане. Ее сложность потребовала кропотливой работы. Дело в том, что по данному вопросу существовало очень много противоречивых положений, относящихся к самым разнообразным философским, лингвистическим и методическим направлениям. Так, например, предположения о том, что базой для образования категорий рода послужили будто бы «идея пола» (Г. Пауль, В. Богородицкий), «признак ценностей» (В. Вунд), «противопоставление одушевленного и неодушевленного» (А. Мейе), «переосмысление живого и неживого» (А. Чикобава), «общественная жизнь» (Н. Марр), «социальная активность и пассивность» (И. Мещанинов), «класс предметов активного и пассивного значения» (В. Трофимов) и многие другие – все это представляло собой ту невероятную путаницу, которая явилась результатом смешения грамматической категории рода с разнообразнейшими неграм-

матическими явлениями. Эти «установки», приведшие в конечном счете к терминологической неупорядоченности и в сущности игнорирующие роль категории рода, как и всех других грамматических категорий, в определении грамматического строя языка, не могли, конечно, не отразиться отрицательно на весь процесс обучения русскому языку в национальной школе. Правильное, принципиальное разрешение вопроса об изучении грамматических категорий русского языка в национальной школе открыло бы широкие возможности для совершенно новой организации педагогического процесса, для применения наиболее активных приемов обучения русскому языку в школах Республики.

К большому сожалению, у Фарида Низаметдиновича были и недруги. Из года в год в его производственной характеристике появлялись утверждения, что в кандидатской диссертации недостает научности. Они, будто клеймо, преследовали и давили талантливого педагога-языковеда. Не обошлось без клеветы и попыток опорочить его. Был такой случай, когда необоснованно в присутствии большой аудитории Фарида Низаметдиновича унизил и оскорбил бывший выпускник Башгосуниверситета. Кстати, тот «герой» ныне является известным поэтом, писателем, публицистом, но в человеческом отношении остался довольно непорядочным карьеристом-националистом.

Чувство несостоявшейся личности, присутствие барьера в коллективе, неудачи в семье – вот составляющие трагедии, финал которой наступил после ухода из университета по собственному желанию. Его смерть в 1977 г. была ускорена всеми этими событиями.

Его дочь Диляра Фаридовна Терегулова-Тимербулатова закончила факультет иностранных языков Башкирского государственного университета. Она работает учительницей английского языка в одной из уфимских школ. Ее уникальный авторский проект обучения иностранному языку делает «обучаемыми» каждого, кто хочет знать язык. Внуки Фарида Низаметдиновича – Ильгиз успешно закончил Башкирский государственный медицинский университет с красным дипломом, а Руслан еще учится в школе.

Сания Низаметдиновна Терегулова (1917 г.р.). Ей было 14 лет, когда семья переехала из д. Еланлы в Уфу. После окончания в 1936 г. медицинского техникума она два года проработала медсестрой в больнице системы НКВД. В 1938 г. поступила в Башкирский медицинский институт. Но началась Великая Отечественная война и уже в первые дни войны она была мобилизована на фронт, служила в авиачасти в качестве военного фельдшера. Демобилизовалась в октябре 1945 г. В 1952 г. закончила Казанский государственный медицинский институт. До ухода на заслуженный отдых работала врачом-терапевтом. Этого скромного, тру-

долюбивого и отзывчивого врача хорошо знают в Казани. Она награждена медалями «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», «Ветеран труда», значком «Отличник здравоохранения».

Рагиб Низаметдинович Терегулов (1919–1941). После окончания средней школы он учился в сельхозтехникуме. Учился на «отлично», обладал большими способностями к учебе. Оттуда Рагиб был призван на военную службу.

Первые удары фашистской армии приняли на себя славные пограничники и войска прикрытия государственной границы.

Рагиб Терегулов, будучи пограничником, проходил службу в Каменец-Подольске (Хмельницкая область, Украина). С началом войны на подступах к Каменец-Подольску развернулись ожесточенные бои, в связи с угрозой окружения войска Юго-Западного фронта 9 июля 1941 г. оставили город. Воин-пограничник Рагиб Терегулов погиб, видимо, в первые дни войны. На запрос Махфузы Шамсутдиновны Главное управление пограничных войск НКВД СССР сообщило следующее: «На Ваше письмо с запросом о сыне Терегулове Рагибе Низаметдиновиче сообщаем, что местонахождение его в настоящее время пока неизвестно. В имеющихся списках безвозвратных потерь пограничных войск НКВД (убитых, умерших от ран и пропавших без вести) тов. Р.Н. Терегулов не значится. 27 апреля 1942 г.». В дальнейшем на запросы его матери ответа о судьбе сына не последовало.

Камиль Низаметдинович Терегулов (1921–1945). С детства интересовался авиацией и его манила профессия летчика. Действительно, Камиль стал им. Во время Великой Отечественной войны К.Н. Терегулов часто приезжал в Казань за боевыми самолетами. Он всегда останавливался в квартире своей старшей сестры Райли. В последний раз он приехал в 1944 г. Затем была весть о нем: *«Ваш сын летчик гвардии лейтенант Терегулов Камиль Низаметдинович уроженец Башкирской АССР, Кигинского района, деревни Еланлино, находясь на фронте, пропал без вести 19 апреля 1945 года».* Камиль Терегулов несколько дней не дожил до долгожданной Победы. Вылетел с особым заданием в США и оттуда не вернулся. Прислали только его личные вещи и матери его была назначена пенсия за погибшего сына.

Так горе не обошло семью Терегуловых, как и миллионы других семей советской страны в той страшной войне с фашизмом.

***Младшие Терегуловы***

В начале июля 2001 г. мне представилась возможность совершить второй раз поездку в Казань в течение одного года. Несколько дней общался с дочерьми и другими потомками Низаметдина и Махфузы Терегуловых. С Райсой Махмудовной побывали в мусульманском кладбище, где поко-

ятся ее бабушка Махфуза и родители – Райля Низаметдиновна и Махмуд Кашапович. Кстати, могилы супруг Ибрагимовых находятся недалеко от последнего пристанища великого татарского поэта Габдуллы Тукая. Сания Низаметдиновна собрала на чай своих близких людей – сестер и племянниц. А какую аппетитную губадию с румяненькой корочкой по-мастерски она приготовила! За столом в непринужденной обстановке велась оживленная беседа. Признаюсь, мне было очень приятно присутствовать среди потомков знаменитых Терегуловых. В то же время нас объединяло нечто более важное – наша малая родина, кигинская земля. Райса Махмудовна отметила, что в последнее время между Терегуловыми сложились налицо реальные и ценные отношения, возникшие благодаря моей активности. Мне же было интересно слышать из их уст всё о славных предках – жизни и деятельности Терегуловых и Еникеевых, а также представителей сегодняшнего поколения. Тогда мне посчастливилось лично познакомиться с Рахилей Низаметдиновной Терегуловой. Именно в ней, по-моему, присутствуют дворянские черты, какие мы знаем по книгам и фильмам. Это – манера общения, речь, умение по-особому держаться при людях. Словом, аристократичность. В этом нет ничего удивительного. Ведь предки Терегуловых принадлежат к знатному роду татарских мурз.

Рахиля Низаметдиновна Терегулова-Кузнецова (1927 г.р.) родилась в селе Еланлино Кигинского района БАССР.

После смерти отца в 1931 г. переехала со всей семьей в Уфу, где прошли ее детские и юношеские годы.

После окончания средней школы Рахиля Терегулова поступила в Башкирский государственный педагогический институт. Но по ряду причин перевелась в Казанский государственный педагогический институт, который успешно закончила в 1955 г. и получила диплом преподавателя русского языка и литературы.

Р.Н. Терегулова работала в разных системах: в педагогическом училище г. Тетюши ТАССР, в профессионально-техническом образовании и народного образования. Она вела предметы: русский язык и литература, выразительное чтение, методику преподавания русского языка и литературы. В те годы, когда в Советском Союзе вышло постановление об обязательном среднем образовании всего населения и в связи с этим начали открываться вечерние и заочные средние школы, Рахиля Низаметдиновна стала работать завучем на заочном отделении при меховом комбинате. Сотни рабочих без отрыва от производства обучались у нее русскому языку и литературе. В 1970-х гг. в Казанском химико-технологическом институте обучалась группа студентов из Вьетнама. Русский язык преподавала им Рахиля Терегулова-Кузнецова.

Муж Рахили Низаметдиновны – Валерий Александрович Кузнецов был очень ярким и разносторонним человеком. В последние годы жизни ему открылись религиозные истины и как особо почитаемого его похоронили в одном из монастырских дворов в городе Ярославль, где он родился.

Ия әйберләрне, малларны күзгә күрсәтми яшереп тора. Шулай шаяра. Әле генә саныйсың, бер-икесе җитми, тагын саныйсың, шул арада саны дөрес чыга, шулай аптыратып бетерә кешене. Гаилә әгъзаларын яратса, йорт иясе бер зыян да салмый, яратмаса, борчый. Савыт-саба шалтырата.

– Тик кенә тор, йокларга ирек бир! – дисәң дә, тынычлана ул.

Сахаускова Розалия Мазгар кызыннан, 1955 елгы.

## МӨСЛИМ АВЫЛЫ

### *Мөслим (тарихи риваять)*

Мөселман халкы яши, дип, авылга Мөслим исеме кушканнар. Монда халык Пенза өлкәсеннән күчеп килгән. Уңдырышлы җирләр эзләп килгәннәр. 1886 елларда килә башлыйлар, 1900 елда мәчет төзиләр. Колхозлашу елларында 120 хуҗалык була биредә. Мәчеттә мәдрәсә булган. Мишәр Мөслиме дип тә йөриләр әле бу авылны. Телләре тирә-як авыллар арасында аерылып тора, мишәрчә каты сүлиләр.

Абдуллин Илмир Аманулла улыннан, 1967 елгы.

### *Читән күпер (топонимик риваять)*

Урсай белән Тымытык арасында Читән күпер дигән күпер бар. Ык кушылдыгы Сәстекай елгасы аша урнашкан күпер. Пугачев түбәтәй белән ком ташытып салдырган күпер, дип тә әйтәләр аны. Читән күпер дигән исеме каян? Нык булсын, дип, ике як ярга читән үреп, шуңа беркетеп салганнар аны. Читәнен ел саен яңартып торганнар. Күпер үзе читәннән түгел, агач сузып, киртәдән инде.

Хәкимова Мәүгыйдә Ибраһим кызыннан, 1936 елгы.

### *Ногыт салучы Саҗидәттәй (ышанулар, юраулар)*

Саҗидәттәй ногыт сала торган иде. Шулай карый да әйтә. Саҗидәттәй – Чәпәк абзый хатыны. Әйберең югалып, таба алмагач, барасың, Саҗидәттәйнең кырык бер ташы була торган иде. Шул кырык бер ташны өчкә аера, ногыт сала инде, карый. Шул урында шул әйберең, дип әйтеп бирә.

Тагын Зифаттәй дә сала иде ногытны. Ногыт салганда эчләреннән нәрсәдер укыйлар да иде. Ногыт салучыга я хәер кертәсең, я каймак-ише әйбер. Акчага түгел.

Ярмиева Рәйфә Миргалим кызыннан, 1939 елгы һәм Абдуллин Илмир Аманулла улыннан, 1967 елгы.

### *Мөкәмәй (мәзәк хәл)*

Мөкәмәй булган. Мөхәммәдҗан инде чын исеме. Өч малае булган. Алар үсеп җиткәннәр. Берсен дә башка чыгармый озак яшәгән. Җибәрәсе килми икән төп йорттан. Туплаган балаларын. Өч малаеның берсе башка чыккан атасына әйтми-нитми генә.

– Заһри китте! – ди икән моңа карчыгы.

– Кем типте?

– Типмәде беркем, Заһри китте! – ди икән моңа карчыгы һаман.

– Ныкмы типкән? – ди икән Мөкәмәй, әллә колагы ишетмәгәнгә, әллә ишетәсе килмәгәнгә. Сүзне кирегә бора икән. Сүз әйтмәгән Заһрига. Шулай башка чыккан Заһри.

Абдуллин Илмир Аманулла улыннан, 1967 елгы.

***Мунча пәриләре (мифик ышанулар, тыю)***

Мунча пәрие мунчада була. Вакытлары – төнге унике. Төнге уникегә кала башласаң, яратмыйлар. Ашыктыра, я аякны кытыклый. Өстәлләр әзерлиләр уникедә. Ашыйлар, эчәләр, ди. Төнге уникедә мунча керергә ярамый. Әтәч кычкырганчы мунча – аларныкы.

Ярмиева Рәйфә Миргалим кызыннан, 1939 елгы.

*(Дәвамы бар)*

***Резида Шәрифуллина***

# ШАЛТЫ АВЫЛЫ КАЙЧАН САЛЫНГАН?

*Адәм баласы ул шундый зат, гомеренә дистәләгән еллар өстәлә барган саен, үткән тормыш юлына әйләнеп карый, үзенчә нәтиҗәләр ясап, ирешкән уңышларын барлый, ирексездән, ясалган хаталарын искә төшерә. Әмма иң әүвәл нәсел-нәсәбеңне, тамырларыңны белү теләге арта бара, алай гына да түгел, ул бик тә мөһим максатка әйләнә. Мин кем? Ата-бабаларым нинди нәселдән? Тамырларым кая барып тоташа? Бу сорауларга җавап эзләп, вакыт үтү белән саргаеп беткән иске кәгазьләрне, гәҗит-журналларны, төрледән-төрле кулъязмаларны, инде таушала башлаган фотоларны актарырга керештем. Бар ихтыяр көчемне җигеп, эзләнүләремне алга таба дәвам итеп, архивларга да шактый йөрергә туры килде. Үзебезнең нәсел шәҗәрәсенә бәйле, туган авылыма, туган ягыма мөнәсәбәтле әллә никадәр кызыклы да, гыйбрәтле дә мәгълүматлар күреп, хәйран калдым.*

*Кем ничектер, мин бала чагымнан ук борынгылар тормышы белән кызыксына идем. Әткәй мәрхүмнең кышкы кичләрдә сөйләгән хатирәләре әле һаман да исемдә. «Җиде бабаңны бел!»–диләр безнең халыкта. Халык әйтсә, хак әйтә инде ул. Мин дә менә, гомер агышым пенсия яшенә таба борылгач, нәсел-тамырымны барлап, туган-тумача белән күрешергә, авылдашларымның хәлен белергә дип, туган туфрагыма–ямьле Баулы якларында урнашкан искиткеч матур Яңа Шалты авылына юл тоттым. Вакытлар узган саен, үткән гомернең, аралашкан кешеләренең кадере арта бара икән. Тормышыңда хыялга илтә торган юлда юнәлеш күрсәтеп, җитәкләп баручыларга күңелдә туган рәхмәт хисләре тагын да ныгый.*

*Баулы районының тарихы бик тә бай, үзенчәлекле һәм берничә гасырны үз эченә ала. «Баулыга нигез салучыларның типтәр дип аталулары исә аларның башкорт җирләренә[1] килеп утырган татарлар булган, дип фаразларга мөмкинлек бирә. Районда Хансуәр, Шалты, Исергәп, Татар Кандызы кебек борынгы авыллар бар. Борынгы заманнардан бирле татар авыллары белән янәшәдә Удмурт Ташлысы, Урыстамак кебек удмурт, Потап-Томбарлы, Васькино-Туйралы кебек чуваш, Дмитриевка кебек мордва авыллары яшәгән. Узган гасыр башларында бирегә Курск губернасыннан да берничә авыл күчерелә һәм шул чорда Поповка, Фоминовка, Кырым-Сарай (элекке исеме Большая Епифановка) авыллары-*

[1] Әмма, бу «башкортлар», үз чиратында, Нугай Урдасыннан калган нугайлар да булып чыгарга мөмкин һәм еш кына ул шулай булган да (ред.).

*на нигез салына, соңрак рус авыллары саны ишәя төшә. Бүген биредә 21 милләт вәкиле, зур интернациональ гаилә булып, тату һәм дус яши. Баулы районының хәзерге территориясенә элеккеге берничә волость кертелгән. Алар башта Самара губернасының (элекке Куйбышев өлкәсе) Бөгелмә өязенә караганнар. Баулы авылы биредә волость үзәге була, барлыгы биш башлангыч земский һәм чиркәү-приход мәктәбе, мәчетләрдә халык хисабына тотылучы мәдрәсәләр эшләп килгән. Мәдәният агарту учреждениеләре бөтенләй булмаган. 74 мәчет һәм ике дистәгә якын чиркәү әһелләре дин хезмәте күрсәткән. Баулы волостенда 87 эре һәм вак торак пункт исәпләнгән.*

*Сәнәгать предприятиеләреннән Петербургта яшәүче патша киңәшчесе Бутлеровның Акбуа һәм Александровка авылларында ике спирт заводы һәм алпавыт Ждановның кирпеч заводы булган. 1912-нче елда Волга-Бөгелмә тимер юлы һәм Ютазы станциясе салына. Халык игенчелек белән шөгыльләнгән», – дип яза КПСС-ның Баулы райкомы беренче секретаре булып эшләгән И.Х. Мәүлетхуҗин [Мәүлетхуҗин: 1987. ББ. 157–158].*

Туган якка кайткан саен, авылыма якынлашу белән йөрәк күбәләктәй талпына башлый. Монда бар нәрсә дә күңелгә якын, җанга рәхәт өсти.

Яңа-Шалты авылы өч өлкәгә илткән юл чатында, табигатьнең бик матур җирендә урнашкан. Бер яктан Башкортостан Республикасыннан борылып аккан ямьле Ык елгасы, куе әрәмәлекләр, мәһабәт Урал тау итәкләре аерып торса, икенче яктан чиксез Оренбург далалары башлана, өченче яктан – Татарстан җиренә кергән иген кырлары, көтүлекләр, төрле зурлыктагы таулыклар. Миңа калса, иң гүзәл һәм иң матур җирләр бездәдер ул. Авылыбызның бер ягында – Ык, авыл аша Кандыз елгасы ага. Авылыбызның үткән тарихы бик тә бай һәм шактый үзенчәлекле.

1920-нче елга кадәр ул Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостена кертелгән. 1920-нче елдан ТАССР-ның Бөгелмә кантоны составына күчерелгән. 1930-нчы елның 10 августыннан – Баулы районы, 1963-нче елның 1 февраленнән Баулы районы бетерелгәч, Бөгелмә районына караган, ә 1965-нче елның 1 февраленнән яңадан төзелгән Баулы районы территориясенә кертелгән.

Авылда яшәүче халык саны:

1859-нчы ел – 1512; 1889-нчы ел – 1811; 1897-нче ел – 2001; 1910-нчы ел –2480; 1920-нче ел – 2534; 1926-нчы ел – 2077; 1938-нче ел – 1381; 1949-нчы ел – 1310; 1958-нче ел – 1163; 1970-нче ел – 1265; 1979-нчы ел – 1001; 1989-нчы ел – 721; 2002-нче ел – 604; 2012-нче ел – 588; 2016-нчы ел – 532.

Яңа-Шалты авылының килеп чыгуы татар халкының бик тирәнгә үтеп кергән чал тарихы белән бәйләнгән. Бераз шушы тарих битләренә күз салыйк. Белгәнебезчә, Казан ханлыгының күп өлеше Явыз Иван та-

рафыннан басып алына. Соңрак, урыс патшасы Петр I Рәсәйнең чикләрен киңәйтү буенча зур уңышларга ирешә. Бу җирләрдә, билгеле, урыслар хакимлеген көчәйтергә кирәк була һәм моның өчен байтак кына чаралар да күрелә. Патша фәрманы белән Казан-Оренбург юлын төзү татар морзасы генерал Мәсәйгә йөкләнә. Бу татар генералына белдерелгән зур ышаныч була. Ул моңа Швециягә каршы сугышкан вакытта күрсәткән батырлыклары өчен лаек була. Аны хәтта хәрби хезмәттән дә азат итәләр. Патша генералга хәзерге Оренбург өлкәсе, Башкортостан, Татарстан чикләренең кисешкән урынында, Ык һәм Кандыз елгалары үзәнендә бик күп мәйданда җир биләмәсе бүләк итә.

Мәсәй Казанга килә. Идел-Чулман буйларыннан, Урал якларыннан юл төзүдә катнашучыларны җыя. Аларга ирек һәм җир вәгъдә итә. Бу дәвердә Рәсәйдә крепостное право хөкем сөрә әле. Солдатлар армия хезмәтендә 25 ел гомерләрен уздырып кайталар. Генерал тиз арада кирәкле эшчеләрне туплый. Алар арасында җирсез ярлылар, көнлекчеләр, хәтта качаклар да күп була.

Юлны төзү Казан шәһәреннән башлана. Алдан килешенгәнчә, һәр 20–25 чакрым юл үткәннән соң, почта станциясе, тукталышлар төзиләр. Һәрбер юлчы тукталыш саен атын алыштырып, бераз ял итеп, юлын дәвам итә алган. Вакыт үтү белән бу тукталышларга кешеләр килеп урнашалар. Тора-бара алар зураеп, авыллар һәм шәһәрләр хасил була. Бөгелмә, Кандыз, Иске Шалты, Абдуллино, Богырыслан һәм башкалар шундыйларга керә. Мәсәйнең үз резиденциясе Иске Шаутыда (хәзер Оренбург өлкәсендәге Иске Шалты) урнашкан булып, монда җаек казаклары килеп төпләнгәннәр. Бу авыл бик тиз үсеп киткән. Ул вакытларда «Шауты» сүзе станция яки тукталыш сүзен аңлаткан. 1694-нче елда Кандыз белән Ык елгасы кушылган җиргә Мәсәй үз якыннары белән күчеп килә һәм шул көннән башлап Яңа Шаутыга нигез салына. Вакыт үтү белән авыл исеменең әйтелеше бераз үзгәрә төшә һәм инде бик күп еллар дәвамында «Яңа Шалты» дип йөртелә.

Алар элеккеге 1-нче ферма янында яши башлаганнар. Бу вакытта ул урыннар куе урман белән капланган булган. Аларның малларын бүреләр, төрле җәнлекләр килеп, буып китә торган булган. Авыл бик тиз үсешкә ирешкән, чөнки ул булачак зур юл өстендә булган һәм төзү материаллары күп булган урынга урнашкан.

Башта бу җирләргә килеп утыручы кешеләрне солдатка алмаганнар. Яшәү өчен уңайлырак җирен күргәч, кешеләр Шалты ягына жыйнала башлаганнар. Аларның кайберләре үзләренә аерым җир кишәрлекләре алып урнашканнар һәм алар тора-бара Шалтының күрше авылларына әверелгәннәр.

Авылның тәүге нигезе Мәсәй белән Ханбәктән башлана. Поповкага Курск губернасыннан килгән урыслар төпләнә. Анда Падимин дигән бояр биләмәсе була. Шалты халкы аларны «курчаннар» дип тә йөрткәннәр. Салих авылына Пенза-Инза якларыннан килгән Салих исемле мишәр килеп урнаша. Яңа Чүте, элек биредәге инеш исеменә карап, Карамалы дип аталган. Анда шулай ук мишәрләр нигез корган. Хәнсүәр авылының килеп чыгуы, риваятьләргә караганда, бик үзенчәлекле. Яңа Шалтының аксакалы Хәбибрахман ага Хәмзин: «Кайсыдыр чорда, кайсыдыр ханның сөйгән кешесе булган. Хан аңа: «Теләсә кайдан, теләсә нинди җирне сайлап ал»,–дигән. Ханның сөекле бәндәсе шунда килеп утырган»,–дип, бик кызык итеп сөйли иде.

Ык елгасының икенче ярында урнашкан күрше Сөярмәт авылына нигез 1691-нче елда салына. Ул Шалтыдан өч елга иртәрәк төзелә башласа да, киң итеп үсә, зурая алмаган. Авыл урнашкан җир уңайсыз, тар, бер яктан–биек тау, икенче яктан–шаулап аккан Ык елгасы. Җәелеп яткан үзәннәрне, авылның үзен дә, һәр ел саен язгы ташу сулары баскан. Яңа Шалты халкы аны электән үк «сигез өйле Сөярмәт», дип атаган.

Яңа Шалты авылы тарихы бөтен татар халкы, шулай ук Рәсәй тарихына охшаш һәм бергә үрелгән.

XVIII гасырның икенче яртысында, ягъни 1773–1775 елларда, Идел буе һәм Урал тирәләрендә Пугачев восстаниесе җәелеп китә. Пугачев, безнең авыл аша үтеп, авылыбызның «Болын урамы» исемен йөрткән урамында үзенең көрәштәшләре белән кунып, ашап-эчеп киткән. Бу вакыйгалар Шалты аксакаллары телендә буыннан-буынга сөйләнеп киленгән.

1778–1780-нче елларда авылга беренче куыклы керосин лампасын Хаҗи Ибрай алып кайта.Тәүге тимер сабанны да Яңа Шалтыда ул куллана башлаган. Бу тамашаны күрергә бөтен авыл җыелган. Хәтта күрше авыллардан да килеп караучылар булган. Тимер сабан ул елларда бик кыйбат булган, шуңа күрә аны сирәк кешеләр генә сатып ала алган.

Бөгелмә өязе земская управасының архив фондында сакланган 1897-нче елгы документларында шундый язмалар бар: «Салих волосте Яңа Шалты авылының халкы–элек башкорт җирендә яшәүче татарлар, салым салынырга тиешле җирләре 6246 ½ дисәтин».

XX гасыр башында Яңа Шалты авылының иң алга киткән, киң үсеш чоры кичергән вакыты була. Шул дәвердә 750 хуҗалыктан торган зур авылга әйләнә. Олы юл өсте, якын тирәләрдә базарларның шактый булуы зур әһәмияткә ия булган. Бөгелмә, Абдуллино, Татар Кандызы базарлары заманында гөрләп торган. Яңа Шалтының үз базары да атнага бер тапкыр чәршәмбе көнне үткән. Анда да башка авыл-шәһәрләрдән сатып-алучылар бик күп килә торган булган.

1904-нче елны рус-япон сугышы Яңа Шалты халкына йогынты ясамый калмый. Әлеге сугышка батыр йөрәкле күп кенә ир-егетләр китә. Патша хакимиятенең, урыс генералларының булдыксызлыгы аркасында Рәсәй җиңелә. Бу хурлыклы сугышта авылдан китkәннәрнең барысы да диярлек чит җирләрдә башларын салалар. Дөрес, Әхмәт исемле бер кеше кайткан, ләкин анысы да аягын өздереп, агач аяк белән өенә кайтып егылган. Менә шул елларда инде Яңа Шалты авылында хуҗалыклар саны кими башлый. Кешеләр бөләләр, яхшы тормыш, бәхет эзләп чит җирләргә чыгып китәләр.

1905-нче елгы революция дулкыны Шалты авылын да читләтеп узмаган. Аннан Столыпин реформасы елларында халыкның күп өлеше авылдан күчеп киткән. Шалты авылы янында гына урнашкан Лабашов хуторы безнең авыл җирләренә кызыккан, һәм кан кою юлы белән булса да, авылны алырга теләгән. Бу хуторда бик бай урыслар утырган булган. Алар Шалтыга сугыш башларга дип, башкортлар белән шартнәмә төзегәннәр. Ләкин бу хәл вакытында беленә һәм хуторны барып туздыралар, урысларны куып җибәрәләр. Башкортлар ярдәмгә килеп өлгерә алмый калалар.

Авылда хәлле крестьяннарга караганда ярлылар күбрәк була. Җәбер-михнәт күргән Яңа Шалты кешеләре үз авылларында байларга ялланып эшләгәннәр. Авылның үзендә зур байлардан Сөләйманов, Шабаев, Гарипов, Фәхрәзиев булган. Алар кулында авылдагы барлык җирләрнең 2/3 өлеше тупланган була. Үз авылларында гына түгел, күрше-тирәдә дә авыл халкы байларга ялланып, көнлекче булып эшли. Якында гына урыс боярларының хуторлары булган. Җирсез, атсыз халык кая барсын? Монда килеп, эшкә ялланганнар. Кызу урак өстендә читкә китеп эшләүчеләр бермә-бермә арткан, әмма эш табу бик җиңел булмаган.

Язучы, дистәләгән повесть, хикәя, шигырьләр авторы, авылдашым Гали Гыйззәтнең әнкәсе истәлекләреннән: «Арыш урагы өсте, иртән иртүк чалгыларны алып, яшь балаларны кабык бәләкәй арбаларга салып, Палимин боярына (Поповкага) барабыз. Төрле яктан күрше авыллардан халык күп җыела иде. Капка ачылганны көтәбез. Менә ишегалдына керәбез. Анда озын өстәлләр. Табын ризык белән тулган. Кешеләр кашыкларын үзе белән йөртәләр. Ашарга утырабыз. Бояр үзе күзәтеп йөри. Кем яхшы ашый, шуларны язып ала да эшкә куша. Начар ашаучыларны алмыйлар. Ашый да алмаган кеше ничек эшләсен инде? «Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен»,– дип, юкка гына әйтмәгәннәр бит. Көнлек хезмәт хакын һәр көн кич белән бирәләр иде. Без, хатын-кызлар, 15–20 тиен, ирләр 30–40 тиен алалар. Ул чакта бер кадак шикәр (400 грамм) бер тиен тора иде».

### *Караңгылык чорында*

*«Арыш чәчтем – уңмады,*
*Бодай чәчтем – булмады.*
*Байларга гел хезмәт иттем,*
*Тамаккаем туймады».*
*Борынгы татар халык җыры.*

Революциягә кадәр авылыбызда күпчелек өйләр салам түбәле иде. Шалты авылы безнең якларда иң ярлы авылларның берсе булган. Халыкның ялкаулыгыннан түгел, юк, тырыш булган безнең халык. Бабаларыбыз чабата үргән, арысландай егетләребез лашманда йөреп, зифа буйлы кызларыбыз байга киндер тукмаклап көн иткән елларда, җирне агач сука белән ертып, игенне иңгә аскан тубалдан кул белән сибеп чәчкәндә, көлтәләрне чабагач белән сукканда, кыскасы, күп еллар элек – Октябрь революциясенә кадәр, Шалтыда Хәйбулла исемле ир-егет яшәгән. Шалтыда туып-үскән, шунда гомер иткән. Туган җиренең кодрәте канына сеңгәндер, киң күкрәкле, таза бәдәнле, алыптай куәтле булган ул. Хак булса, кулы белән даганы сындыра алган, ике куллап тотынса, атны күтәргән. Күзе үткен, күңеле моңлы, йөрәге гайрәтле булган Хәйбулланың ике күзеннән, әйткән сүзеннән акыл бөркелеп торган. Нәрсәгә тотынса, шуны булдырган, тик бәхете генә булмаган. Тир түгеп җир сукаласа, янып-пешеп урак урса – ашлыгы бай кесәсенә керә. Җәй буе эсселәрдә каралып, яңгыр-явымнарда чыланып-юешләнеп көтү көтсә – симез сарыклар, сөтле сыерлар бай абзарына кайта. Чаң-чоң чүкеч сугып, алачыкта юртаклар дагалый, ә ул елгыр атлар байны утыртып элдерә. Шундый мәһабәт гәүдәле, арыслан куәтле, бөркет карашлы, алтын куллы кеше дә көч-хәл белән җан асрасын әле! Ашарына җитәрлек булса, унҗиде яшьлек алмадай кызы Фәрдияне алтмыш яшен тутырган Кыям картка кияүгә бирер идеме?

Шулай да, яшьрәк чагында хәрби хезмәт үткәндә үзен мыскыллауга түзә алмыйча бер урыс солдатына бер генә суккан, тегесе шунда ук җан тәслим кылган. Барлык солдатлар Хәйбулланы яклагач, офицерлары да мәрхәмәт күрсәткәннәр, эш трибуналга барып җитмәгән. Хәйбулла батырның гаделлеген таныганнар. Полк мулласы аның янына килеп, башка бер кешегә дә сукмаска Коръән тоттырып ант иттергән. Шуннан соң Хәйбулла сүзендә торган, гомерендә бер кешегә дә сукмаган. Тик бервакыт урманга утынга баргач, төялгән йөкне тарта алмаганга, ачуыннан атының маңгаена йодрыгы белән тондырган. Билгеле инде, бичара хайван шунда ук җан бирән. Хәйбулла кеше атын үтерү кайгысыннан нишләргә дә белмәгән, хатынын биленнән күтәреп йөк өстенә утырткан да, йөге-ние белән арбаны тартып өйләренә алып кайткан.

Авылдашларымның риваятькә тиң истәлекләренә күз салыйк: авыл егетләре Хәйбулланы кызык итмәкче булалар. Батырның сөйгән кызына күз атып йөргән күрше егете Хәйбулланың бүреген сиздерми генә ала да, яңа гына буралган бура башына меңгереп куя. Батыр сүзсез генә бүреген бура башыннан ала, шул ук бураны бераз күтәрә төшеп, аның бүрәнәләре астына инде күрше егетенең бүреген салып куя. Мескен егет күпме генә тырышмасын, күпме генә бура тирәсендә әйләнеп йөрмәсен, бүреген тартып чыгара алмаган. Бу хәлдән соң, билгеле, Хәйбулланың абруе бермә-бер арткан.

Ә менә Шалтының икенче батыры Сәмигнең тормышы, кызганычка каршы, фаҗига белән тәмамлана. Ул янгын вакытында арбаның күчәре сынгач, кырык чиләк сыешлы мичкәне күтәреп, янгын янына илтеп куя һәм кешеләрне бәладән коткарып кала. Ул чакта Рәсәй хакимиятенең сәясәте төрле милләтләр арасында үзара ызгыш-талаш оештыруга юнәлгән була. Әгәр алар үзара дус яшәсәләр, бергәләп үзләренең изүчеләренә каршы көрәшкә күтәрелүләре бар бит! Сәмиг батыр шул сәясәтнең корбаны булды да инде. 1901-нче елны Абдуллин базарына барырга чыккач, юлда аңа унлап йөкче чувашлар очрый. Кем кемгә юл салырга тиеш? Алар арасында бәхәс чыга, бәхәс, зурдан кубып, низагка әверелә. Чувашлар белән килешеп булмаслыгын аңлагач, Сәмиг кайсысының чанасын уңга, кайсысын сулга аударып, узып китә. Әмма Ялбай чувашлары эшне болай гына калдырмыйлар. Сәмиг батыр базардан кайтканын сагалап торалар. Аны күрүгә, яшеренгән җирләреннән чыгып, кинәт кенә күсәкләр, сәнәкләр белән өстенә ташланалар. Чын-чынлап батырларча көрәшә Сәмиг, тик көчләр тигез булмый. Инде кешелеген югалткан адәм актыкларыннан аерылдым, дигәндә, берсе аягына сәнәк белән кадый. Егылган Сәмигны күсәкләр белән бик каты кыйныйлар. Бу бәрелеш озак бара. Ялбай чувашлары арасында да яраланучы-имгәнүчеләр шактый күп була. Кан югалтудан көчсезләнгән Сәмиг бер мунчада төн үткәрә. Шунда аны, мәсхәрәләп, гәүдәсен кисәкләргә турап, ерткычларча җәзалап үтерәләр. Яңа Шалты-Абдуллино юлы өстендә Ялбай авылына керер алдыннан уң якта ялгыз кабер бар. Аның ташы да юк, исеме дә язылмаган. Бу – Сәмиг батырның мәңгелек йокыга талган урыны.

Шалты халкы кайчан да булса яхшы тормыш киләсенә өмет югалта ул елларда. Ачлыктан, хәерчелектән чарасыз калган тол хатыннар тәненә юха елан оялаган камыт аяклы, ач күзле Искәндәргә юк кына бәягә кыз балаларын сатып җибәрәләр. Безнең авылдан өч кызны алып китте ул мөртәт, шайтан ялчысы! Безнең күршедә үскән Таифә кызы Бибинур гүзәлләрнең гүзәле иде. Йөз илле сум биреп ала анасыннан маклер аны. Зур керем өмет итеп, эчендә шайтаннары биешә. Ләкин Бибинур төре-

кләргә сатылудан үлемне яхшырак күрә һәм шунда юлда очраган елга чоңгылына сикерә. «Монда калса да, ачлыктан үлгән булыр иде, чөнки анасы да, калган биш сеңлесе дә бер-бер артлы ачлыктан үлеп беттеләр, – дип, ачынып сөйләгән иде Хөппиҗамал әби. – Үзебезнең тамак тук булса да, янәшәдә генә ачлык, үлем, хәерчелек күреп яшәүләре бик авыр иде. Тагын бер авырлыгы шунда: бай гаиләләргә бүрегә караган кебек карыйлар, әйтерсең лә, хәерчелеккә, үлемгә тик син генә гаепле. Хәзер тамак тук, өс бөтен, бар халык бер чама тормышта, җан тыныч, йокы тыныч».

### *Октябрь һәм Шалты*

Декабрь аеның салкын бер көнендә Шалты авылының басу капкасыннан бер атлы юлчы килеп керде һәм Шәфыйк байлар капкасына юнәлде. Иртәгесен авылны шаккатырып: «Патшаны чәнчелдергәннәр, байларга көн бетәчәк. Җирне, байлар җыйган бөтен байлыкны ярлыларга өләшәчәкләр икән», – диебрәк сөйләшкәли башладылар. Шулай итеп, яхшырак тормышка өметләре өзелгән күпләрне куандырган революция турындагы хәбәр Шалтыга 1917-нче елның унҗиденче декабрь көнендә килеп ишетелә. Ләкин бертөрле яңарыш та сизелми.

Бу яктан, гомумән, Бөгелмә, Баулы яклары бик үзенчәлекле була. Совет власте биредә шактый авыр һәм соң урнаша: халык артык надан, ә кара көчләр каршылыкны шактый бердәм, оешкан һәм дәвамлы күрсәтәләр. Мисал өчен, безнең күрше Хөппиҗамал әби болай сөйләде: «1917-нче елның нәкъ Яңа елы алдыннан безгә Глазков дигән офицер килеп керде (Глазков Бөгелмәдә урнашакан 129-нчы запас полк командиры була). Ул авылның байларын, муллаларын җыйды һәм аларга корал табарга, авылда власть үзгәртергә уйласалар, үзенә хәбәр җибәрергә, башка авылларга да күз-колак булырга кушты. Без, бик борчылып, бу урыс авылга килеп, кеше үтерү оештырыр, дип яшәсәк тә, ул авылга бүтән килеп йөрмәде».

Дөньяның асты өскә килде. Эшче-крестьяннар, берләшеп, 1917-нче елның 7 ноябрендә (иске стиль белән 25 октябрендә) революциядә җиңеп чыктылар. Безнең авылдаш Хисмәтулла Идиятов, Петербург гарнизоны солдаты буларак, Кышкы сарайны алуда катнашкан. Ул Владимир Ильич Ленинны күрү бәхетенә ирешкән һәм гомер буе моның белән горурланып яшәгән. Ул бу турыда авылдашлары, бигрәк тә мәктәп укучылары каршында бик тәэсирләнеп чыгыш ясый торган булган.

Рәсәйдә Совет хакимияте урнашты. Илне бөлгенлектән торгызу, сәнәгатьне күтәрү өчен завод-фабрикаларда эшләүчеләрне азык-төлек белән тәэмин итәргә кирәк иде. Авыл халкына продразверстка килеп төште. Азык-төлек хәзерләү отрядлары авылларга килеп, һәр хуҗалыктан

икмәк, ит, бәрәңге, йомырка җыеп алып китәләр иде. Продразверстка – ул вакытта Совет властен икмәкле итү өчен бердәнбер чара булган, күрәсең.

Ике ел илдә Гражданнар сугышы бара. Аннан алда – Герман сугышы. Халык тәмам алчыкты, хәлсезләнде. Продразверстка дип, халыктагы бөтен икмәкне алып бетерү кулакларның гына ризасызлыгын тудырып калмый, халыкның 60% тәшкил иткән хәлле крестьяннарның да Советка булган өметләрен җимерә, ярлыларны да аптырашта калдыра. Шуннан файдаланып, 1920-нче елның февралендә Совет власте белән килешмәгән кулаклар, элеккеге сәүдәгәрләр, акгвардиячеләр, дезертирлар, кайбер руханилар, урта хәлле крестьяннарның бер өлеше акгвардияче эсерларның «Каракош» оешмасы житәкчелегендә Советларга каршы сәнәкчеләр фетнәсе күтәрделәр. Сәнәк сугышы өч губернаны – Казан, Уфа, Самараны колачлый. Кабынып китүе Уфа губернасына кергән Минзәлә өязенең Яңа Алан авылында була. Хәзер бу җирләр Татарстанның Әлмәт районына керә. Әлеге җирлектә ул чакта өч миллион кеше яшәгән.

Сәнәкчеләр унсигез яшьтән алып илле яшькә кадәр булган ир-атларны мобилизацияләү турында фәрман тараттылар. Моңа буйсынмаганнарны үлем белән куркыттылар. Фетнәчеләр яңа хакимияткә хезмәт иткән һәр кешене, яшенә, җенесенә карамыйча, җәзалап юк итәргә, үтерергә дигән максат тота иде. Бу сәнәк сугышында ачу бер кешедән икенчегә күчә, кеше акылын югалта, көтүгә әверелә. Сәнәкчеләрнең вәхшилекләре тетрәндерә.

Петровка спирт заводында да тетрәндергеч вакыйгалар була. Алдагы көнне генә спирт заводы фетнәчеләрдән азат ителгән була. Ләкин сәнәкчеләрнең бер төркеме урманга качып өлгерә, алар төнге буранда кире әйләнеп кайта. Капка төбендәге каравылчыны, сакка калдырган унҗиде кызылармиячене тавыш-тынсыз гына юк итәләр. Завод директоры Сәгыйдулла абзый Хәбибуллинны тотып алып, бик каты җәзалыйлар: күзләрен чокып алалар, борынын, колакларын кисәләр, күкрәгенә кисеп биш чатлы йолдыз ясыйлар, бөтен тәнен сәнәк белән тишкәләп бетерәләр. Соңыннан завод ишегалдындагы фонарь баганасына асып куялар. Башкорт ягында сәнәкчеләр шулай ук котырганнан-котыра бара, балта белән сабыйларның ияген сугып чыгаралар, йөкле хатыннарның корсагын ярып, көмәнен алалар, корбаннарының киемнәренә ут төртеп, карап торып яндыралар, кайберләрен ат койрыгына бәйләп, урам буйлап йөртәләр.

Безнең Яңа Шалты авылында да фетнәчеләр халык армиясе төзибез, дип, белдерәләр. Тик авылдан берәү генә дә бу армиягә язылмый. Ә, киресенчә, бик күпләр төн җиткәч, әрәмәлекләргә, тауларга китеп кача, кайберәүләр «Кызыл патизан» отрядына барып юлыга. Картлар: «Идиятуллла белән Вәлкәй шул отрядта иде», – диделәр.

Бу вакыйгаларның барышына минем Сәмигулла бабамның әтисе Шәрифулла да зур йогынты ясаган. Эш эшләргә, дөнья көтәргә бик һәвәс булган ул. «Алтын куллы бәндә булды, эшләмәгән эше юк иде аның. Оста игенче дә, бакчачы да ул, терлекләрне дә бик яратып карады. Күп балалы гаиләдә туып үскәнгәме, бөтен эшнең тәмен белә иде. Мул итеп ашлыгын чәчеп урдылар, яшелчәсен дә, җиләк-җимешен дә үстереп саттылар», – дип сөйли торган булган анын турында авыл картлары. Авыл халкы бик нык хөрмәт иткән аны. Бөтен тапкан малы күпме тир түгеп, көнне төнгә ялгап эшләү нәтиҗәсе булган. Аңа вакытлыча ялланып эшләүчеләрне кыерсытмаган, гадел булган, кирәгенчә түләгән, алар белән бергә утырып ашын да ашаган. Үзенә дә, якыннарына да, аның кул астында ялланып эшләүчеләргә дә бик таләпчән булган. Ярдәмгә бик мохтаҗларга ярдәм иткән. Авылдашларына вакытында кирәкле киңәшләрен дә бирә белгән.

Фетнә башлангач, Башкорт ягыннан килеп, безнең авыл кешеләрен Бәләбәйгә, сәнәкчеләр аеруча котырган якларга, Совет яклы кешеләрдән үч алырга өндәп, отряд җыеп йөргәннәр. Шунда Шәрифулла бабам авыл кешеләрен туган туганын үтерә торган сугышка җибәрмәгән. Сәнәкчеләрнең коточкыч вәхшилекләре турында ишетеп, хәбәрдар булган ул. «Анда сезгә ни калган? Кеше каны коеп йөргәннән соң, сезнең үз гаиләләрегез исән калыр, дип уйлыйсызмы?!» – дигән. Бабамның абруе шулкадәр зур булган, бу сүзләрдән соң авылның бер генә кешесе дә сәнәкчеләргә кушылмаган. Берникадәр вакыттан соң күрше авыл сәнәкчеләре Бөгелмәдән килгән партия эшлеклесен эзәрлекләп, Шалты буйлап эзләп йөргәндә, бабам аны үзенең өй базында буш кисмәк эчендә качырып, коткарып калган.

1918-нче елның көз айларында, Ленин декреты нигезендә, крестьяннарга җир бүленеп бирелә. Тик җир алуның шатлыгы зур булмый. Чөнки күпчелекнең җирне эшкәртү өчен аты да, сабаны да, ә чәчәр өчен ашлыгы да булмый.

### *Гражданнар сугышы. Чапаев дивизиясе Шалтыда*

«1919-нчы елның май ае, унберенче май кебек хәтердә. Без Хисмәтуллалар белән кырда идек. Хисмәтуллла авылга кайтып килде. Килеп җиткәч, озак кына сүзен әйтә алмый торды һәм: «Салихка аклар килгән. Тиздән Шалтыга да киләчәкләр», – диде. Без, эшләребезне ташлап, авылга кайтып киттек». Бу Колчак гаскәрләре калдыклары иде. Аларны озак сугыштан соң, Чапаев дивизиясе Богырысланда тар-мар иткән була.

Безнең авылга, кара каргалар ябырылгандай, аклар килеп керде. Алар авылның төрле йортларына кереп, аш пешерүне таләп иттеләр, төрлечә җәберләделәр. Мылтык тerәп ату белән куркыттылар. Бу тәмле ашап кына өйрәнгән буржуй, мулла балалары «менә ит ашыйбыз», дип кенә

торганда, авылда: «Кызыллар килә!» – дигән тавыш янгырады. Әйе, бу Чапаевның атаклы 25-нче дивизиясе Оренбург, Башкортостан якларын аклардан чистарта килеп, Габдрахман ягыннан безнең авылга килеп керәләр иде. Шалтыга 225-нче полкның 75-нче бригада солдатлары, ә соңрак командиры И.С. Кутяков булган 73-нче бригада да килеп кушыла.

Аклар, тревога күтәреп, жыйналдылар, ничек кенә булса да кызылларны тоткарларга тырыштылар. Кызылларга авыл крестьяннары да булыша. Алар абзар, йорт ышыгыннан акларга аталар. Яралы солдатларга ярдәм күрсәтәләр, азык белән тәэмин итәләр. Аклар, Урыстамак авылына таба чыгып, Сөярмәтнең очлы тавы башына урнашалар. Ә кызыллар, пушкаларын мәчет түбәсенә урнаштырып, акларга ут ачтылар.

«Аклар халыкның бик күп малларын, азыкларын талап алдылар. Кызыллар килеп кергәч, алар барысын да ташлап качтылар. Халык бу әйберләрне җыеп, кызылларга тапшырды. Рәтамак ягына чыгып, акларга бер кеше, хәйләләп: «Кызыллар Шалтыдан киттеләр инде!» – дигән. Аклар яңадан безнең авылга килә башладылар. Авылга якынлашкач, аларның күбесен безнекеләр кырып ташладылар. Кызыллар ягында бик күп татар егетләре бар иде, алар сугышкан вакытта мөселман киемендә сугыштылар. Авылга басып кергән аклар халыкны төрлечә җәберләделәр, сарыкларын, сыер, атларын талап алдылар, суеп ашадылар. Кешеләрне йортларыннан куып чыгардылар. Кызыллар армиясе сан ягыннан да берничә тапкыр артык иде. Аклар халыктан талап жыйган малларын ташлап качарга мәҗбүр булдылар». (Вәһапов Бәдертдин абый сөйләве буенча 1966-нчы елда язып алынды).

***Шалтыдан чапаевчылар***

«1919-нчы елның язы иде. Акларны куып, Шалтыга кызыллар килеп керде. Күперне аклар шартлатып киткәнлектән, чапаевчылар безнең авылда өч көн тордылар. Мин дә, үзем теләп, Чапаев отрядына язылдым. Кулыма мылтык алдым. Иптәшләремдә пулемет, кылыч, пушкалар иде. Ык елгасы аша салынган күперне рәтләгәч, без акларны куып, Рәтамак, Кушкаран аша Бәләбәйгә киттек. Шулвакытта Чапаев безгә үз кулы белән 300 сум акча бүләк итте. Бу дивизиягә безнең авылдан үзләре теләп 38 кеше язылды». (Чапаевчы Мирсәяпов Динмөхәммәт абый сөйләве буенча 1966-нчы елда язып алынды.)

Чапаев үзе Шалты аша үтми, ә Башкортостан буйлап, Ыкның уң яры буйлап акларны куа. Исән чагында Газыйм бабай Канипов: «Чапаев артиллеристлары белән Сөярмәт аша узды. Алар Ык аша башкорт ягына чыгарга омтылган акларның кирәген бирделәр», – дип сөйли иде.

91 яшьлек Шәйдуллин бабай болай дип искә ала иде: «Без эти белән өянке кисә идек. Габдрахман авылы ягыннан унлап кылычлы-сөңгеле

җайдаклар авыл читендә туктады. Икесе авыл эченә кереп безнең тыкрык аша өске урамга менә башлады. Кызыллар мулланың абзар түбәсеннән, Мирза Сәмигуллин агайның лапас түбәсеннән ата башладылар. Аклар кире борылып чаптылар. Кандыз елгасы аша салынган күпергә кергәндә, бер атның корсагына пуля тиде. Ул авыл башындагы сөргән җиргә чыгып җан бирде. Хуҗасының да эченә пуля тигән булган. Кемнеңдер мич башына яшеренгән җиреннән аны алып чыгып, күпер буендагы тимер алачыгы каршында атканнар һәм күмгәннәр, дип сөйлиләр. Кабере, әлбәттә, билгесез. Ләкин анда корбан булган солдат гаепсез иде».

82 яшьлек Имаметдин абый Сәяхов сөйләвеннән: «1918-нче елның көзе. Иртән әни белән казларны ашатып, келәтне яптык. Бездә әсир мадьяр солдаты тора иде. Ишегалдына өч ат җиккән тарантас килеп керде. Аннан аркылы-торкылы каешлар белән кылыч, мылтыклар таккан офицерлар сикереп төштеләр. Алар артыннан корал төягән өч олау килеп туктады.

Бабай иртәнге намазын укый иде. Ул сәҗдәгә тезләнгән чагында берсе наганын чыгарып, бабайның артына терәде, ләкин атмады. Алар келәттәге биш-алты казның муенын кылыч белән чаптылар да, күрше хатын-кызларын җыеп йолкыттылар, тазарттырдылар. Аннан соң тураклап казанга тутырдылар. Аларның пешкәнен көтеп утырганда берсе урамнан йөгереп керде дә, кызылларның килүен хәбәр итте. Алар ашык-пошык кына җыендылар да, атларын җигеп, урам буйлап Ык күперенә чаптылар. Корал төялгән бер арбалары калды. Чөнки бер атлары аксаган иде, аны аягына бастыра алмадылар. Ул чагында аларда ат кайгысы да, корал кайгысы да калмаган иде.

Без үзебезнең атларны әрәмәгә яшергән идек. Озак та үтмәде, Ык күпере янды. Аклар Сөярмәт ягына чыгып, артларыннан күпергә ут төрткәннәр. Кичкә таба авылга кызыллар килеп керде. «Пәриле тау»га тупларын куеп, Ык аркылы Сөярмәт тавына аттылар. Безгә дә килеп керделәр. Ишегалдындагы кораллар төялгән арбага безнең атны җиктереп (без аклар киткәч, аларны яшергән әрәмәдән алып кайткан идек), әтине үзләре белән алып киттеләр.

Капка төбендә бер буралык каен бүрәнәләре ята иде. Кызыллар аны Ык буена ташып, күпер салып, Уфа ягына киттеләр. Әтине Чишмә стансасына җиткәч кенә аты-ние белән кайтарып җибәргәннәр. Унбиш көн дигәндә, исән-сау әйләнеп кайтты, Аллага шөкер!»

Авыл картлары «Шалты авылы революция, Гражданнар сугышы чорында алтмыштан артык ир-егетен югалтты», – дип сөйлиләр иде. Революция алдыннан җитмешкә якын шалтылы армия сафында була. Күбесе 1914-нче елны сугышка алынганнан соң кайтмаган була. Патша армия-

сендә хезмәт иткән егетләрнең кайсылары аклар ягында, кайсылары кызыллар ягында торып сугыша. Шуларның бер унбишләбе генә өйләренә, яраланып булса да, кайту бәхетенә ирешә. Чапаев дивизиясе белән киткәннәрнең дә дүртесе генә исән кала. Моннан башка, аклар белән авылда булган бәрелештә дә үлүчеләр булган.

«Илгә төшкән бәла – һәр иңгә төшкән бәла. Ялгыз башка төшкән хәсрәт авыр була. Шунысы килмәсен, бу мәхшәр озакка бармас», – дия-дия, хәтәр елларны кичерде авылым халкы.

1921-нче елда Идел-Чулман буйларында коточкыч ачлык хөкем сөрә. Җәй буена җиргә бер генә тамчы яңгыр да төшми. Уннарча мең кеше ачлыктан кырыла. Хәтта этләрне, песиләрне дә ашап бетерә халык. Авылда халык саны бик нык кими. Габдулла бабай (ул 1903-нче елда туган) болай дип сөйләгән иде: «Сугыш халыкны күпләп кырды, дип әйтмәс идем мин. Халык 1921–1923-нче елларда ачлыктан күпләп үлде. Бу елларда бер көн эчендә икешәр-өчәр мәет күмгән көннәр булды. Ә шулай да, халык инсафлырак, мәрхәмәтлерәк иде ул елларда».

Ул еллар «Алабута елы» дип тарихка кереп калган. Күп кешеләр әнә шул алабута, кыргый үләннәр ашап исән калдылар да.

### *Коллективлашу юлында*

Беренче адымнар. Авылның хәле, халыкның тормышы беркайчан да җиңелдән булмаган. Шалты басулары таулы, чокыр-чакырлы, ташлы булганлыктан, иген әллә ни уңмаган. Халык гасырлар буе кинәнеп икмәк ашый алмаган. Ачлык золымыннан котылырга ниятләптер инде, 1920–1930-нчы елларда авылдан хәтсез кеше Себергә, казакъ, үзбәк якларына китә. Кара язмыш дигәнең анда да артларыннан калмаган икән. Себер якларында кара урман төпләп тә, казакъ-үзбәкләргә мамык җыеп, чиксез зур куй көтүе көтеп тә, алар чын бәхетне таба алмаган. Күбесе ике-өч елдан ертык язмышларын сынаганнан соң, туган туфракка кайтып егыла.

1920-нче елда Татарстанда коммуналар оеша башлый. 1923-нче елда авыл активыннан өч кеше: Гәбделкаһир Сәмиков, Хәйбулла Насыйбуллин, Сәхип Масаевлар хәзерге Азнакай районы Сукаеш авылына барып, Татарстанда иң яхшы эшләп килгән «Якты юл» коммунасының эше белән танышып кайталар. Аның җиттәкчесе Шәйми Шәвәлиев колхозлар оешкач та әле, озак еллар колхоз председателе булып эшли. Кайткач, авыл активы тынычлык белми. Совет йортына алар беркөнне зур җыен җыялар. Килми калган кеше булды микән ул җыелышка? Барысы да шылт та итмичә чыгыш ясаучыларны тыңлый, һәркем дулкынлана. Коммунаны хуплаучы да, ачыктан-ачык янаучысы да җитәрлек була. Халык күңеленә коткы салырга маташучылар да юк түгел. Ләкин коммуна

яклылар җиңеп чыга. Шул җыелышта ук тугыз кеше коммунага языла. Ә бер елдан коммунаның инде эшкә яраклы утыз җиде кешесе була. Землемер килеп аларга уртак сөрү җирләре, печәнлек болын, ул чагында унбер дисәтинә исәпләнгән Каенлыкны бүлеп бирә. Артель хезмәткәрләре иген белән бергә яшелчә дә үстерәләр. Барлык эшләрдә башлап йөрүче, ат шикелле җигелеп эшләүче Инсаф Мифтиев була. Ул колхозга кергәч тә иң алдынгы колхозчы булып, районга, республикага танылa. Һәм Инсаф ага Мифтиевнең исеме Мәскәүләргә дә ишетелде. Ул колхозчыларның беренче съездына барып, авылыбыз, кешеләребез турында бөтен илгә ишеттереп сөйли. Инсаф ага М.И. Калинин, Н.К. Крупская кебек Совет дәүләтенең зур эшлеклеләре белән очрашып сөйләшеп, алар белән фотога төшү бәхетенә дә ирешә.

Үткәннәрдә гыйбрәт, сабак һәм нәтиҗә ясар өчен үрнәк бар. Бер телем икмәккә тилмереп, ярым ач, ялангач йөргән халык, күмәк эшләүнең ачлыктан коткаручы юл икәненә үзе нәтиҗә ясагандыр ул елларда. Шуңа да, колхозлашу башлангач, зур авыл саналган Шалтыдан берничә дистә кеше генә колхоз оешкан елны колхозга керми кала. Аларның да күбесе бай тормышлылар, җир эшкәртү өчен атлары, чәчүлек өчен ашлыгы җитәрлек булган крестьяннар була.

ТАССР Игенчелек Халык Комиссариатының архив фондында Баулы районы колхозларының еллык отчетлары сакланган. Анда Яңа Шалты авыл Советының Ленин исемендәге колхозы күрсәтелгән. Колхоз 1929-нчы елның 14-нче мартында оешкан. 1932-нче елның 1-нче гыйнварына колхозда 413 хуҗалык исәпләнгән, андагы гомуми халык саны 1849 га җиткән; сөрүлек җирләре – 3246 гектар, печәнлекләр – 418 гектар, көтүлекләр – 413 гектар, барлык җир мәйданы – 4076, 93 гектар тәшкил иткән; 441 аты, мөгезле эре терлекләрдән 145 сыеры, 126 үгезе, 137 танасы булган, 682 сарык, 46 дуңгыз үрчетелгән; тагы 4 ат, 4 сыер, 1 бозау, 1 дуңгыз абзары, 10 икмәк саклау амбары, 3 контора бинасы төзелгән; хезмәт инвентарьларыннан 180 сабан, 82 тырма, 5 культиватор, 5 чәчкеч, 9 ургыч, 6 лабогрейка, 1 печән чапкыч, 2 ат тырмасы булдырылган.

Беренче колхозчы Вәлиев Халик хатирәсе: «Коллективлашу Шалты авылында 1929-нчы елның мартында башланды. Колхозга беренчеләрдән булып Вафи Вәлиев, Харрас Низамов, Хаҗигали Шагалиев, Шәйдулла Хәсәнов, Шәйдулла Гобәйдуллин, Гарифулла Ханбеков, Латыйп Шафиков, Галим Мөдәррисов, Габдулла Сәмигуллин, Солтан Җиһангиров, Сәетшәриф Ибниәминов, Сәхибулла Сибгатовлар керделәр. Алар арасында мин дә бар идем. Колхозчыларның беренче жыелышы яшерен рәвештә авылдан читтә, Ык елгасы буенда үткәрелде. Башта нибарысы өч ат бар иде. Дәүләт безгә 17 ат бирде. Авыл зур булганлыктан, башта ике колхоз

оешты. Аның берсе – «Сталин» исемендә булып һәм аның белән Вәлиев Вафый җитәкчелек итте; икенче колхоз – «Гигант» дип атала иде һәм аның җитәкчесе Идиятов Хисмәтулла. Соңыннан бу ике колхоз берләшеп, Ленин исеме белән аталды. Аның рәисе буларак Вәлиев Вафый калды. Авыл советы рәисе итеп мине сайладылар. Беренче колхозчыларга башта бик кыенга туры килде, чөнки барлык эшләрне дә кул көче белән генә эшли ала идек. Соңыннан колхоз дәүләттән ургыч, лобогрейка, сеялкалар алды. Игенчелектә машиналар кулланыла башланды». (1967-нче елда язып алынды.)

Авылда техника. Яңа Шалтыда оешкан колхоз шулай әкренләп тернәкләнеп китә. Колхозга беренче трактор кайту зур вакыйга була. 1930-нчы елда беренче кайткан «Фардзон» тракторында Фәткуллин Хәлил эшли. Аның авыл буйлап беренче үтүен, кырга беренче буразналар сузуын бар кеше, бигрәк тә балалар, җыелып, тамаша кылалар. Бу авыл хуҗалыгын механикалаштыруның беренче карлыгачы иде. Фәткуллин җир дә сөрә, ашлык та суктыра. Соңрак колхозга комбайн да кайта. Аңа Вәлиев Вафый утыра. Ләкин ул машиналар хәзергеләрдән күпкә калышканнар.

Колхозга беренче машиналар кайткач, халыкның шатлыгы зур була. Тик менә шунысы гына борчый – аларны эшләтә белүче, хәтта йөртә белүче кеше дә булмый. Вәлиев Халик сөйләве буенча: «Беренче вакытларда гап-гади ургычны кабызып җибәрә белүче кеше табылмаса, 1935-нче елда колхозда 44 механизатор эшли иде инде». Колхоз кырларында 127 ударник колхозчы эшли, өч фермада 600 баш мал исәпләнә. Ферма маллары өчен 300 центнер силос әзерләнгән иде. 1935-нче елда колхозчылар дәүләткә ит, сөт, йон түләүне 100%ка үтәделәр. Бу аларның күмәк хуҗалыкта фидакарь хезмәтләре аркасында гына мөмкин булды.

Әмма кулак элементлары яшь колхозның уңышларына түзә алмадылар. Алар колхозга каршы котырту эшләре алып бардылар, Совет хезмәткәрләренә һөҗүмнәр оештырдылар. 1935-нче елда районда чыгып килгән «Колхоз» газетасы үзенең 22-нче санында кулакларның колхоз амбарыннан 10 центнер борчак урлаулары, ә 70 центнер борчакны 10 центнер вак таш белән катыштырулары турында язып чыкты. Шул ук газетаның 40-нчы санында кулак Габдуллин Җәббарның кара эшләре турында хәбәр итә. Ул үз ишеләре белән ялган акт төзеп, 20 центнер бодайны үзләштерә, совет кешеләренә карата коткы уята, ялган сүзләр тарата.

Кулакларның бу кара эшләренә җавап итеп, колхозчылар тагын да тырышыбрак эшлиләр, тагын да зуррак күрсәткечләргә ирешәләр. 1934-нче елда язгы чәчү 17 көндә тәмамланса, 1935-нче елда ул 7 көндә төгәлләнә.

Колхозда 7 бригада, һәрберсендә 2шәр звено. Звено һәм бригадалар үзара ярышып эшлиләр, нәтиҗәләрне чагыштыралар. Урак вакытында һәр көнне сугышчан битләр, стена газеталары чыгарыла, анда һәркемнең ничек эшләве чагылдырыла. Колхозчыларга эшләү өчен уңайлы шартлар тудырыла. Моның өчен ашханә, мунча, кое, ашлыкны суктыру өчен әвен, машиналар өчен ягулык саклаучы складлар, радиоприемниклар белән тәэмин ителгән ике кыр станы оештырыла. Бу бик дөрес адым була.

1936-нчы елда язгы чәчү вакытыннан алда төгәлләнә. Барлыгы 1500 гектар җир чәчелә. Иртә культураларны чәчү 104% итеп үтәлә. Колхозчылар Кәрәмов, Гәрәев, Шәфиков, Лотфуллин җир эшкәртүне 200–250% итеп үтиләр.

Халыкның мәдәни үсеше дә күзгә күренеп арта. Октябрь революциясенә кадәр авылда бары 32 кеше укый-яза белсә һәм өч кеше газета яздырып алган булса, 1935-нче елда наданлык бөтенләй диярлек бетерелә, 429 гаилә 644 газета һәм журнал яздырып ала.

ТАССР Үзәк Башкарма Комитетының архив фондында Салих волосте Бөгелмә кантоны Яңа Шалты авылы буенча 1930-нчы елда Каюмов Абдрахман, Сәмигуллин Гыйбадулла, Хәйруллина Мөсәвирәне кулакка чыгару турында белешмә сакланган.

«Колхоз төзегәндә зур гына ялгышлар да җибәргәләнде инде. Урта хәлле крестьяннарны кулакка чыгару, вак малларны җыю һәм башкалар булды. 1929-нчы елның язында Казаннан Курмаев дигән бер комсомол егет килеп, «Уңышлардан башлар әйләнү» дигән мәкаләнең эчтәлеген аңлатты. Шуннан соң колхозга мәҗбүри кертелгән кешеләр колхоздан чыгып бетте. Ләкин 1930-нчы елда яңадан колхозга барысы да үз теләкләре белән керделәр. 1930–31-нче елларда рәис булып егерме биш меңче Хәертдинов дигән иптәш эшләде». (Вәлиев Халик сөйләве буенча 1967-нче елда язып алынды.)

1970нче еллар башында авыл хуҗалыгына мөнәсәбәт үзгәрә. 1966-нчы елның беренче июленнән колхозчылар хезмәтенә гарантияле түләү кертелә. Тулаем алганда авыл хуҗалыгы белән идарә итүнең боерык бирү тәртибеннән икътисади ысулларга күчәргә, җитештерүчеләргә зур мөстәкыйльлек бирергә дигән максат куела. Мөнәсәбәт үзгәрүнең нәтиҗәсе озак көттерми. Сигезенче бишьеллыкта «Ленин» исемендәге хуҗалык саллы уңышларга ирешә. Бөртеклеләрнең уңышы 9,0 центнердан 22,4 центнерга кадәр җитә. Кайбер күрсәткечләр, тулаем алганда, район күрсәткечләрен дә узып китә. Сыер, дуңгыз фермалары, яңа мастерской төзелеше алып барыла.

Ул елларда колхоз белән Газиз Фәррах улы Ганиев идарә итә. Г.Ф. Ганиев (1924–1990) 1924-нче елның 25 гыйнварында Татарстанның Баулы районы Яңа-Шалты авылында туа, унбиш яшеннән колхозда эшли

башлый. 1942-нче елның гыйнварында ул Кызыл Армия сафларына алына, укчылар полкы белән Ленинград фронтында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Ике тапкыр каты яралана. 1943-нче елның ноябрендә красноармеец Г.Ф. Ганиев демобилизацияләнә. Сугышчан батырлыклары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Ленинград оборонасы өчен», «Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен (1941–1945-нче еллар)» һәм башка юбилей медальләре белән бүләкләнә. 1944-нче елның башында Г.Ф. Ганиев тыныч хезмәткә кайта. Җиде ел дәвамында колхоз бригадасын җитәкли, ындыр табагы белән идарә итә. Читтән торып Алабуга мәдәни-агарту училищесының библиотека бүлегенә укырга керә. Тик аны тәмамлагач та, колхозда ферма мөдире булып эшли. 1948–1964-нче елларда халык депутатларының Шалты авыл Советын җитәкли. Бу вазифада аның оештыру сәләтен күреп алалар һәм 1965-нче елда район Г.Ф. Ганиевны Казанга укырга җибәрә. Курсларны тәмамлаганнан соң, 1966-нчы елның февралендә, аны «Ленин» исемендәге колхоз рәисе итеп билгелиләр. Бу постта ул 18 ел хезмәт итә. Үзенең таләпчәнлеге, колхозчылар өчен янып йөрүе белән авылда гына түгел, район, республика күләмендә дә дан казанды. Газиз Фәррах улы эшләгән дәвердә колхоз зур уңышларга иреште, халыкның тормыш хәле яхшырды.

Дәүләт хуҗалыкның бу уңышларын югары бәяләде. Күп белгечләр дәүләт орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде. Ганиев Газиз – Октябрь революциясе ордены, Кыямов Гали – Ленин ордены, Шәрифуллина Тәзкирә – Кызыл Байрак ордены, Мөдәррисов Равил – Ленин ордены, Мәрдәншина Фәния Октябрь революциясе ордены белән бүләкләнделәр. 1978-нче елда ирешкән уңышлары өчен «Ленин» исемендәге колхоз КПСС Үзәк Комитетының һәм Министрлар Советының Күчмә Кызыл Байрагына лаек булды. Аны тапшыру өчен ул чакта легендага тиң Фикрәт Табеев – КПСС өлкә комитетының беренче секретаре – үзе килде. Чеп-чи татар авылы халкы каршында урысча чыгыш ясап, халыкны шаккаттырды.

1970-нче елларда безнең колхоз күп техникасы булган алдынгы хуҗалыкларның берсенә әверелә. Колхозда барлыгы 11 йөк машинасы, 18 трактор, 7 комбайны бар иде. Тагылма инвентарьлардан: сабан, чәчкечләр, культиваторлар, кукуруза комбайны һәм башка күптөрле тагылма машиналары булганлыгы билгеле. Колхозыбыз тулысынча белгеч-механизаторлар белән тәэмин ителгән. Алар кулында корыч машиналар гөрләп кенә торалар. Алдынгы комбайнчы Гиззатуллин Нуретдин 1967-нче елның урыпҗыю чорында 223,5 гектар җир эшләп, 2694% уңыш җыеп алды.

Ферма салдык. Колхозга оешу дәверендә «Колхоз-союз»дан 16 баш сыер бирделәр. Колхозга керүчеләрдән җыелган сыерлар белән барлы-

гы 90 баш сыер булды. Ләкин аларны тотарга абзар юк. Шуңа күрә ул малларны яңадан 1–2 ел халыкка таратып торырга туры килде. Сыерлар фермасы башта элеккеге колхоз идарәсе урынында иде. Ә инде 1933-нче елларда председатель Хәлимов вакытында саламнан кирпеч сугып, ферма салдык. 1950-нче еллар башында авылга дәүләт линиясеннән электр энергиясе килә. Бу авыл өчен бик зур әһәмияткә ия була. Һәрбер өйдә «Ленин лампочкалары» яктырта башлый. Махсус курслар тәмамлаган Имаметдин Сәяхов озак еллар буе электр линияләренең төгәл эшләвен күзәтеп, кайгыртып торды.

Яңа Шалтының ике зур тегермәне бар иде. Түбәнге тегермәндә староверлар – Андрей, соңрак аның улы Фокий эшләде. Югары тегермәндә Сафакай Саниев хуҗалык итте. Ләкин он тарттырганда тегермән ташы ярылып, Сафакай аганы таш басып үтерә. Шуннан соң ул тегермәнне бетерәләр. Түбәнге тегермәндә аның улы Камил Саниев соңгы тегермәнче була. Авылда инде күптән су тегермәннәре юк. Колхоз таралу сәбәпле, авылда тегермәннәр бетте. Баулы ягыннан авыл башына кергәндә һәрбер юлаучыны иске тегермәннең җимерелеп барган бинасы каршы ала. Бу җитмешенче елларда төзелеп, электр көче белән эшли торган тегермән, су тегермәннәре кебек онны бик чиста һәм сыйфатлы итеп тартмаса да, күп еллар буе авыл халкының һәм күрше-тирә авыл кешеләренең ихтыяҗларын канәгатьләндереп килде.

### *Язмышлар һәм ялгышлар*

Революциягә кадәр авыл өч мәхәлләгә бүленгән. Һәр мәхәлләнең үз мәчете булып, авылга ямь биреп торганнар. Мәчетләргә указлы муллалар беркетелгән. Алар мәчетнең төзеклеге, малайларны укытуга, намаз, гаетләр укуга җаваплы булганнар. Якын-тирә авыллардан Шалты мәчетләренең төзеклеге, зурлыгы, ә муллаларының укымышлылыгы белән аерылып торган.

Самара губернасы Бөгелмә өязе Яңа Шалты авылының 1908, 1914-нче елларда язылган метрика китабында түбәндәгеләр күрсәтелә:

Беренче мәхәлләнең имам-хатыйбы һәм мөгаллиме вазифаларын башкаручы итеп 1887-нче елның 11-нче июленнән Ярулла Габделвахит улы билгеләнә. Ул 1853-нче елның 14-нче гыйнварында Яңа Шалты авылында туган, Бөгелмә өязенең Тымытык авылында укыган.

Икенче имам – Габделҗәмил Габделхалик улы, 1836-нчы елда туган, бу эшкә указны ул 1864-нче елның 8-нче гыйнварында алган.

Мәэзин – Фәләхетдин Габделгали улы, 1850-нче елда туган, указны 1896-нчы елның 31-нче июлендә алган.

1914 елда беренче мәхәлләнең халкы 729 кеше булган, шуларның 359-ы – ир-ат, 370-е – хатын-кыз.

Икенче мәхәлләнең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе булып Габделкасыйм Мөхәммәтрәхим улы тора, 1844-нче елда туган, Стәрлебаш мәдрәсәсендә укыган.

Икенче имам – Хөснетдин Гатаулла улы, 1847-нче елда туган, указны 1887-нче елда ала, Стәрлебаш авылында укыган.

Мәэзин – Низаметдин Шиһабетдин улы, 1860-нчы елда туган, указ 1887-нче елда бирелә, Бөгелмә өязенең Байрак авылында белем алган.

Икенче мәхәлләнең халкы 1914-нче елга – 701 кеше, шуларның 647-се – ир-ат, 654-е – хатын-кыз.

Өченче мәхәлләнең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе булып 1910-нчы елның 23-нче мартыннан Габделрәхим Габделрафик улы Габделхаликов эшли, 1880-нче елда туган, Бөгелмә өязенең Тымытык авылында укыган.

Икенче имам – Кагабүльәкбәр Ярулла улы, 1879-нчы елда туган, указны 1910-нчы елда алган, Бөгелмә өязенең Тымытык авылында белем алган.

Мәэзин Гәбделгазиз Гәбделҗәмил улы Хәсәнов, 1881-нче елда туган, указны 1910-нчы елда алган, Бөгелмә өязенең Тымытык авылы мәдрәсәсен бетергән.

Өченче мәхәлләнең халкы 1914-нче елда 554 кеше тәшкил итә, аларның 276-сы – ир-ат, 278-е – хатын-кыз. Самара губернасы идарәсе рөхсәте белән, бу мәчет 1908-нче елның 28-нче августында төзелә.

Революциядән соңгы елларда Шалтының Урта урам мәчетен Фәррәхетдин мулла караган, Түбән очныкын – Низаметдин мулла, ә Яңа урамныкын Гаптерәкыйп мулла караган. Авылда указсыз муллалар да булган. Мисал өчен, Әкбәр һәм Шадыр муллалар шундый.

Билгеле бер яшькә җиткәч, малайлар муллага укырга мәчеткә, ә кызлар өйдә абыстайларга йөргәннәр. Укыткан өчен сәдака тәртибендә, хәленнән килгәнчә, акчалата, ризыклата, әйберләтә түләү булган.

Һәр мулла үз мәхәлләсендәге халыкның төгәл хисабын алып барган. Туу, үлү, солдат хезмәтенә, кая да булса эшкә китүнең төгәл датасы язылып барылган. Мулла шулай ук халыкның тәртибен, инсафлыгын да кайгыртткан.

1930-нчы елларда Рәсәйдә руханиларга, дин әһелләренә карата каты эзәрлекләүләр башлана. Аларны сөргенгә озаталар, төрмәгә ябалар. 1939-нчы елның җәендәТүбән оч мәчетенең манарасын аударалар, 1940-нчы елда Урта мәчетнекенә дә чират җитә. Ә 1941-нче елның җәендә Яңа урам мәчетенең манарасын бау белән тартып аударалар. Аның ничек ыңгырашып жиргә ярым ае белән кадалып төшүен күреп, күпләрнең күзләреннән яшь атылып чыга. Манараларны авыл кешеләре Рәхмәтулла Хәмидуллин, Сәфиулла Ханбәков, Лотфулла Инсапов, Җамалетдин Фәр-

рахов, Шевцов, Митяевлар кистеләр. Аларның барысы да сугышка киттеләр, тик берсе дә кире әйләнеп кайтмады...

Авылдагы муллалар арасында Урта урам мулласы Гаптелгани улы Фәррәхетдин үзенең укымышлылыгы, халыкка яхшы, гадел мөгаләмәсе белән аерылып торган. Үзе белгәннәрне шәкертләренә өйрәтү өчен көчен дә, вакытын да кызганмаган.

Муллалар, күп еллар ышандырып килгәнчә, бал-май эчендә йөзгәннәрме соң? Юк, билгеле. Мисал өчен, Фәррәхетдин мулланын бер аты, бер сыеры, сарыклары, түбәләре балчык белән ябылган иске һәм яңа йорты булган. Рауза абыстай белән алты бала тәрбияләп үстергәннәр. Кызлары Закирә, Сорур, Әминәне, улары Габделгазыйм, Габделгазиз һәм Хәйбулланы эш сөючән, динле, Алланы олуг күрүчән, кешелекле, мәрхәмәтле кешеләр итеп тәрбияләгәннәр.

В.И.Ленин үлгәннән соң, илдәге буталчылык тагын да көчәеп китә. Һәр төбәктән сыйнфый дошман эзләү, һәр кешедә революция дошманы күрү шул дәрәҗәгә җитә ки, кемнең кем икәнен уйлап та тормыйча, өенә килеп алып, кайдадыр озату бернәрсә дә тормый башлый. Ә Фәррах мулла кайсы ягы белән властьларга ошамый? Мулла булуы белән. «Дин – искелек калдыгы, ә муллалар аларны саклаучы», – дип ягышалар ул заманада. Бәлки, халыкта булган шәфкатьлелек, иманлылык, кешелеклелекнең тамырына чабу, муллаларны мәсхәрә итүдән, аларны Себергә озатудан башлангандыр да. Кем белә?

Утызынчы елларның явыз шаукымы Шалтыга да килеп җитә. Әминә ханым менә ниләр сөйли: «Без байлар түгел идек. Ул чорда алты баланы ач-ялангач итмәү өчен генә дә шактый күп тырышырга кирәк булган. Әткәй-әнкәй өйдә үзләре дә эшләде, безне дә тик тотмадылар. Авылга «байларны, алар белән муллаларны да Себергә озаталар», кебек хәбәрләр килеп ирешкәч, әткәй: «Балаларым яшь, мине алып китсәләр, ни эшләрләр?» – дип борчылып, ашаудан, йокыдан калып йөргән бер мәлдә, кәнсәләргә чакырттылар. Сорау алгач, Баһау бабай, Низаметдин, Гаптерәкыйп муллалар белән кара Хәйбулла йортына илтеп яптылар. Бу хәл әткәйгә бик авыр тәэсир иткән, анын хәле күзгә күренеп начарланган. Ул шул йортта үлеп тә китте. Авылга килгән судья: «Ярмыйча күммибез», – дип китә. Ике тәүлек Поповкадан Каштанов дигән врачның килгәнен көткәннәр. Ул әткәйнең инфарктан үлгәнлеген әйтте. Ярганда күкрәгендә пычак сынды. Бу хәл 1932-нче елның 3 декабрендә булды. Соңыннан колхозга кереп, тырышып эшләдек. Тормышыбыз тернәкләнде.

Фәррах мулланың алты баласыннан бүгенге көндә дистәләгән оныгы һәм оныкларының балалары бар. Алар арасында нинди генә профессия

ияләре юк: врачлар, укытучылар, ветеринария врачлары, зоотехниклар, юристлар, инженерлар һәм башкалар. Күп еллар буе Баулы НГДУына Фәррах мулланың оныгы Гали Газиз улы Ганиев җитәкчелек итте. Хәзерге көндә ул ООО «ТаграС-Холдинг»ының генераль директоры булып эшли. Икенче оныгы Ильшат Газыйм улы Ганиев республикабыздан читкә даны таралган «Майский» агрохолдингының директоры. Фәррах мулллaның үз малае Газиз Фәррах улы Ганиев озак еллар буе Шалтыда «Ленин» исемендәге колхозның рәисе булып эшләде.

Шунысы аяныч: бүгене көндә замана җилләренең шаукымы тигәнме – кайчандыр гөрләп торган колхоз таралган. Зур итеп салынган ферма биналары мал-туарсыз, инде җимерелеп бара. Кыр-басулар ярым буш. Күрше «Берлек» хуҗалыгы эшчәннәре җирләребезне арендага алып ашлык үстерәләр икән. Авылда эш булмау сәбәпле, яшьләр авылдан китә. Шалтының киләчәге зур шөбһә уята.

Әмма шунысы куанычлы: Яңа Шалтыда, Баулы районында беренче булып, 1992-нче елда мәчет эшли башлады. Сәгыйт Саниевның тырышлыгы белән Түбән оч мәчетенең манарасын яңадан күтәрделәр. Моңа бөтен авыл халкы һәм ул вакытта эшләп килгән «Шалты крестьян хуҗалыклары берлеге» шактый зур өлеш кертте. Казанда кече предприятие җитәкчесе булып эшләүче Илгизәр Насыйбуллинның мәчеткә күрсәткән матди ярдәме бик күпләрне сокландырды. 1998-нче елда Шалтыда яңа мәчет ачылды. Өр-яңа мәчеткә Фәррах мулла исеме бирелә. Алдарак әйтеп үткәнемчә, революциягә кадәр Фәррах мулла Урта урам мәчетенең мулласы булып торган һәм авыл халкы өчен күп яхшылыклар эшләп калдырган. Мәчеттә имам-хатыйплыкны Фәррах мулланың оныгы Мәгъҗәнов Әсгать алып бара. Авылыбызда рухи яңарыш күзгә күренеп сизелә. Аңа иман нуры керде. Барча мөселманнарның күңелләрен шатландырып, Яңа Шалты авылы өстендә азан тавышлары яңгырый.

***Мәктәп төзелү***

Революциягә кадәр безнең Яңа Шалты авылында аерым төзелгән мәктәпләр булмаган. Мәдрәсәләрдә муллалар балаларга төрле дини сабаклар биргәннәр. Бөек Октябрь революциясеннән соң авылыбызда да халыкның көн-күреше яхшыра барган саен, аң-белем алу теләге арта бара.

ТАССР Мәгариф Халык Комиссариатының Бөгелмә кантоны буенча 1921-нче елгы архив фондында 1-нче дәрәҗәле Яңа Шалты гомуми татар хезмәт мәктәбе күрсәтелгән. Мәктәп 1917-нче елда ачылган, аның элеккеге исеме – Церковно-приходская. Мәктәпнең бер үз бинасы, ике башка бина наемга алынган була. Йортлар агачтан салынган, керосин лампасы белән яктыртылган, мич ягып җылытылган. 1921-нче елның 1-нче гыйнварына 124 укучы исәпләнгән, шуларның 49-ы – малай, 75-е – кыз.

Укытучылар составы:

Шәмсия Харис кызы Габдуллина, 19 яшь, татар, татар урта мәктәбен һәм 2 еллык Бөгелмә укытучылар хәзерләү курсын тәмамлаган. Эш стажы 1916-нчы елдан. Габдуллин Мәльгасыйп, 25 яшь, татар, татар урта мәктәбен һәм 3 еллык Бөгелмә укытучылар хәзерләү курсын тәмамлаган. Эш стажы 1917-нче елдан. Насыйбуллин Гариф, 27 яшь, татар, татар урта мәктәбен тәмамлаган. Эш стажы 1920-нче елдан. Мөхитулла Хисмәт улы Идиятуллин. 1920-нче елда Яңа Шалты авылында туган.

*2003-нче елның 23 августында Яңа Шалты мәктәбенең хәзерге буын укучыларына язылган мөрәҗәгате һәм истәлекләре.*

«Октябрь революциясеннән соң зуррак авылларда яңа мәктәпләр төзү, яңа программа буенча укыту эшләре җәелеп китте. Моңарчы яшәп килгән мәктәпләр «мәдрәсә» дип аталып йөртелделәр. Яңа Шалты авылында типовой төзелештәге мәктәп салу эше 1927-нче елда башланды. Бу елларда авыл Советы рәисе Шәрәпов Мөхәммәтдин һәм аның ярдәмчесе Идиятов Хисмәтләр (бусы минем әткәй) тырышлыгы белән башкарылды. Безнең әткәй Башкортостан ягына чыгып, хәзерге Серафимовка тирәсендәге «завод урманы» дип аталган зур урманда мәктәп йортын буратты. Бураны 1928-нче елны «Бай Каһир» дигән кешенең ындыр урынына күтәреп куйдылар. Шушы яңа төзелә торган мәктәптә эчке эшләр төгәлләнеп тә бетмәстән, ашыгычлык белән 1928-нче елның беренче сентябреннән бер бүлмәнең эшен бетереп, безне беренче класска җыеп, укыта да башладылар. Ата-аналар да яңа мәктәп ачылуга чиксез шатландылар. Моңарчы балалар «мәдрәсә» дип атала торган кечкенә генә йортта дүрт класска чаклы укыйлар иде. Анын мөдире Зәйдуллин Гатият абый булды. Яңа типовой мәктәп төзелгәч, яңа укытучы Хәкимов Зәки мөдир итеп билгеләнде (ул үзе Ютазы кешесе иде). Авыл халкы каршында аның дәрәҗәсе бик югары булды. «Укытучы Зәки Хәкимов» дигән исем белән мәктәпнең печате дә бар иде. Безне беренче класста Үтәмишев Мирза абый укытты.

1932-нче елны дүртенче сыйныфтан соң без «Башлангыч мәктәпне тәмамлады» дигән таныклык алып чыктык. 1932–33-нче уку елыннан башлап «Тулы булмаган урта мәктәп» дип аталган җидееллык мәктәп эшли башлады. Шушы мәктәпкә тирә-як авыллардан: Чүте, Хәнсевәр, Салих, Габдрахман, Сөyрмәт, Эрәтамак авылларыннан килеп укый башладылар. Бишенче класстан башлап, «а», «б» класслары дип исемләнеп, икешәр сменада укыдылар. Мәктәп каршында 70–80 бала торырлык тулай торак бар иде. Балаларның белем алуга, укырга теләкләре бик зур булды. Ата-аналар да барлы-юклы хәлләре белән балаларын ничек булса да укытып, белемле кеше итәргә тырыштылар иде. Дүрт сыйныфлык бе-

леме булган кешеләр колхозда хисапчы, ферма мөдире, агротехник булып эшли ала иделәр.

5–7-нче классларда «Авыл хуҗалыгы нигезләре» дигән фән укытыла иде. Ул фәнне Хәтирә Сәетова укытты. Без классыбыз белән кырга барып, чәчү вакытында жирнең мәйданын үлчәп чыгарабыз. Бер гектар җиргә күпме бодай, күпме солы һәм башка культураларны чәчү нормасын билгелибез. Чәчкечне (ул вакытта тракторлар юк, атка сеялка тагып чәчәләр) ничек көйләргә өйрәнәбез. Фермага барып, сыерның тереләй авырлыгын тасма-метр белән үлчәп-исәпләп чыгарабыз. Силос базының күләмен билгелибез, ул базга ничә тонна силос салынган, ул азык ничә баш сыерга җитә һ.б. Без укытучыга сораулар биреп, ничек булса да ул фәнне белергә, үзләштерергә тырыша идек. Мәктәптә укытыла торган һәр фән күргәзмәле итеп практикага бәйләп үткәрелде.

Мәктәптә беренче тапкыр пионер оешмасы 1933-нче елда эшли башлады. Безнең муенга кызыл галстук бәйләделәр. Галстук таккан килеш өйгә шатланып кайтып кердем. Инәкәй муендагы галстукны күрү белән тотынды әрләргә: «Камун» булгансың бит, бар, илтеп бир бу кызыл муенчакны, Алласыз!» – ди. Аннары өйгә кайткач, галстукны әнигә күрсәтмичә яшерә торган булдым. Өлкән пионервожатый – Нәбиева Камал апа иде.

1933-нче елда Шалты җидееллык мәктәбендә «мәктәп яны участогы (пришкольный участок) эшли башлады. Минем алтынчы сыйныфны бетереп, җиденчегә күчкән ел бу. Уку елы бетәр алдыннан укучыларны линейкага тезделәр дә: «Кемнәр үз теләкләре белән мәктәп бакчасында калырга тели, кул күтәрегез», – диделәр. Иң беренче булып мин күтәрдем. Без алты укучы участокта калырга риза булдык.

Бакчаның мәйданы 7–8 гектар чамасы булыр. Мәктәп кырыннан башлап әлеге тегермән яки автобус тукталышына чаклы иде. Ике гектарга якын бәрәңге, яшелчә түтәлләре, аннан соң арырак – арыш, бодай, ясмык (чечевица) чәчелгән. Шулар өстенә мәктәпнең ике аты, сыерлары бар иде. Җәй көне төн йокламыйча участокта чиратлап каравыл торабыз. Шуның өстенә колхоз кырыннан өч гектар борчак алып, йолыктык. Бу әзерлек барысы да алдагы уку елында мәктәп ашханәсендә кыш буе балаларны түләүсез ашату өчен иде. Мәктәп участогында без бик тату яшәдек. Күңелле иде ул вакытларда.

Яңа уку елы башлангач, безне мәктәп линейкасында мактадылар. Безгә 75 сум акча бирделәр. Ул акча кайдан җыелган соң, дип сорарсыз. Мәктәпнең 4 сыерының сөтен савып, машинада (ул чакта авылда маслозавод бар иде) аертабыз, майны базарда сатып, мәктәп кассасына җыябыз. Вәлиев Галми кассирыбыз иде. Менә шул җыелган акчаны безгә гадел

хезмәтебез өчен эш хакы итеп түләделәр. Бу безгә карата, үз чиратында, кызыксындыру формасы итеп тә бирелгәндер.

Яңа Шалты мәктәбенең 7 сыйныфында укыган вакытта миңа кышкы чорда дәрестән соң укый-яза белмәүче хатын-кызлар һәм олы яшьтәге ир-атларны укытырга куштылар. Ул «Ликбез мәктәбе» (ликвидация безграмотности) дип аталды. Аларны мәктәпкә җыеп түгел, ә аерым кеше йортында укыттык. Алар 16–17 кеше иделәр. Кыш узганчы шактый укырга-язарга өйрәнделәр. Ул чакта «Яңалиф» дип атала торган латин хәрефләре белән язылган газета килә иде. Минем укыткан хатыннарым газетаны да танып укый ала башладылар. Анда укыткан өчен РОНО хезмәт хакы түли иде. Киләчәктә укытучы хезмәтен сайларга миңа шул «Ликбез» мәктәбендә эшләвем ярдәм иткәндер. Мин кырык елга якын балалар укыттым.

Бу елларда безнең гаиләләр матди яктан бик авыр хәлдә яшәделәр. Авылдан сигез кешене – ирләрне, бер гаепсезгә «халык дошманы» дип, һәрберсен ун елга иркеннән мәхрүм итеп, алып киттеләр. Шул исәптән, минем әти – Идиятов Хисмәтне. Алар «Мәскәү-Идел» каналын төзүдә (җир казуда) эшләгәннәр, күбесе ике-өч елдан кайттылар. Безнең әти унөч айдан кайтты. Авылга кайткач, ягъни 1935-нче елның җәеннән башлап, колхозда ферма мөдире, аннан бригадир булып эшләде.

Яңа Шалты җидееллык мәктәбендә озак еллар Закирова Сара апа директор булып эшләде. Шалтыга Бөгелмә педагогика училищесын тәмамлап,1933-нче елда килде ул. Сугыш елларында (1941–45-нче елларда) бер үк вакытта авыл Советы рәисе вазифаларын да башкарган кеше. Шушы мәктәптән фронтка китеп һәлак булган мәктәп директорларын тарихыбызда онытмасак иде: Хәкимов Зәки (Ютазыдан), Әхмәтшин Садри (Димтамактан), Митрофанов Михаил Андреевич (Алабугадан), Гыйльфанов Нуретдин Хөснетдинович (Яңа Шалтыдан).

Бер истәлекне әйтеп үтәсем килә. Мин сугыштан соң шушы Яңа Шалты мәктәбендә алты ел укыттым (1946–51-нче еллар). 1950-нче елның яңа уку елын каршылап, мәктәп тирәсенә агачлар утырттык. Менә шушы мәктәп яны капкасының ике ягына минем хатыным Закирова Ракия белән ике тирәк утырттык (Аргы як Шәкүр бабайдан алып). Ул тирәкләргә хәзер илле өч яшь инде. Бу мәктәптә минем өчен моннан да зур, олы истәлек юктыр, мөгаен.

Миңа хәзер 83 яшь тулды. Үзе бер гасырга якын гомер узган. Сез, балалар, миннән сорарга мөмкинсез: «Мөхит Хисмәтуллович! Әйтегез әле: озын гомерле булып, озак яшәүнең сере нәрсәдә?» Җавап бирәм: «Сере шунда дип беләм – һәрвакыт үзеңнең сәламәтлегеңә игътибарлы булырга кирәк. Нервыларыгызны саклагыз. Димәк, кешеләр белән тату яшәргә

тырышыгыз. Ызгыш-талаш, юкка-барга кызып китеп бәхәсләшү кебек стресслар тудырмагыз. Ашау-эчү, туклану режимын саклагыз. Спиртлы эчемлекләр эчмәгез. Авырсагыз, халык медицинасы кушканча дәвеланыгыз, мунча керегез, парланыгыз. Һәрвакыт физик эш белән шөгыльләнегез, күбрәк җәяү йөрегез. Тормышта мөселманча яшәргә тырышыгыз. Мин ислам диненә бирелгән, мөселманча яшәүче кеше. Рамазан аенда бер көн дә калдырмыйча ураза тотам. Һәр көнне таң атканнан башлап биш тапкыр, бөтен шартларын җиткереп, намаз укыйм. Сәламәтлек өчен намаз укуның файдасы бик зур. Укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләгәндә дә физкультура фәнен үзем укыттым. Сабан туйларында йөгереп, бүләк алган чаклар еш була иде. Гомеремдә аракы һәм исерткеч эчемлекләрне даими эчмәдем. Тәмәкене бервакытта да, хәтта фронтта йөргәндә дә тартмадым. Минем гәүдә буем 1 м 63 см, авырлыгым 63 кг. Шушы чагыштырманы мин гомер буе диярлек үзгәртмәскә тырыштым. Унөч ел буена Баулы мәхәлләсендә имам булып тордым. 1995-нче елны Мәккәгә хаҗга бардым. Үзем 40 елга якын укытучы булу йөзеннән, балаларны бик яраттым, аларның шәхесен кимсетердәй тупас сүзләр әйтмәскә тырыштым. Шушы елда Яңа Шалты авылында урта мәктәп ачылуга илле еллык юбилей тантанасына миңа да катнашырга насыйп булды. XX гасыр дәвамында Яңа Шалты авылында булып узган мәктәп тарихын искә алып, сезнең белән уртаклаша алуыма мин бик шатмын. Күңелегездә иман нуры, киләчәккә яшәү дәрте-өмете бервакытта да сүрелмәсен. Бәхетле, тәүфыйклы булыгыз. Вакытлар үтү белән сезнең белән шушы очрашу мизгелләрен дә искә алыгыз.

Тәкъдимем:

Бу язмаларым мәктәп музеенда саклансын иде.

Хушыгыз! Сәлам белән Шалты мәктәбенең беренче укучысы буларак Мөхитулла Хисмәт улы Идиятуллин. 23 август 2003-нче ел».

*Яңа Шалты мәктәбе: саннар һәм фактлар:*

Яңа Шалтыда беренче ликбез (ликвидция безграмотности) 1918-нче елда эшли башлый.

1921-нче елда башлангыч белеме сыйныфы эшли башлый.

1928–29-нчы уку елында мәктәп – укучыларны беренче тапкыр үз бинасында кабул итә.

1932–1933-нче уку елында мәктәп – җидееллык, 1951–52-нче уку елында унъеллык статусын ала.

1953–54-нче уку елында мәктәпне беренче чыгарылышта – 36 егет һәм кыз тәмамлый. Әйтерсең лә бу ике класска укучыларның иң яхшыларын гына сайлап алганнар: 36 баланың 28 шул елны югары уку йортларына укырга керделәр. Шуларның икесе фәннәр кандидаты булды: Габсаби-

рова – медицина фәннәре, М. Баһауова – ветеринария фәннәре буенча. Тимерҗан Багманов –фән докторы, профессор. Мөсәгыйт Хәбибуллин – халык язучысы.

1978-нче елның беренче сентябрендә мәктәпнең яңа бинасы ачылды.

Шәхсән мин үзем мәктәп елларын сагынып, бик еш искә алам. Беренче укытучым Гатиятуллина Саимә апа күңелемдә һәрчак истә һәм ул миндә бары тик иң якты хисләр генә уята. 1976-нчы елның беренче сентябрендә безне, 26 малай һәм кызны, үз канаты астына алып, төрле холыктагы һәрбер баланың күңеленә ачкыч табып, күңел җылысын биреп, олы тормыш юлына әзерләде, Туган илгә, Туган җиргә мәхәббәт тәрбияләде, олыларга, әти-әниләргә хөрмәт белән карарга өйрәтте. Һәрберебезгә, һичшиксез, икенче әниебез булды.

Башлангыч белем алып, зуррак классларга күчкәч тә, шулай ук күңел җылысын биреп, могҗизалы белем дөньясына алып кереп, төрле фәннәрне үзләштерергә, дөньяны таный белергә өйрәткән зур хөрмәткә лаек кадерле укытучыларым Дания апа Шиһапова, Әлфия апа Ганиева, Заһит абый Ганиев, Фәүзия апа Абдуллина, Мөрсәлим абый Гыйләҗев, Ваския апа Кыямова, Наҗия апа Кучумова, Әсгать абый Шәрәпов, Флера апа Минһаҗева, Лотфулла һәм Зиннур Шәрифулиннар һәм башкалар булдылар. Кайбер укытучылар телгә алынмаган булсалар, зинһар, гафу итсеннәр инде. Алар барысы да минем күңелдә иң якты маяк булып калдылар.

Ләкин иң яраткан укытучым, минем дөньяда иң-иң якын кешем – ул әтием Зиннур Сәмигулла улы Шәрифуллин иде. Әйтергә кирәк, бер мин генә түгел, төрле елларда ул белем биргән күп санлы укучылары да аны бик яраталар, хөрмәт итәләр. Аңа карата булган бу олылау хисе риваять кебек буыннан-буынга күчеп, күңелләрдә мәңге сакланыр. Әле һаман да әтиемне авыл халкы зур хөрмәт белән искә ала.

Ул дәресләрне шундый мавыктыргыч итеп үткәрә, мәктәп программасыннан башка өстәмә мәгълүматлар белән дә бик оста баета белде. Әтием күпкырлы талант иясе иде. Ул шундый мавыктыргыч итеп биология фәнен дә, география, тарих, астрономия фәннәрен дә укучыларга аңлата һәм зур кызыксыну уята торган иде. Хәтта, тиктормас шук малайлар да әтием дәресләрендә шым булып, игътибар белән тыңлап утырганнар. Дәрес бетеп, кыңгырау шылтыраса да, тәнәфескә ашкынып чабучылар юк, әтием сөйләгәннәрне балалар сәгатьләр буе тыңлап утырырга да ризалар иде».

**Әдәбият**

1. И. Х. Мәүлетхуҗин. Тарихы бай, киләчәге якты, Казан утлары. 1987. №2.

***Тәминә Биктимирова***

## УТ ЭЧЕНДӘ ТАТАР КЫЗЛАРЫ...

Түземлекләр җиткәч чигенә,
Сынау килгәч туган иленә,
Килеп басты Татар хатыны
Көрәш сызыгының чигенә,
Шәлъяулыгын салып иңенә.

...Халык диңгезенең төбеннән,
Берәмтекләп, сөеп җыелган
Сөембикәләре милләтнең
Кан-көрәштә күпме җуелган...
Исемнәре җырга уелган.

*Лена Шагыйрьҗан*

Без – сугыш чоры балалары. Ил өстенә ишелеп төшкән олы кайгы, миллионнарның гомерен кискән, аналарны һәм балаларны ятим иткән сугыш, гомер буе безнең белән янәшә бара. Аннан котыла да алмадык, алмабыз да төсле. Гомер үтеп бара инде.

Бала чактан караган кинофильмнар, укыган китапларның күбесе руслар күрсәткән батырлык, тиңдәшсез каһарманнар да рус батырлары, рус кызлары иде. Мәктәптә укыганда «Мин кемгә охшарга телим» дигән темага сочинение язарга булса, без, билгеле инде, Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина, Любовь Щевцова, Ульяна Громовалар хакында яздык. Ул кызларны һич тә гаепләргә җыенмыйм. Аларның батырлыгы күңелгә кергән, матур булып урнашкан. Ә менә хатын-кызның сугыш кырында хәле ничек, нинди җайсыз, авыр хәлләрдән ничек чыга? Ничек ияләнә, ниләр кичерә, ничек чыдый ул? Боларын уйлый белмәгәнбез икән. Кулыма чорыбызның күренекле язучысы, Нобель премиясе лауреаты Светлана Алексиевичның «У войны не женское лицо» (китап исеме шулай хәтеремдә калган) дигән әсәре төште. Бу китап миңа сугышта катнашкан кызларның бөтен фаҗигасен аңлатып бирде дә инде. Ирләргә сугышта бер читен булса, хатын-кызга мең тапкыр читенрәк икәнен аңлау – бөтен дөньямны әйләндереп ташлады.

Мин үзебезнең татар кызларының хәлләре тагын да аянычрак булганлыгын, аларның фаҗигаләрен, кичерешләрен аңлап тетрәндем.

1958 елда яңадан «Азат хатын» журналы чыга башлады. Рәхмәт журналны чыгаручы каләм осталарына. Безнең татар кызлары – аларның да сугышта күрсәткән батырлыклары, тылда фронтка киткән ирләре уры-

нына басып эшләүче аналарның сугыш шартларында балаларын ачтан үтерми саклаулары хакында язмалар бирелә башлады һәм бу мактаулы эш әле дә дәвам итә.

Телевизор караштыргаларга туры килде быел. Үзәк каналларда да, үзебезнекендә дә татар кызларының батырлыгына багышланган ник бер тапшыру булсын! Ярый әле, Аллага шөкер, сугышны кичереп, 60 елдан артык тигез тормышта яшәгән хатын-кызларыбыз бар икән. Аларны карап сөендек.

Кызлар гына түгел, тиңдәшсез батырлыклары белән дөньяга танылган егетләребез дә искә алынмады... дисәм, үзәк каналда бер таныш исем яңгырады. Рейхстагта җиңү байрагын беренчеләрдән булып кадаган (бу хакта сугышта кинооператор булып катнашкан атаклы Роман Карменның истәлекләрен дә, рәсемнәрен дә дөнья күргән иде) татар баласы – 19 яшьлек Григорий Булатов исеме иде ул.

Күңел әрни: безнең буын Совет хакимияте чорында үзенең газиз халкы, туган-үскән җиренең тарихы, милләтнең чишмә башы, асылы, тамырлары турында белми үсте. Үз ата-бабаларыбыз, чын Ватаныбыз, үз милләтпәрвәрләребез хакында да белмәдек. Безнең башлар борынгы, урта гасырлар, яңа һәм иң яңа тарихлар белән тутырылды. Тарихыбызны белсәк, бүгенге наданлык та, үз халкыңа, аның үткәне һәм бүгенгесенә битарафлык та алай ук булмас иде.

Сүзем ут эчендәге татар кызлары хакында иде бит әле. Сугыш утын кичкәннәрне искә алу иде максатым.

Үз Ватаннарында үги булып яшәсәләр дә, шул илгә афәт килгәндә хаклык, язмышлар белән исәпләшмәгән кызларыбыз. Тормышның кайсы гына өлкәсенә карама – анда каһарманлыклары белән балкып торган кызларыбыз күп. Рус әдипләре, тарихчылары татар кызларының сугыш вакытында күрсәткән батырлыкларын, хезмәткә намус эше итеп карауларын, һәр эшне көчләрен, хәтта тормышларын кызганмый башкаруларын күрмәмешкә салыштылар. Йөрәгемне әрнеткән нәрсәләр күп...

Сугышның иң хәтәр көннәрендә Мәскәү белән Ленинград шәһәрләре күкләрен саклаучы зенитчы кызларның күбесе татар кызлары булуы хакында ник онытылды? Белергә теләүчеләргә «Сөембикә» журналының быелгы 5-нче санын укырга киңәш итәм. «Татарочкалардан үрнәк алыгыз» исемле мәкаләдән зенитчы кыз хакында Раилә Хәялиева язган. Рәхмәт аңа.

Дөрес, мәкаләдә язылганнар гына түгел, зенитчы кызларыбыз күп булган, кайберләренең исемнәрен тагын искә алыйк. Мәрхүм булсалар, рухлары шатлансын, могҗиза белән исән калсалар, үзләре шатлыктан еласын. Кайгырсак та, шатлансак та елыйбыз бит. Болар: Наилә Әхмәтҗанова, Мәрьям Кадыйрова, Фәнихә Юсыпова, Заһидә Вафина, Мөнәвәрә

Насыйбуллина, Зәйтүнә Хәлиуллина, Сәйдә Мостафина, Лена Шәмсетдинова, Зөлфия Нурлыгаянова, Бикә Хәйруллина, Суфия Исхакова һәм тагын бик күпләр. Исемнәрен тәсбих тарткан кебек кабат-кабат әйтеп, рәхмәт белдерик.

Ничек шулай үзләрен башка милләт кызларына үрнәк итеп куя алдылар икән? Бер зенитчы кызларга гына да әйтелгән сүз, бирелгән бәһа түгел әле бу бәя. Сугыш елларында күпме кызларыбыз торф чыгаруда эшләделәр. Ул эш шул вакытта, чын мәгънәсендә, икенче фронтка әйләнә, чөнки торф сугыш кораллары ясый торган заводларны, электр станцияләрен эшләтүгә, торак йортларны җылытуга киткән. Андагы эш шартларының никадәр авыр булганын хәзер аңлатуы да кыен.

Безнең кызларның торфны Мәскәү, Вологда, Иваново өлкәләреннән алып ерак Себер җирләрнә кадәр чыгарганы мәгълүм. Бер генә мисал китереп үтим, чөнки язмам бик озынга китә. Арча районының Иске Иябаш авылыннан Хәкимова Рәйсә белән Фазылова Кәримәләр өч ел буе Түбән Тагил урманнарында торф чыгаруда эшләгәннәр. «Сездән башка татар кызлары тагын бар идеме? – дип сорагач, – и, сеңлем, нишләп булмасын, элегрәк хатлар да алышкан идек, хәзер исемнәре онытылган инде, гаепләмә», – диделәр. Гаепләмәдем, әмма бернәрсәгә әле дә җавап таба алмыйм. Тагил өлкәсендә торф чыгарырлык бүтән милләт кызлары булмады микәнни?

Владимир, Калинин өлкәләрендә озак еллар торф чыгарган авылдашым Хәҗирә апа Төхфәтуллина болай дип сөйләде:

– Бервакыт без торган бистәгә күрше колхоз рәисе килде. Колхозның исеме хәтеремдә калмаган, Калинин өлкәсе иде. Шул рәис (үзе чулак, фронттан кайткан булса кирәк): «Кызлар, сезнең тырышлыкны белеп, зинһарлап килдем. Быел уңыш яхшы, безгә ял көннәрендә урак урырга килмәссез микән, игеннәр әрәм була бит», – дип чакыра.

Киттек шул авылга. Безнең Әтнә районы кызлары инде: Бәрәскә, Бәрәзә, ике Шимбердән. Торф нормасын тутырабыз да, шимбә, якшәмбе көн урак урабыз. Рәис куанычыннан еламый гына. Әле эшләгән өчен ит, май, он бирделәр. Рәхәтләндек туйганчы ашап, ике-өч ел булыштык үзләренә.

– Ул авылның үз кешеләре, үз колхозчылары кайда иде? – дип сорыйм Хәҗирә ападан.

– Үз кешеләре дә бар инде. Тик безнең хәтле эшли алмыйлар ич алар, – ди ул, бер дә исе китмичә генә. – Үзләренең яшелчә бакчаларында казыналар. Безне генә көне-төне колхоз эшенә йөртәләр иде, сеңлем.

Искитәрлек хәл. Халкымның иң гүзәл, иң матур сыйфаты – эш сөючәнлеге үзенә үк дошман булып кайта икән, ләбаса. Ул, татар халкының фаҗигасе, дисәм дә, ялгышмам төсле. Кайда авыр хезмәт – шунда татар,

шунда татар кызлары. Торф чыгарганда кызларның гарипләнүе, хәтта үлеп калулары да мәгълүм бит. Бу хакта безгә «Торфчы Мөнәвәрә», «Мәгъдәнә» бәетләре сөйли.

Әйе, авырлыклар килсә, татар кызларының зур намус ияләре икәнлекләрен дә, нинди гүзәл сыйфатларга ия булуларын да белүчеләр була. Сугышның иң хәтәр көннәрендә шушы торф чыгаруда эшләгән хатын-кызлар өчен татар телендә «Правда» исемле махсус газета чыгып килүе очраклы хәл түгел. Бу газетаны татар журналисткасы Мәрьям Дибаева берүзе чыгара. Мәскәү өлкәсендәге торфчы кызлар янына ул, 1944-нче елда ире Самат Дибаевның фронтта һәлак булган хәбәрен алып, кечкенә кызын әнисе тәрбиясендә калдырып китә.

Берүзе материал җыеп, мәкаләләр язган, Мәскәүгә килеп типографиягә тапшырган, берүзе бөтен тиражны күтәреп кайтып, торфчы кызларга өләшеп тә йөргән бит ул. Аның истәлекләрен «Ил язмышын салып иңнәренә» дигән китабыма керткән идем (Кара: [Биктимирова: 2006. ББ. 190–191]).

Тагын бераз читкә киттем. Әмма, укучылар мине аңларлар, чөнки фронт белән тылдагы батырлыкны аерып куя алмыйм мин. Кайда җиңелрәк булды, дигән сорауга җавап табып булмый.

Җавап таба алмаган сораулар тагы бар әле ул. Күңелемдә халкымның шушы мактаулы, эш сөюче, намуслы кызлары алдында оялу микән, кызгану микән – бер хис саклана. Ни өчен аларны бөтен СССР буйлап авыр хезмәттә тилмерттеләр икән? Милли сәясәтнең ачык чагылышы бит бу. Татарстанның бөтен шәһәрләрен, авылларын эвакуация белән килгәннәр тутырган. Ә Татарстан кызларын, товар вагоннарына төяп, читкә, эшкә озатканнар. Авыр эштән, ачлыктан үлеп калганнар күп, әмма хисабын бүген кем белә? Совет власте елларында Дәүләт Оборона комитеты фронт өчен, дип эшләткәч, нигә аларга льготалар, пособиеләр бирелмәде икән? Кем белә җавабын? Кем курыкмыйча әйтә ала?

Тагын фронтка әйләнеп кайтыйк әле. Безнең горурлыгыбыз, курку белмәс очучы Мәгүбә апа Сыртланова телевидение тапшыруы вакытында искә алынды. Рәхмәт. Ул – гади очучыдан эскадрилья полкының командир ярдәмчесе дәрәҗәсенә ирешкән татар кызы. Бу полк хакында беләсездер, дип уйлыйм. Яшьлегебездә без соклана, батырлыклары белән чиксез горурлана идек. Мәгүбә апа, ялгышмасам, 1971-нче елда бакыйлыкка күчте. Саубуллашырга бардым, җәсәде Казанның Офицерлар йорты залына куелган иде. Педагогия институтында эшләгән укытучыбыз Зөһрә апа Вәлиуллина миңа: «Мөселманча куябыз җир куенына, Аллага шөкер, рөхсәт бирделәр», – дип әйтеп, сөенече белән уртаклашты. Урыны җәннәттә булсын.

Әмма, никтер, икенче очучы героебыз Ольга Санфирова искә алынмады кебек. Бергә булалар бит алар. Күренекле язучыбыз Шамил Рәкыйповның «Кызлар–йолдызлар» дигән китабында алар хакында язылган. Кеше көлдереп, «нәрсә хакында укырга белмәгәч, «Зөләйха күзләрен ача»ны укудым», дип сөйләде бер хатын, оялмыйча. Укысын иде ул әнә бу китапны...

Бар һәм бик күп горурланырлык татар кызлары. Фронтка үз теләге белән киткән атаклы снайпер кызлар–Зәйтүнә Габделвәлиева, Әлфия Рәхмәтуллиналарны онытып буламы? Шәфкать туташларыннан снайперлар командасы төзегән Бөгелмә кызы Гөлсем Шакирҗанованы рәхмәт хисләре белән искә алыйк–60тан артык дошманның башына җиткән кыз ул.

Шәфкать туташларыбыз хакында сөйләгәндә, меңнәрчә яраланган сугышчыларны сугыш кырыннан алып чыгып үлемнән коткарган Мөнирә Әхтәмәва, Сафура Подвигина, Суфия Хәйретдинова, Зәйтүнә Бариевааларны; Әлмәт районының Миңлебай авылы кызы Мөхлисә Даутоваларны; медицина пунктларында һәм госпитальләрдә яралыларга күпме канннарын биреп, тормышларын саклап калган Мәрьям Гимаева, Рая Ибраһимова, Роза Зарипова, Зәйнәп Гыйлаҗетдинова һәм иң беренчеләрдән булып «Батырлык өчен» медале алган шәфкать туташы Асия Ильматованы хөрмәт белән искә алыйк.

Аеруча горурлык беләм үземнең якташым–Әтнә районы Түбән Көек авылы кызы–шәфкать туташы Наҗия Шакированың исемен атап үтәм. Һәм аның янына авылдашым Фәрзәнә апа Хисамиеваны, Түбән Көек кызлары Хәлиуллина Майшәрәп белән Шәмсеруй Фазылҗановаларны куям. Авыл кызлары, ә нинди батырлыклар күрсәткәннәр!

Нинди авыр шартларда операцияләр ясап, терелтеп, сугышчыларны яңадан армиягә яраклы итеп сәламәтләндергән хәрби табибәләрдән Вәсимә Сәйфуллина, Фатыйма Хәбибуллина, Мөнәвәрә Шәрифҗанова, Әминә Хәмзина, Рәисә Булатова, Оркыя Насыйрова һәм башкаларга олы рәхмәтебез булсын.

Халыкара «Кызыл Хач» җәмгыятенең иң югары бүләге–«Флоренс Найтингел исемендәге алтын медальгә лаек булганнар арасында татар кызы Фаина Чанышева да бар. Белеп торыгыз.

Татар кызлары елга фронтларында да тырышып хезмәт иттеләр. Яралыларны, гаскәрләргә кирәкле азык-төлек, сугыш коралларын ташыйлар алар. Араларында пароход штурманнары Фәйрүзә Галиева һәм Оркыя Курмаева да булган. Оркыяның әнисе һәм өч сеңлесе Харьков шәһәрендә дошманнар кулында калгач, ул үч алу теләге белән, хәрби очучылар мәктәбенә китә һәм фронтта һәлак була.

Язганнарым күп төсле, әмма язасыларым тагын да күбрәк икән. Тик һәрнәрсәнең чиге була. Шулай да көнбатыш фронтның махсус партизан

оешмасы штабында хезмәт иткән Чистай кызы Чәчкә Заһированы (руслар исемен Рита дип йөртәләр), дошман басып алган Днепропетровск шәһәрендә подпольеда көрәшеп һәлак булган Фатима Гафурованы, һәм быел интернетта мактаулы исеме чыккан тиңдәшсез разведкачы Фәридә Салимҗановаларны искә алмый китеп булмый икән. Үзләренең курку белмәс батырлыклары, оста сугышчылар булып ирләрне дә соклandырган пулеметчы кызларыбыз – Суфия Гыймаева, Маһирә Мөхәммәтшина, Нина Ризатдинова, Әминә Хафизовалар да һәйкәлләр куярга лаек затлар.

Тылдагылар хакында сөйләделәр, яздылар, Алла бирсә, тагын язарлар, дип өметләнәм. Бары кайбер саннарны гына искә төшерәм. Авыл хуҗалыгында төп көчләр хатын-кызлар (1944-нче елда 76,8%) һәм яшүсмерләр булды. МТСта эшләүче механизаторлар арасында 55%ны хатын-кызлар тәшкил итте. Комбайнчыларның – 62, тракторчыларның 81% хатын-кызлар иде. Татар кызларыннан тракторчылар Х. Сираҗиева, Б. Гыйззәтуллиналар (кызганыч, исемнәре язылмаган) «Советлар Союзының иң яхшы тракторчысы» дигән исемгә лаек булдылар.

Исемнәре язылмаган, бер карашка әллә ни батырлык дип тә саналмаган бер төркем хатын-кызларыбызны искә алып китәм. Аларның намуслы хезмәтләрен күрсәтеп, исемнәрен табарга югарыда аталган якташым Наҗия апа Шакирова сораган иде. Архивлардан эзләдем, таба алмадым. Бу исемсез каһарманнарыбыз – кер юучы хатын-кызлар. «Сталинград янында күпме хатын-кыз яралы сугышчыларның керләрен юа, үтүкли иде», – дип үтенде Наҗия апа. Бик кызганыч, кайсы районнан җибәрелгәннәрен дә ачыклап булмады. Әмма бу изге эштә, 1942-нче елда гына да, Татарстаннан 84 мең (!) хатын-кыз катнашкан икән.

Бу саннар артында да – кеше язмышлары. Берсе генә хакында да ник язылмады икән?

Сугыш еллары ераклаша бара. Ил-көнебез тыныч булсын, бу газаплар бүтән кабатланмасын иде. Ә бу җәһәннәмне үткән кызларга багышланган фильмнар «Мөселман кино»сында гына булса да күрсәтелсен иде, дигән теләкләр белдерәм.

### Әдәбият

1. Биктимирова Т. Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: Алма-Лит, 2006.

## ПРИКАЗАНО ПОБЕДИТЬ…

2020 год знаменуется как 75-летие Великой Победы над фашистской Германией. Но мало кому известно, что в этом году также исполняется 75 лет Победы в боях с японскими агрессорами за свободу, независимость и освобождение китайского народа.

В истории России/СССР имелись такие моменты, о которых не принято было упоминать. Но, как гласит народная поговорка, шила в мешке не утаишь. За все эти годы мы ежегодно отмечали День Победы, поздравляли ветеранов Великой Отечественной войны, слушали воспоминания бывших бойцов, смотрели душепотрясающие фильмы о войне с фашистской Германией. Однако, мы ничего не знали о тех событиях, о которых в советское время не только запрещалось говорить, но и вспоминать. Оставшиеся в живых воины навечно похоронили их в душах – незабываемые дни 9–21 августа 1945 г. предписывалось забыть. Они просто выполняли приказ: Победить!

Лишь спустя годы начали появляться новые факты, всплыли засекреченные документы. В дни празднования 70-летия Победы мне в руки попали документы, рассказывающие о событиях того времени и часть списка погибших воинов. Возможно, кто-то до сих пор ищет своих родных, близких, пропавших без вести осенью 1945 г. Война закончилась, а многие солдаты, служившие на Дальнем Востоке, так и не вернулись.

К вниманию читателей мы представляем «Хронику боевых действий», подготовленных из материалов совместного информационного проекта рабочей группы проекта «Историческая память в Приамурье» и газеты «Амурская правда».

Выражаем огромную благодарность руководителю Сахалинской РОО УКЦ «Туган тел» Закии Валитовой за предоставленные материалы и фотографии.

## ХРОНИКА БОЕВЫХ ДЕЙСТВИЙ

В начале войны с Японией перед 2 Краснознаменной А 2 ДВФ и оперативно подчиненными ей частями ставились задачи: прочно оборонять рубеж р. Амур на участке более тысячи километров, не допустить ее форсирования противником и выхода его войск к Транссибирской железнодорожной магистрали, а также его прорыва в устья рр. Зея, Бурея и Шилка.

В период с 21.07.45 г. до 0.30 ч. 09.08.45 г. 2 Краснознаменная А была приведена в полную боевую готовность, части и соединения первого эшелона заняли свои районы обороны в соответствии с решением, утвержденным Командующим 2 ДВФ 28.07.45 г.

### *9 АВГУСТА 1945 ГОДА*

Боевые действия в полосе 2-й Краснознаменной А начались после часу ночи 9 августа 1945 г. по хабаровскому времени. Разведывательные подразделения в течении суток вели активные поисковые действия, пограничные отряды приступили к уничтожению погранполицейских постов.

Разведкой было установлено, что противник спешно отводит свои подразделения от берега р. Амур вглубь территории Маньчжурии, поджигает населенные пункты. Горят гг. Сахалян (Хэйхэ), Цикэ.

### *10 АВГУСТА 1945 ГОДА*

74, 55, 78 и 75 ПОГО уничтожили все погранполицейские посты на правом берегу Амура на участках от устья Шилки до Сухотино, от Константиновки до устья р. Дичун, за исключением нескольких крупных гарнизонов: Мохо, Оупу, Хума, Фашань.

3 и 12 сд, 101-й УР взяли под контроль острова и провели разведку боем с захватом отдельных населенных пунктов на правом берегу Амура.

После проведения с 3.30 до 5.30 Зейско-Бурейской БРК набеговой операции на Сахаляньский (Хэйхэский) рейд в 11.00 началась десантная операция. К исходу дня был полностью взят под контроль г. Сахалян (Хэйхэ). В этот же день отрядом был освобожден населенный пункт Айгунь.

Части 2 Краснознаменной А получили приказ о переходе в наступление и произвели перегруппировку.

### *11 АВГУСТА 1945 ГОДА*

Противник, без боя оставив предполье и взорвав часть оборонительных сооружений в отдельных опорных пунктах Сахалянского и Цикейского УР, отходит на заранее подготовленные районы обороны.

2 Краснознаменная А в соответствии с директивой Военного Совета 2 ДВФ от 10.8.45 №339/НШ с утра 11 августа перешла в наступление. В течение дня части первого эшелона продолжали переправу через р. Амур в районах армейских переправ: Благовещенск, Константиновка и вели бои по захвату населенных пунктов на правом берегу р. Амур и уничтожение гарнизонов противника. Части второго эшелона производили перегруппировку и сосредоточение войск к районах армейских переправ.

3 сд сосредоточилась в районе Саратовки, Константиновки и продолжила переправу. Ее 70 сп закончив переправу овладел населенными пунктами Хадаянь, Канифу, Дахуашулинззы, Сихомоэрцзинь.

214 сп 3 сд продолжает переправу в районе Поярково и передовыми подразделениями от 4.00 11 августа и к 17.00 овладел г. Цикэ. В бою были уничтожены до 200 солдат и офицеров противника.

Передовые отряды 101 УР овладели пунктами Цялуншань (1,5 км западнее Гродеково) и Цяньлаяоцзя. Передовой отряд 258 отбр в 11.25 овладел населенным пунктом Шаньшеньфу, оставив для охраны караул и стремительно продвигаясь на юго-восток к 23.00 с подошедшим батальоном 586 сп и отрядом 256 опулб вели бой по овладению станцией Айгунь и населенными пунктами Сиганцзы и Ланьцзитунь.

Отряд 368 гсп во взаимодействи с группой 74 ПОГО и Стретенским одрк форсировал р. Амур в районе Игнашино и к 17.00 овладел г. Мохо. Авиация 18 ак из-за неблагоприятных метеоусловий боевых вылетов не производила. Вылетевший на разведку самолет ПЕ-2 140 раэ не возвратился с задания, он пропал в районе г. Сун-у.

***12 АВГУСТА 1945 ГОДА***

Войска 2 Краснознаменной А начали бои за овладение подготовленными к длительной обороне УР противника. Командующий войсками 2-й Краснознаменной А Герой Советского Союза генерал-лейтенант танковых войск Макар Фомич Терехин с 12.00 руководил войсками из района Константиновки – на Бэйаньском направлении (Константиновка, Сун-у, Бэйань), где сосредотачивал главную свою группировку: две стрелковые дивизии, две отдельные танковые бригады, пять артиллерийских полков.

3 сд к исходу дня овладела опорными пунктами на переднем крае обороны, отразила несколько контратак противника.

214 сп 12 сд преследовала отходящего из Цикэ в направлении Сюньхэ, противника. Остальные части дивизии находились на марше к переправе.

На второстепенном, Мэргеньском направлении (Благовещенск, станция Айгунь, Мэргень) формировалась оперативная группа.

Подразделения 258 отбр, 3 б-на 586 сп, отряд 101 УР, при поддержке 465 минп в течении дня ведут бои в районе станции Айгунь и населенных пунктов Сиганцзы, Дунганцзы и к исходу дня, отеснив противника, овладели рубежом реки Гунбелахэ.

Батальоны 101 УР заняли оставленные узлы сопротивления противника, надежно прикрывали тылы Мэргеньской группировки наших войск и обеспечивли переправу войск в районе Благовещенска.

Части Краснознаменной АмВФл осуществляли переправу войск, частью сил огнем поддерживая действия наших войск, а авиация 18 ак вела разведку, прикрывая войска и нанося удары по войскам и коммуникациям противника. 12 августа было произведено 253 самолетовылета. Зенитной артиллерией противника в течении дня были подбиты два самолета ЯК-9, летчики совершили посадку на нашей территории.

На всех участках противник упорно сопротивляется.

### *13 АВГУСТА 1945 ГОДА*

В 8.00 3 сд возобновила наступление на Хомоэрцзинский узел сопротивления и к исходу дня овладела населенными пунктами Эюхэкоу, Сяоуцзявопэн. 2 б-н 70 сп блокировал уцелевший опорный пункт противника. 8 сп со средствами усиления блокировал восточную часть узла сопротивления и вел бой по уничтожению противника, капитулировавшего только 17 августа (через четыре дня).

12 сд главными силами сосредотачивалась на переправе Константиновка. 214 сп, овладев Сюньхэ в течении суток, вел преследование противника в направлении Малоланьтунь. В районе Сыбулы он встретил ожесточенное сопротивление. Несколько раз безрезультатно атаковал противника и сам отражал контратаки противника. 1 б-н 192 сп 12 сд, действуя в отрыве от главных сил на левом фланге армии, во взаимодействии с маневренной группой Зейской-Бурейской БРК и пограничниками 75 ПОГО, с рассветом в районе Сагибово форсировал р. Амур и к 9.00 освободил г. Фошань. Части оперативной группы на Мэргеньском направлении после тяжелого ночного боя закрепились на левом берегу р. Гунбелахэ. 18 ак несмотря на неблагоприятные метеорологические условия, содействовал наступлению армии, произвел 104 самолетовылета.

### *14 АВГУСТА 1945 ГОДА*

На Бэйаньском направлении противник ожесточенно сопротивлялся. Тяжелые бои в течении суток вели полки 3 сд и 74 отбр. Танкисты в районе севернее Сяоуцзявопэн ночью в 4.30 под покровом тумана были окружены противником силою до двух батальонов и атакованы. В результате полуторачасового боя в условиях ограниченной видимости уничтожено до 200 человек солдат и офицеров противника, большинство из которых были «смертниками», атака отбита. В течении дня бригада вела бой за овладение населенным пунктом Яотунь. 70 сп 3 сд в 9.30 был контратакован противником силою до батальона пехоты из района южнее Сяоуцзявопэн. В результате огня противник отошел потеряв убитыми до 400 человек. К исходу 14 августа полк овладел переправой через р. Суньбэлахэ и захватил плацдарм.

18 сп 3 сд с 11.00 совершил марш после переправы в районе Константиновки и к 20.00 овладел рубежом восточнее Сяоуцзявопэн. 8 сп уничтожил блокированного противника в Хомоэрцзинском узле сопротивления. 214 сп 12 сд преследуя противника вышел к Маолатуньскому узлу сопротивления восточнее Сяоуцзявопэн. Главные силы дивизии в течении дня закончили переправу и сосредоточились на правом берегу р. Амур для совершения марша в район Сяоуцзявопэн.

Стретенский ОДРК закончил переброску отряда 386 гсп из Игнашино в Джалинду. Бурейская бригада речных кораблей частью сил готовилась в районе Константиновки к походу к р. Сунгари – в район действий основного ядра Краснознаменной АмВФл.

Несмотря на сложные метеоусловия, части 18 ак в течении суток совершили 149 самолетовылетов.

### *15 АВГУСТА 1945 ГОДА*

На Бэйаньском направлении 3-я стрелковая дивизия с 74 отбр совместно с подходящими артиллерийскими полками в течении дня с боями продвинулась в направлении Сяоуцзявопэн, Яотунь, Чжэнцзявопу, обходя с юга главную группировку 123 японской пд с задачей последующего захвата Сун-у. Противник контратаковал из Сун-у. 2 б-н 18 гсп совместно с 214 сп 12 сд к 15.00 завершили окружение и разгром противника в Маолатуньском узле сопротивления. 12 сд главными силами вышла в район действий своего 214 сп и повела наступление в общем направлении на Эрчжань (станция Жуцик) обходя Сун-у с востока.

На Мэргэньском направлении части оперативной группы продолжали сосредоточение и подготовку к наступлению на Ганцзинский узел сопротивления. Артиллерия группы заняла назначенные огневые позиции. 388 пап закончил переправу через р. Амур. Отряд 101 УР ведя разведку по Приисковому тракту к исходу дня в районе Удогоу встретив подразделение японцев, сходу вступил в бой.

18 ак поддерживал наступление войск армии на главном направлении, произвел 317 самолетовылетов.

### *16 АВГУСТА 1945 ГОДА*

В 0.25 Военным Советом 2 Краснознаменной А на имя командира оперативной группы, командиров 3, 12, 396 сд, 73, 74 и 258 отбр, была направлена шифрограмма следующего содержания: *«Выполнить поставленные задачи; требую от Вас с утра 16.08 перейти в решительное наступление по уничтожению противостоящего противника, помня, что перед Вами действуют арьергарды отходящих частей; больше применять обходных действий и просачиваний; нельзя допускать дальнейшей Вашей задержки в выполнении поставленной задачи. Буду беспощаден к тем офицерам, которые допустят нерешительность, трусость в выполнении поставленной задачи. Довести мои указания до командиров батальонов и дивизионов»*.

На Бэйаньском направлении 3 сд и приданные ей части в течении дня вели бои по овладению Сун-у. 70 сп с 74 отбр и к 13.00 овладели аэродромом и пригородом Сун-у. 2 б-н полка, обойдя город с северо-запада,

к 16.00 вышел к южной окраине Сун-у. 18 сп с 16.00 в исходном районе для форсирования р. Суньбилахэ северо-восточнее Сунь-у для обхода города с востока, провел разведку боем 4 ср опорного пункта Сунучжанского узла сопротивления. 2 б-н 70 сп и 1 б-н 18 сп дивизии прикрывали с севера действия своих главных сил. В течение дня батальоны отразили атаки противника. Дивизия завершила обход и блокирование с юга главной группировки 123 японской пд. 8 сп завершал разгром блокированных остатков гарнизона Хомоэрцзинского узла сопротивления.

12 сд главными силами к 12.00 закончила переправу через р. Суньбилахэ на участке Эюхэкоу, Уцзявопэн и перешла в наступление. К 16.00, преодолев сопротивление батальона противника, дивизия вышла на рубеж 6–8 км южнее Эюхэкоу. 192 сп дивизии сосредоточилась на переправе в Константиновке. 73 отбр после переправы через р. Амур, совершила марш и сосредоточилась в районе Сяоуцзявопэн.

На Мэргеньском направлении части оперативной группы после артиллерийской подготовки, наступая одновременно с запада и востока, сомкнули фланги и завершили полное окружение Ганцзинского узла сопротивления. 258 отбр в 21.00 начала маневр в тыл Ганцзинского узла сопротивления. В течении дня при благоприятной погоде активно действовала авиация 18 ак. Произведено 208 самолетовылетов на разведку, по коммуникациям и войскам противника.

К исходу 16 августа основная группировка японских войск общей численностью личного состава более 20 тыс. чел., была окружена.

### *17 АВГУСТА 1945 ГОДА*

В 5:00 в штаб 74 отд из города Сун-у прибыл парламентер – майор Квантунской армии, по поручению коменданта Сахалянской провинции генерал-лейтенанта Тейджиро Китазава для ведения переговоров о капитуляции. На переговоры прибыл командующий войсками армии, передавший парламентеру письменное требование:

*«Коменданту Сахалянской провинции генерал-лейтенанту Тэйдикиро Китазава (в других документах – Тэйджиро Китазава, здесь и далее воспроизводится текст оригинала без исправлений). Заслушав Ваших парламентеров, требую:*

*1. Прекратить военные действия всех японских войск, Маньчжурских и белогвардейских отрядов на территории Сахалянской провинции к трем часам дня Хабаровского времени 17.8.45 г.*

*2. Наметить пункты сосредоточения войск, Маньчжурских и белогвардейских отрядов. О пунктах сосредоточения войск поставить меня в известность к трем часам дня Хабаровского времени 17.8.45 г.*

*3. Оружие должно быть сложено и передано по указанию командования Красной Армии.*

*4. С трех часов дня хабаровского времени 17.8.45 г. вооруженным силам Японии, Маньчжурии и белогвардейским отрядам воспретить порчу железных дорог, мостов, складов, запасов, снаряжения, вооружения и боеприпасов и прочего. (приписка) предприятий и учреждений*

*5. В случае не выполнения моего требования Ваши войска, Маньчжурские и белогвардейские отряды будут уничтожены, за что Вы несете персональную ответственность. Сопротивление ваше безполезно и приведет к лишним жертвам.*

*6. Всем сложившим оружие гарантирую жизнь и безопасность.*

*генерал-лейтенант: /Терехин/*
*генерал-майор: /Шемионко/*

*11 часов 10 минут Хабаровского времени Город Сун-у*

*(подписали: командующий войсками 2-й Краснознаменной Армии, Герой Советского Союза генерал-лейтенант танковых войск Макар Фомич Терехин, член Военного совета 2-й Краснознаменной Армии генерал-майор Шемионко Иосиф Иосифович)*

С 17 часов началась капитуляция 123 пд и подчиненных ей частей. В районе Сун-у сдалось 17061 человек. Генерал-лейтенант Китазава лично сдался генерал-лейтенанту танковых войск Терехину.

3 сд с 74 отбр, приданными артиллерийскими полками к 17:00 овладела городом Сун-у. Противник прекратил сопротивление. С 18:00 70 сп и учебный батальон дивизии, наводит порядок в Сун-у и принимает военнопленных. 18 сп выступил на Эрчжань. 8 сп на марше к Сун-у для присоединения к основным силам дивизии. Остальные части, включая приданные, в районе Сун-у готовятся к маршу. 465 минп с 17:00 совершил марш от станции Айгунь на Сун-у в распоряжение командира 3 сд.

12 сд с 73 отбр в течении дня наступала вдоль тракта от Сяоуцзявопэн на Эрчжань ведя бой с отходящим противником, который прекратил сопротивление только к 20:00 и начал сдачу. Дивизия продолжала движение на Эрчжань. 192 сп переправился через р. Амур в районе Константиновки для соединения с главными силами противника.

101 УР продолжал оборону занятых районов, обеспечивая Благовещенскую переправу и вел разведку. Отряд 100 опулб в 12:00 в районе Тахэричи завязал бой с маньчжурской 12 смешбр. Вследствие превосходства противника батальон перешел к обороне. Маньчжуры после боя активности не проявляли.

Оперативная группа на Мэргеньском направлении в течение дня производила перегруппировку. 258 отбр к 7:00 маневром вышла в тыл Ганцзинского узла сопротивления и занимала Доугоуцзы; в 15:00 с 181 минп выступили для преследования противника на Мэргень; к 19:00 у Шитоумяо встретили сильное сопротивление противника. Передовой отряд с ходу развернулся и вступил в бой. До наступления темноты противник с ближних высот был выбит и понеся потери отошел с занимаемого рубежа. Части бригады закрепились на захваченном рубеже и стали готовиться для наступления. Основные силы группировки – 396 сд без 614 сп к исходу дня сосредоточилась в районе Доугоуцзы в готовности к маршу по Мэргэньскому тракту. В состав оперативной группировки также вошел 368 гсп, который сосредоточился в Сахаляне.

Пограничные отряды после ликвидации погранполицейских постов, на своих участках охраняли государственную границу, производили преследование и ликвидацию отходящих групп противника, изымали агентуру противника в приграничной полосе, охраняли тылы частей Красной Армии.

В 17:15 от Военного Совета 2 ДВФ была получена шифровка, адресованная командующему войсками армии, следующего содержания: *«В связи с объявлением приказа командующего Квантунской Армией о прекращении военных действий японскими военными силами, приказываю:*

*1. Разоружение, прием пленных (японцев и маньчжур), прием вооружения и имущества проводить силами войск армии. Никаких сборных пунктов военнопленных органами НКВД организовано не будет.*

*Пленных сосредотачивать и размещать в военных городках в Маньчжурии. Охрану для сопровождения их и охрану на месте сбора (размещения) выставлять от войск из расчета: на 1.000 чел. пленных – один св; на 2.000–3.000 – ср; на 5.000–6.000 – сб.*

Пленных конвоировать и размещать: японцев и маньчжур отдельно, изолируя солдат от офицеров.

Питание организовать по нормам японской армии, существующей до начала капитуляции, за счет захваченных и сданных запасов продовольствия.

Для поддержания порядка в занятых и оккупированных городах выделять в распоряжение комендантов от стрелкового взвода до стрелковой роты, в зависимости от размеров и важности объектов населенного пункта».

### *18 АВГУСТА 1945 ГОДА*

*«Ставка Верховного Главнокомандования приказывает:*

*1. На тех участках фронта, где японские войска складывают оружие и сдаются в плен, боевые действия прекратить.*

*2. В городах Маньчжурии, освобожденных от японцев, могут быть подняты китайские флаги, администрацей назначенной ЧАН-КАЙ-ШИ.*

*В этом китайской администрации не препятствовать и содействовать ей в установлении порядка.*

*3. Склады с продовольствием, горючим, оружием и всяким снаряжением, а также автомашины и другое имущество, захваченное нашими войсками, считать своими трофеями и китайцам не передавать.*

*4. Требую немедленно довести до командиров полков.*

*Ставка Верховного Главнокомандования. СТАЛИН. АНТОНОВ».*

| д. Толмаево | 7 двор.<br>30 дмп | ясашныя татара | л. 421 об. |
| д. Меленке | 5 двор.<br>15 дмп | ясашныя татара | л. 423 об. |
| д. Абдулово | 13 двор.<br>33 дмп | ясашныя татара | л. 424 об. |
| д. Верхние Байки | 8 двор.<br>24 дмп | ясашныя татара | л. 428 |

**РГАДА, Фонд 350. Оп. 2. Ч. 2. Д. 3793. 1747 г. II ревизия.**

## Книга переписная ясачных крестьян (татары, мари, вотяки, мещеряки), служилых татар и мещеряков Казанской дороги Уфимского уезда.

| | | |
|---|---|---|
| д. Аташева, что на речке Куилде | ясачные татара | л. 1 |
| д. Кутуева, что на речке Куяшъ Башъ | ясачные татара | |
| д. Бешкуразова, что на речке Бузуиде | ясачные татара | л. 1 об. |
| д. Шедалино, что на речке Шедали | ясачные татара | л. 2 |
| д. Текарликово, что на речке Уяшъ Яды | ясачные татара | |
| д. Киргизъ | татар | л. 2 об. |
| д. Исяшево, что на речке Каречке Миняузе | татара | л. 3 |
| д. Солтанебеково, что на проточном ключе | татара | л. 3 об. |
| д. Нугуша, что на речке Нугуше | татара | |
| д. Тохталачик, что на речке Шабизе | татара | л. 4 об |
| д. Курмашево, что не речке Кудюшли | татара | л. 5 об |
| д. Кулсейтово, что на речке Ташлы | татара | |
| д. Дюсметево | татара | |
| д. Узы, что на речке Узе | татар | л. 6 |
| д. Кудашли, что на речке Чишме | татара | |
| д. Григорьево | татара | |
| д. Сукса, что на речке Суксе | татара | л. 6 |
| д. Недырово, что на речке Урсалы | татара | л. 7 |
| д. Надырово, что на речке Бантуга | татара | л. 8 об. |
| д. Смаилово, что на речке Каме | татара | л. 9 |
| д. Новокашира в вершине речки Большой Урсалы | татара | л. 9 об. |
| д. Сялеево в вершине речки Большой Урсалы | татара | л. 10 об. |
| д. Якеева, что на речке Менле | татара | л. 11 |
| д. Алкеева, что на речке Куякъ | татара | л. 12 |
| д. Бешмунча, что на речке самой вершины Камы | татара | л. 13 об. |
| д. Какыръ Илге, что на речке Мелле | татара | л. 14 об. |
| д. Тосуганово | татара | л. 15 об. |
| д. Карабашева | татара | л. 16 об. |
| д. Кудашева | татара | л. 18 |

| | | |
|---|---|---|
| д. Абдрахманова | татара | л. 19 |
| д. Каратаево, что на речке Каратае | татара | л. 20 |
| д. Бакиева, что по степовой Зая реке наусть Сазлы | татара | л. 23 |
| д. Маткабыбашъ, что на речке Матабы Баше | татара | л. 24 |
| д. Маткабытамак, что наусте Маткабы речки | татара | л. 27 |
| д. Малая Урсала, что на речке Урсале | татара | л. 29 |
| д. Альметева, что позая реке | татара | л. 30 об. |
| д. Бигашева позая реке, что на речке Уртакушъ | татара | л. 33 |
| д. Бигашева, что на усти речки Игар Илге | татара | л. 34 об. |
| д. Муратова позаю, что на речке Мамай | татара | л. 35 об. |
| д. Чепаево, что на речке Кичуе | татара | л. 36 |
| д. Минлибаева, что по речке Кичье вдершине | татара | л. 38 |
| д. Кичье Чатъ, что на речке Кичье | татара | л. 39 об. |
| д. Недырово, что на речке Саушлы | татара | л. 41 |
| д. Меметева | татара | л. 43 |
| д. Кулшерыпова позаю реке, что на речке Мама Илге | татара | л. 45 |
| д. Сеитова, что на речке Кырлыгасе | татара | л. 46 |
| д. Урмушли, что на киргилазе речке | татара | л. 47 |
| д. Сары Беккулава, что на речке Шешме | татара | л. 47 об. |
| д. Аналикова, что на речке Шешме | татара | л. 49 |
| д. Резипова, что на речке Синиряне | татара | л. 51 |
| д. Иштерекова, что на речке Шошме | татара | л. 51 об. |
| д. Старая Резипова, что на речке Камышле | татара | л. 53 об. |
| д. Киркалы, что на речке Киркале | татара | л. 54 об. |
| д. Камышлы, что на речке Камышле | татара | л. 56 об. |
| д. Казбулатова, что по степной реке Шешме | татара | л. 57 |
| д. Шугур, что пошешме реке на речке Шугурове | татара | л. 57 об. |
| д. Токтарова, что по реке Шешме на речке Урдалы | татара | л. 59 |
| д. Куакбашева, что на речке Куваке | татара | л. 60 об. |
| д. Шачили | татара | л. 62 |
| д. Бугады, что на речке Кыдаше | татара | л. 64 |
| д. Капей, что на речке Кыдашъ | татара | |

| | | |
|---|---|---|
| д. Устюбы, что на речке Кыдаше | татара | л. 64 об. |
| д. Арасланда, что на речке Арасланде | черемиса | л. 65 |
| д. Каимгрово, что на речке Мортыше | черемиса | л. 65 об. |
| д. Старая Атитерева, что на речке Узе | черемиса | л. 66 об. |
| д. Юдачева, что на речке Ивбазе Баше | черемиса | л. 67 |
| д. Мурзагулова, что на речке Терпели | черемиса | л. 67 об. |
| д. Варзеды, что на речке Варзеде | черемиса | л. 68 |
| д. Чаки, что на речке Чаке | черемиса | л. 68 об. |
| д. Черемиская Бюрьтюкова, что на речке Тектене | черемиса | л. 70 |
| д. Бюнрюшъ | черемиса | л. 70 об. |
| д. Кереметева, что на речке Гнилой Таньпе | черемиса | л. 71 |
| д. Таки Елань | черемиса | л. 71 об. |
| д. Тиктень, что на речке Тиктень Баше | черемиса | л. 72 |
| д. Келта | черемиса | л. 72 об. |
| д. Калы Тамакъ, что на речке Тактияле | черемиса | л. 74 об. |
| д. Камышлы, что на речке Камышле | черемиса | л. 75 об. |
| д. Токпердино, что на речке Казлыяре | черемиса | л. 77 |
| д. Менези, что на речке Менезе | черемиса | л. 79 об. |
| д. Калтаково, что на речке Атрекле | черемиса | л. 80 |
| д. Чюпаева, что на речке Мушуге | черемиса | л. 82 об. |
| д. Каракулы, что на озере Каракуле | черемиса | л. 83 об. |
| д. Балдырганъ, что подле Бимы | черемиса | л. 84 |
| д. Новая Киясова, что втогузахъ | черемиса | л. 85 об. |
| д. Усаклы | черемиса | л. 86 об. |
| д. Имбетева | черемиса | л. 87 |
| д. Чопаева | черемиса | л. 87 об. |
| д. Бабаева, что в сенских вершинах | черемиса | л. 89 |
| д. Мещерева Кузмурзина тож | черемиса | л. 90 |
| д. Тенбагышева, что на речке Чешме | черемиса | л. 91 |
| д. Кичкинашева, что на речке Ардаше | Черемиса | д. 92 |
| д. Новая Курмань Илгешелтыкъ Башъ, что на речке Шелтык Баше | Черемиса | л. 92 об. |
| д. Урусаева, что на речке Шелтыке | Черемиса | л. 95 |
| д. Акборисова Бигишева тож, что на речке Шелтыке | Черемиса | л. 96 |

| | | |
|---|---|---|
| д. Уибулатова, что на речке Базинских Вершинахъ | Черемиса | л. 97 |
| д. Енахметева, что на речке Сюнских Вершинахъ | черемиса | л. 99 |
| д. Новопоселенная Акулова, что на речке Менеузе | черемиса | л. 100 |
| д. Урахчиная, что на речке Лаишлы | вотяки | л. 101 |
| д. Калтаево, что на речке Мешеде | служ. мещеряки | л. 103 |
| д. Ахметево, что на озере Менези | служ. мещеряки | л. 110 об. |
| д. Калны, что на озере Кулешкуле | служ. мещеряки | л. 112 |
| д. Еланкулы, что на речке Арьясъ | служ. мещеряки | л. 114 |
| д. Терибердина (Кушнаренково), что на речке Зеряклы | служ. мещеряки | л. 115 об. |
| д. Юнусова, что на озере | служ. мещеряки | л. 116 об. |
| д. Досметева, что на речке Кудушле | служ. мещеряки | л. 117 |
| д. Мукачева, что на речке Кудешли | служ. мещеряки | л. 126 |
| д. Курмашева, что на речке Кулюшле | служ. мещеряки | л. 128 об. |
| д. Кибашева, что на речке Мелимуле | служ. мещеряки | л. 134 об. |
| д. Уразаи, что на озере Кулише | служ. мещеряки | л. 135 об. |
| д. Старая Кудюшли, что на речке Кудюшле | служ. мещеряки | л. 140 |
| д. Бакаева | служ. мещеряки | л. 143 об. |
| д. Баиталы Наурузава тож, что на речке Баитале | служ. мещеряки | |
| д. Копаева, что на речке Чермасане | служ. мещеряки | л. 146 об. |
| д. Рюсмекеева, что на речке Чермасане | служ. мещеряки | л. 148 об. |
| д. Емуранова, что на речке Чермасане | служ. мещеряки | л. 150 |
| д. Ерыкшан и Сланова тож | служ. мещеряки | л. 152 |
| д. Сеитова, что на речке Караче | служ. мещеряки | л. 153 об. |
| д. Имаиутаръ, что на речке Явбазе | служ. мещеряки | л. 154 об. |
| д. Минтеева, что на речке Явбазе | служ. мещеряки | л. 156 об. |
| д. Ижбулатова, что на речке Малой Явбазе | служ. мещеряки | л. 158 об. |
| д. Бактерякова, что на речках Явбазе и Улкаше | служ. татары | л. 161 |
| д. Успели (Учпили), что на речке Явбазе | служ. татары | л. 161 об. |
| д. Кадырова Каишъ, тож что на речке Явбазе | служ. татары | л. 163 об. |
| д. Казыбашъ, что на озере Казы | служ. татары | л. 166 |
| д. Казакларова, что на речке Явбазе | служ. татары | л.166 об. |
| д. Мамедилина, что на проточномъ ключе | служ. татары | л. 176 |

| | | |
|---|---|---|
| д. Иткинеева, что на проточном ключе | служ. татары | л. 176 об. |
| д. Кумлюкучукъ, что на проточномъ ключе | служ. татары | л. 181 |
| д. Куяшъ (Кушуль), что на речке Куяше | служ. мещеряки | л. 182 |
| д. Якалыкуль (Юкаликуль), что на речке Куяшь | служ. мещеряки | л. 185 |
| д. Смаилова, что на речке Сукуязъ | служ. мещеряки | л. 186 |
| д. Рысова, что на речке Сукуязъ | служ. татары | л. 187 |
| д. Текарликова, что на речке | служ. мещеряки | л. 188 |
| д. Куралачик Мансурова тож | служ. мещеряки | л. 188 об. |
| д. Аташева, что на речке Куяше | служ. татара | л. 192 |
| д. Бешкуразова | служ. мещеряки | л. 194 об. |
| д. Шедали, что на речке Шедале | служ. татара | л. 197 |
| д. Измеикова, что на речке Шабизе | служ. татара | л. 198 |
| д. Кипчакъ, что на речке Сюне | служ. мещеряки | л. 198 об. |
| д. Адаева, что на речке Чешме | служ. мещеряки | л. 200 об. |
| д. Варзи, что на речке Варзе | служ. татара | л. 203 |
| д. Салагушъ, что на речке Салагуше | служ. татара | л. 206 |
| д. Тугашева Адаева тож, что на речке Ику | служ. мещеряки | л. 208 |
| д. Тупеево, что на речке Мать | служ. мещеряки | л. 212 |
| д. Калшели, что на речке Калшели | служ. татара | л. 212 об. |
| д. Абдулова, что на речке Нази | служ. мещеряки | л. 213 об. |
| д. Балакова, что на речке Балаке | служ. мещеряки | л. 214 об. |
| д. Чекмагушъ, что на речке Чекмагуше | служ. татара | л. 215 |
| д. Тюрюшъ, что на речке Тюрюше | служ. мещеряки | л. 219 |
| д. Карамалы, что на речке Карамале | служ. мещеряки | л. 227 |
| д. Азино | служ. мещеряки | л. 228 об. |
| д. Улуарем, что на речке Чермасане | служ. мещеряки | л. 230 |
| д. Каратеки, что на речке Кареке | служ. мещеряки | л. 230 об. |
| д. Токмаклахъ, что на речке Керенеке | служ. мещеряки | л. 232 |
| д. Акмушева, что на речке Кармасане | служ. мещеряки | л. 236 |
| д. Кармасан, что на речке Кармасане | служ. мещеряки | л. 238 |
| д. Илмурзина, что на речке Чертаки | служ. мещеряки | л. 240 об. |
| д. Чешмы, что на речке Шушме | служ. мещеряки | л. 241 |
| д. Смалово Киндезь тож | служ. мещеряки | л. 242 |
| д. Наурузова | служ. мещеряки | л. 243 |
| д. Саребек, что на речке Шешме | служ. мещеряки | л. 243 об. |

| | | |
|---|---|---|
| д. Недырова, что на речке Баитугане | служ. мещеряки | |
| д. Игень Ильга | служ. татара | л. 244 |
| д. Бугульма | служ. татара | л. 254 а |
| д. Димтамак | служ. татара | л. 245 а об. |
| д. Кандыз | ясашныя татара | |
| д. Шаулты | ясашныя татара | л. 246 |
| д. Усманова | ясашныя татара | л. 247 об. |
| д. Якупова | ясашныя татара | л. 249 |
| д. Аширова | ясашныя татара | л. 250 |
| д. Кутл. Бетева | ясашныя татара | л. 251 об. |
| д. Наурузова | ясашныя татара | л. 252 об. |
| д. Дюсметева | ясашныя татара | л. 253 |
| д. Сарманаева | ясашныя татара | л. 254 об. |
| д. Мустафина | ясашныя татара | л. 255 |
| д. Юзеева | ясашныя татара | |
| д. Бенкулова | ясашныя татара | л. 256 |

Итоги – почти не читаемы – лл. 257–260 об. Далее – взятые в рекруты в 1746 и 1747 гг. в Уфимской провинции всего 72 человека. Из купечества Уфы – л. 261. Уфимского уезду дворцовые Дуваненской волости с. Дуванеи Бирской волости пригорода Бирску – л. 261 об. и т.д.

*Материал подготовлен группой краеведов*

## Олуг Татар иле

## Magna Tartaria

***Ф. Ә. Бәйрәмова***

# КАЗАКЪ ДАЛАСЫНДА ТАТАР ТАРИХЫ

Язмамның башын «Казакъ даласында татар тарихы» дип куйдым да, уйга калдым... Мин, тарихчы буларак, бу якларның борынгыдан «Татар Даласы» дип аталганын яхшы беләм, бу далалардан, дала итәгеннән башланып киткән, кул сузымындагы Алтай тауларында арий, скиф һәм һун курганнары барлыгын күршедәге Алтай Республикасында үз күзләрем белән күрдем. Бу җирләр, бу халыклар башта Төрки каһанлыклар, аннан Алтын Урда, Себер ханлыгы кебек татар дәүләтләре составында булган. Тарихчы Радлов бу җирләрдә татарларның XV–XVI гасырлардан дәүләтләр төзеп яшәгәнен яза, ә җирле тарихчылар исә бу датаны тагы да ераграк чорларга күчерә:

«IX–XII вв. – в пределах степной зоны Северо-Восточного Казахстана закрепляется в европейских источниках наименование «Татарская Степь», – дип яза алар. – Здесь шел активный процесс формирования тюркской государственности» [Пресняков: 2004. С. 32].

Әйе, татарлар бирегә XVIII–XIX гасырларда гына килеп урнашмаган, алар монда бик борынгыдан – һун-скиф чорларыннан, Алтын Урданың шөһрәтле заманнарыннан бирле яшәгәннәр, дәүләтләр тотканнар, шәһәрләр салганнар, затлы нәсел калдырганнар. Әйе, биредә татарның дала тарихы да, кала тарихы да бар һәм аның эзләре бүген дә саклана. Шушы ун ел эчендә ике тапкыр Көнчыгыш Казакъстанда булып, мин моңа тагы да ныграк инандым. Төп сәфәрем элек-электән татарлар укмашып яшәгән Җидепулат (Семипалатинск-Семей) шәһәренә иде, якын-тирәдәге берничә кала һәм салада да булдым. 2011-нче елның октябрендә, Семейда яшәүче милләттәшләребезнең чакыруы буенча, Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән «Көзге Иртыш моңнары» халыкара татар сәнгате фестивалендә, Татар үзәге рәисе, Татар сәнгать мәктәбе мөдире Габделхак Ахунҗановның 60 яшьлек юбилей тантанасында катнаштым. 2016-нчы елның сентябрендә исә «Татарларны саклап калуда һәм үстерүдә ислам диненең хәлиткеч роле. Евразиядә ислам динен таратуда татарларның

тоткан урыны» дип аталган фәнни-гамәли конференциядә катнашып, «Себердә ислам тарихы» дигән темага доклад ясадым.

Совет заманында Семипалатинск шәһәре шул исемдәге өлкә үзәге булып тора, хәзер исә үзәк Усть-Каменогорскига күчерелгән. Биредән ерак түгел атом-төш коралы сынау урыны (Семипалатинский ядерный полигон) булган, аның зарарлы шаукымы халыкка шактый зур зыян салган. Әле 1959-нчы елда гына да Семипалатински шәһәрендә 22 мең татар яшәгән, хәзер шуның яртысы гына калган, сәбәбе – күпләп күчеп китүләр, катнаш никахлар һәм бу җирләрдә ярты гасырга сузылган атом сынаулары аркасында булган үлем-җитемнәр... Шәһәрдә хәзер өч йөз меңләп кеше яши, шуның 12 меңе – татарлар. Шушы авыр шартларга һәм язмыш сынауларына карамастан, Семей-Җидепулат татарлары бүген дә биредә тулы канлы тормыш белән яшәп яталар. Аларның монда чирек гасыр инде татар иҗтимагый үзәге эшләп килә, «Хак» дип аталган Иртыш буе татар-башкорт оешмасы бар, бөтен Казакъстанга бердәнбер Татар сәнгать мәктәбе дә шулай ук биредә эшли. Ә Семей шәһәренең «Иртыш моңнары», «Гөрләвек», «Илһам», «Истәлек», «Күңелле балачак» ансамбльләрен хәзер хәтта чит илләрдә дә беләләр. «Көзге Иртыш моңнары» дип аталган халыкара татар сәнгать фестивале инде егерме биш тапкыр уздырыла, анда бөтен Россиядән килгән сәнгатькәрләр көч сынаша. Бу милли эшләрнең барысының да башында Татар сәнгать мәктәбе директоры Габделхак Ахунҗанов тора.

Соңгы елларда Җидепулат татарлары миллилекне саклап калуның яңа, фәнни юлларын да эзли башладылар һәм тарихка мөрәҗәгать иттеләр. Биредә инде берничә тапкыр татар тарихына караган фәнни-гамәли конференцияләр уздырылды, аларда милләтебезнең үткәне һәм киләчәгенә тирән анализ ясалды. Шулай ук биредә инде егерме елга якын «Җидепулат татарлары» дип аталган газета чыгып килүен дә әйтергә кирәк, аның баш редакторы – әнисе ягыннан алман, әтисе ягыннан белорус Виктория Купцова, ул үзе Казанда ислам динен кабул иткән. Виктория ханымның газетасы өчен русча язган мәкаләләрен озак еллар буе Казаннан Рузия Сафиуллина һәм Чаллыдан мин татарчага тәрҗемә итеп, җибәреп тордык. Бу газета һәм аның мөхәррире Виктория Купцова Казанда уздырылган «Бәллүр каләм» бәйгесендә дә җиңеп чыкты. Виктория ханым татарлар уздырган бөтен милли чараларның үзәгендә кайный, Габделхак әфәнде белән бергә, аларны башлап йөрүче булып тора.

Әлбәттә, мин дә биредә Җидепулаттагы татар тарихын, милли хәрәкәт тарихын өйрәндем, бу хакта язып та чыктым. Шулай ук шәһәрнең атаклы Татар бистәсенең (Татарский край) өч мәчетендә, музейларында, тарихи урыннарында да булдым, милләттәшләрем белән махсус очраштым. Би-

редә гомер-бакый төрки халыклар яшәсә дә, Семипалатинск каласының рәсми тарихы 1718-нче елдан, ягъни, урыслар биредә хәрби ныгытма салган вакытлардан башлана. Аның Алаш-кала, Доржинкит-Цорджийнкийд дип йөртелгән чаклары да булган. Хәзерге энциклопедияләр тарихи җиде таш пулатны калмыклар-будда храмнары белән бәйләп аңлатсалар да, Миллер, Паллас һәм аның замандашлары бу биналарны «Таш мәчетләр» яки «Татар-Монгол йортлары», дип язып калдырганнар. Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, бу урында элек тә кала булган, анда төрки кабиләләр, шул исәптән, татарлар да яшәгән. Тарихчы Миллерның язмалары буенча, шәһәрнең исеме дә биредәге таш мәчетләргә нисбәтле бирелгән – Җидепулат, ягъни, Семипалатинск. Татарлар бу шәһәрне элек-электән «Сими» дип атаганнар, хәзер исә кала рәсми рәвештә «Семей» исемен йөртә.

Семей шәһәрендә бүген дә татарлардан калган XVIII–XIX гасыр мәчетләре эшләп тора, алар өчәү. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, революциягә кадәр биредә 12–13 мәчет, 7 мәдрәсә булган, аларның барысын да диярлек татарлар салдырган һәм тоткан. Егерменче гасыр башларында биредә яшәүчеләрнең яртысын, ягъни 15 меңен мөселманнар тәшкил иткән, татарлар белән җирле казакълар сан ягыннан бер дәрәҗәдә булганнар. Менә тагы бер мәгълүмат:

«В марте 1901 г. в Семипалатинске числилось:

– татар – 5015 чел.
– казахов – 4622 чел.
– мулл – 8.
– мечетей – 8», – дип яза җирле тарихчылар [Кашляк: 2004. С. 474].

Әйе, заманында Җидесу төбәге татарларның Ана Ватаннары булган! Узган гасыр башларында Җидепулатта мәчетләр, мәдрәсәләр гөрләп эшләп торган, әйткәнебезчә, мәчетләрнең барысы да диярлек татарларныкы булган, бары тик бер мәчетне генә үзбәкләр тоткан һәм ул Уфадагы Диния нәзарәтенә буйсынмаган. Җидепулат тарихына чын мәгънәсендә ташлар белән уелып язылган татарлар да бар, алар – бертуган Мусиннар. Бу бай татарлар биредә XIX–XX гасырларда яшәгәннәр, таш йортлар, мәчет-мәдрәсәләр салдырганнар, күп илләр белән сәүдә иткәннәр. Мусиннар Җидепулатта беренче пар тегермәннәрен төзиләр, Иртыш елгасында дистәләрчә пароходлар, баржалар тоталар, шулай итеп, Иртыш елга флотилиясенә нигез салалар, беренче банклар ачалар. Бүгенге көндә дә Семейда бертуган Мусиннар исемендәге урам һәм мәчет бар, алар салдырган һәм яшәгән йортлар һаман да саклана.

Ләкин, кызганычка каршы, Мусиннар турында мәгълүмат шактый аз булып чыкты, 2017-нче елда Казанда басылып чыккан «Татары Казахстана» энциклопедиясендә дә аларга махсус мәкалә багышланмаган. Дөрес,

Семей шәһәре турындагы мәкаләдә Мусиннар турында бернчә җөмлә бар, әйтик, 1910-нчы елда Л. Мусинның шәһәрдә бер манаралы мәчет төзетүе, бертуган Мусиннарның калада мәктәп, мәдрәсә ачулары, татар театрына нигез салулары язылган [Татары Казахстана: 2017. С. 344]. Кемнәр булган ул бертуган Мусиннар, язмышлары нинди, кайдан килеп–кая киткәннәр? Биредә нәсел дәвамчылары калганмы? Энциклопедиядә моңа җавап юк. Тарих фәннәре докторы Радик Салихов, Түбән Оры авылы татар байлары Хәсән һәм Муса Хуҗасәетовларның, әле 1817-нче елда ук Семипалатинскида сәүдә эшләре башлап җибәрүләрен яза. Бәлки, шушы Муса Хуҗасәетов нәселе соңга табарак Җидепулаттагы данлыклы Мусиннар булып киткәндер [Салихов: 2015. С. 42]?

Семейда хәзер дә Мусиннарның игелекле эшләрен дәвам итүче татарлар бар, алар эре эшмәкәрлек белән шөгыльләнәләр, милләткә иганәчелек ярдәмен күрсәтәләр. Шундыйларның берсе – Эльдар әфәнде Байканов. Ул өлкәнең Башкүл татар авылында туып үскән, Семейда белем алган һәм эш башлаган, хәзер исә Алматы шәһәрендә «Казэлектромонтаж» оешмасын җитәкли, «Бизнес-клуб «Казан» дип аталган иҗтимагый фондның президенты, туган авылында мәчеткә һәм мәктәпкә даими ярдәм итеп тора, анда ферма тота. Миңа Эльдар әфәнденең Семейдагы квартирасында да, аның белән бергә туган авылы Башкүлдә дә булырга туры килде. Аз сүзле, әмма милли рухы, кешелеклелеге һәр гамәлендә чагылыш таба аның. Ул өенең иң түренә әтисенең гармунын, татар кылычы һәм милли сөлге элеп куйган, шул ук вакытта динне хөрмәт итә, мәчетләрне, ялгыз карт-карчыкларны да ярдәменнән калдырмый. Эльдар әфәнде Байканов Семей шәһәрендә узырылган халыкара татар сәнгате фестиваленең төп иганәчесе, ел да 1 мең евролык Гран-при акчасын җиңүчеләргә ул биреп бара.

Милләтебезгә эчкерсез ярдәм итүдә Эльдар әфәнде ялгыз түгел. Семей шәһәрендә яшәүче һәм татарларга ярдәм итеп торучы тагы бер эшмәкәрне атап үтәсем килә, ул – Рафаэль әфәнде Хаҗипов. Рафаэль әфәнде биредә беренче кооперативларны оештырып җибәргән кеше, ул «Семей – Туган җир» җитештерү компаниясен гамәлгә куючы, «Милли Семей», Кытай-Казакъстан уртак предприятиесен җитәкләүчеләрнең берсе, «ИП Хазипов» предприятиесенең генераль директоры. Мин аны Семей халкы арасында «Утрау» дип аталган тарихи урында, атом-төш корбаннарына куелган һәйкәл-стелланы һәм мәйданны төзекләндерү белән идарә иткән вакытында очраттым. Ул елны Семипалатинск атом-төш кораллары сынау полигоны ябылуга 20 ел тула иде, шул уңайдан зур кунаклар көтелә һәм барысы да яңадан төзекләндерелә икән. Әйе, бу гаять җаваплы эш тә татарлар кулында булып чыкты. Бу урын татарлар өчен дә бик

истәлекле, алар Иртыш буйларындагы тормышларын нәкъ менә шушы утрауда башлап җибәргәннәр. Хәзер биредә татарларның Сабантуйлары үткәрелә, ә Рафаэль әфәнде Хаҗипов ел да үз акчасына сыер суеп, Сабантуй кунаклары өчен пылау пешертә һәм халыкны бушка сыйлый икән...

Әйткәнебезчә, Семей шәһәре элек-электән татарларның дини һәм мәдәни үзәге булган, алар биредә ныклы тамыр җибәреп, дөньяны шаулатып яшәгәннәр. Шәһәрнең «Татарский край» дип аталган Татар бистәсе бүген дә ачык һавадагы гаҗәеп музейны хәтерләтә! Күз алдыгызга китерегез – моннан 100, хәтта 200 ел элек татарлар тарафыннан салынган икешәр катлы таш яки карагай йортлар, манаралары күккә ашкан мәчетләр, мәдрәсә биналары, гектарларга сузылган, әйләнеп чыгу өчен генә дә күп вакыт кирәк булган, меңләгән милләттәшебезне үз куенына алган борынгы татар зираты... Бу зиратны совет заманында җир белән тигезләп, өстенә йортлар салмакчы булганнар, бәхеткә, үзгәртеп кору чоры җитеп, Казакъстан аерым дәүләт булып СССРдан аерылып чыкты һәм үз кануннары буенча яши башлады. Казакълар алар, ни дисәң дә, дини халык, Аллаһтан куркалар, дин белән бәйле нәрсәләрне хөрмәт итәләр, һәм Семей шәһәрендә борынгы татар зираты өстенә йортлар салырга ирек бирмәде. Таш койма белән уратып алынган ул зиратның очы-кырые күренми, монда, гади халык белән бергә, муллалар һәм галимнәр, ишаннар һәм изгеләр дә күмелгән, халык аларны исемләп белә һәм догасыннан калдырмый... Бу татар зиратын казан галимнәре килеп, махсус өйрәндеме икән? Андагы кабер ташлары укылганмы? Дала куенында кемнәребез ятканы ачыкланганмы? Миңа бусы билгеле түгел.

Семейда мин татарлар турында бик күп яхшы хәбәрләр һәм истәлекләр ишеттем, шуларның кайберләрен укучыларга да җиткерәсем килә. Әйтик, биредә «оча торган татар» турында риваять-легендаларга тиң хәлләр сөйләнә, аңа багышлап фәнни конференцияләр үткәрелә, мәкаләләр язылa. Әгәр бу хәл XX гасырның урталарында булса, моңа гаҗәпләнмәс идек, әмма «оча торган татар» Гали Сарыбаев, көймәсенә канатлар куеп, XIX гасырның сиксәненче елларында Иртыш өстенә күтәрелә, очып, аргы якка чыга, чәчәк җыеп, кире кайта... «Шура» журналының 1914-нче ел, 9-нчы санындагы З. Алиханов мәкаләсенә таянып, Семей шәһәре тарихчылары менә нәрсә яза:

«В назначенный день все жители Семипалатинска, от мала до велика, собрались на высоком берегу реки Иртыша смотреть полет часовщика Гали. Вскоре сюда прибыл на своем аргамаке и сам виновник события, в телеге лежала его летающая лодка. Лодка и крылья окрашены в разный цвет. Крылья из хлопчатобумажной ткани приводятся в движение рукой через шестерни и колесики, как часовой механизм. Гали поставил лод-

ку на возвышенное место, сам в нее лег, помахивая крыльями, поднялся примерно на 15 сажень и улетел. Перелетев через реку, приземлился, вышел из лодки, собрал цветы, положил их в лодку. Снова взлетел, вернулся на этот берег и тотчас поехал домой» [Киляоглова: 2009. С.37].

Шәһәрнең Невзоров исемендәге музеенда мин «оча торган татар»-га багышланган ике картина күрдем, аның берсе бигрәк тә тәэсир итте. Өстә, болытлар арасында, көймә очып бара, аңа чалма кигән ир-ат баскан, ә аста – елга, шәһәр, зәңгәрсу-яшелгә буялган мәчет һәм оча торган көймәгә карап өрүче, аны куа баручы кара-соры этләр өере... Бу хәлләр булганнан соң, «оча торган татар» артыннан полиция килеп җитә, көймәгә протокол төзиләр, Гали Сарыбаевны хөкемгә тартырга телиләр. Әмма татарлар аны яклап кала, ә полиция Гали Сарыбаевтан «башка беркайчан да очмаска» дип кул куйдыра... Шушы бер вакыйгада гына да күпме мәгънә, нинди фаҗига һәм бөеклек! Җанын, йөрәген янып торган мотор итеп, татар кешесе мең могҗиза белән күккә күтәрелә, дөньяда беренче булып очып күрсәтә, ә аңа... «башка беркайчан да очмаска, күккә күтәрелмәскә!», дип кисәтү ясыйлар... Шушы бер вакыйгага да татарның бөтен бөеклеге һәм фаҗигасе сыеп беткән...

Семей шәһәрендә телдән-телгә легенда итеп сөйләнә торган тагы бер кеше бар, ул – Карый абзый. Аның үз исеме Шакирҗан Сабитов була, ул 2 айлык вакытта чәчәк авыруыннан сукырая, 8 яшендә дөм ятим кала. Сукыр бала әтисенең туганнарында үсә, мәдрәсәгә йөри, сукырлар мәктәбендә укырга-язарга өйрәнә. Соңыннан ул сукырлар мәктәбендә укытучы һәм директор булып эшли. Әмма ул халык күңеленә Коръәнне дөрес итеп, гаҗәеп моңлы тавыш белән укучы Карый абзый, дин әһеле, имам буларак кереп калган. Әле мәдрәсәдә укыган елларында ук остазы Мөхәммәтгали Әюпов сукыр балага Коръән серләрен аңлаткан булган, малай ишеткән аять-сүрәләрне шунда ук күңеленә сеңдереп, кабатлап бара торган булган. Шәхес культы елларында Сталин палачлары остазын атып үтергәннән соң, Карый абзый тулысынча дин эшләренә күчә, Зәңгәр мәчеттә имамлык итә.

«Без малого 70 лет мусульмане Семипалатинска жили молитвами Кари: рождались, вырастали, обзаводились семьями, умирали – и все это под благословением Божьим устами Кари Шакиржана Сабитова», – дип язып калдырган шәһәрнең хөрмәтле кешесе Хәдичә апа Баймуратова [Баймуратова: 2011. С.79].

Семей халкы Карый абзыйны үзе исән чакта ук изгеләр рәтенә керткән, аның фатихасын алып калырга тырышкан. Биредә сөргендә булган чеченнар аны үзләре белән Кавказга китәргә үгетләгәннәр, сукыр Карый ризалашмагач, хәтта урларга да теләгәннәр. Урта Азиядән килгән мөсел-

маннар да аны зурлап үзләренә алып китәргә теләгәннәр, әмма Карый абзый үлгәнче үз милләтенә, Семей халкына хезмәт иткән, бу изге җанның урыны җәннәттә булсын! Мин Карый абзый эшләгән мәчеттә дә, яшәгән йортында, туганнары янында да булдым, аның рухы өчен догаларымны кылдым... Һәм нәтиҗәгә килдем – Аллаһның хикмәте нинди зур: дин иң тыелган заманнарда бер сукыр татар бөтен милләтенә ислам нурын тарата, изге догалары белән халкын саклап кала...

Мин ышанам, Семей халкы ничек итеп «оча торган татар» һәм Карый абзыйны зурлап искә ала, алар эшен үзенчә дәвам итүче Габделхак Ахунҗанов та халык күңеленә эчкерсез, милли җанлы, гомерен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган кеше буларак кереп калачак. Ул Казакъстанда гына түгел, бөтен Себер буенча, баянын күтәреп, татар халкын уятып йөри, Тубылда, Омскида, Новосибирскида уздырылган бөтен милли чараларда, фестивальләрдә катнаша, алар белән җитәкчелек итә. Габделхак Ахунҗанов шулай ук Казанда, Кырымда, Финляндиядә уздырылган милли чараларның түрендә була. Габделхак әфәнденең озак еллар буе милләткә эчкерсез хезмәт итүен күреп, аңа татар байлары да ярдәмгә килә, ул чакырганда татар зыялылары да дөньяның читеннән булса да Семейга килеп җитәләр... Биш вакыт намазын калдырмаган, инсульт һәм авыр операция кичергән һәм карт анасын үлгәнче кулларына күтәреп йөрткән Габделхак әфәнде улларының, оныкларының рәхәтен күреп, милләтнең кадерлесе булып, бәхетле гомер кичерсен иде!

Бу якларга килгәч, көннәрем санаулы булса да, инде берничә татар авылына да барып кайтасым килде. Биредә татар авыллары күп түгел, булганнарының да бер өлеше күрше Алтай краена, бер өлеше Новосибирски өлкәсенә кереп калган. Менә без хәзер Семейдан көнбатышка таба, Павлодар юлы белән ике татар авылына барабыз. Заманында бу урман-дала зонасы булган, әмма соңгы вакытларда меңьеллык карагай урманнарын ут төртеп яндырып, агачын Кытайга сатканнар, бу тирәләр хәзер куркыныч һәм ямьсез төс алган. Юллар начар, кер бәләге кебек сырлы-сырлы, сикәлтәле, далада авыллар сирәк очрый, нибары берничә казакъ һәм берничә урыс казагы авылларын күрдек. Менә олы юлдан уңга борылып, дала уртасындагы ялгыз мәчеткә таба барабыз, бу – Аккултык (Аккүл) авылы икән. Авылда нибары ике йорт, ике әби, зират һәм менә шушы борынгы мәчет кенә утырып калган. Тарихи чыганаклар буенча, бу авылның мәчете 1812-нче елда, бер кадак кулланмыйча салынган, борынгы архитектура истәлеге булып тора. Авыл Семейга чагыштырмача якын булганлыктанмы, китәсе кеше китеп беткән. Мәчетне дә өлкә үзәге Усть-Каменогорски шәһәренә музей итеп күчереп салмакчы булганнар, әмма сүтәргә менгән кешеләр я егылып төшкән, я кулын сындырган, я

имгәнгән. Хәзер мәчеткә кагылмыйлар... Ул, татар тарихының үзе булып, дала уртасында берьялгызы горур басып тора... Милләтнең яңадан дингә килүен, үзенә кереп, намаз укуын көтеп тора кебек даладагы бу ялгыз татар мәчете... Авылда 86 яшьлек Сәхипзадә әби һәм аның туганының кызы Гөлчирә яши икән, соңгысы, казакълар белән никахлашып, хәзер казакъ оныкларын үстерешә. Алар да шушы тирәдә яши икән, чөнки дала иркен, җир күп, кеше аз... Без дә – әнисе ягыннан тамырлары шушы авылдан булган Габделхак Ахунҗанов, Эльдар Байканов һәм мин, Сахипзадә әби янына кереп хәл белдек, хәерләребезне бирдек, фатихасын алдык. Алга таба юлыбыз Эльдар әфәнденең туган авылы Башкүлгә иде...

Бетеп барган Аккултык авылыннан соң Башкүл безгә бу яктагы татарларның башкаласы кебек күренде. Без килә-килешебезгә үк урта мәктәптә уздырылып ята торган тантанага эләктек, аңа Алматыдан зур кунаклар, район үзәге Бескарагайдан хакимият башлыгы һәм аның ярдәмчеләре дә килгән иде. Без дә халык алдында чыгышлар ясадык, бүләкләребезне бирдек. Семейдан 150 чакрымнар көнбатышта урнашкан, Семипалатинск атом полигоныннан ерак булмаган бу татар авылы, Аллаһның рәхмәте белән, һаман яшәп ята... Башкүлдә биш йөзләп кеше яши, барысы да диярлек татарлар. Чирәм җирләр заманында авыл миллионер колхоз булган, хәзер дә аягында нык басып тора. Авылда урта мәктәп, мәчет бар, музей, балалар бакчасы, ашханә, медпункт эшләп тора. Башкүл авылы элек тә мәчет-мәдрәсәле авыл булган, авылда хаҗилар да яшәгән, биредә кырыклап тегермән эшләп торган.

Башкүлдә тарих белән бик кызыксыналар, авылга 1837-нче елда, Казан ягыннан килгән татарлар нигез салган, дип баралар, шуңа күрә 2007-нче елда зурлап Башкүлнең 170 еллыгын уздырганнар, Сабантуйда бәйрәм иткәннәр. Мәчетнең 1857-нче елда төзелгәнлегенә Томск архивыннан документлар да табып алып кайтканнар. Авылда татар үзәге эшләп килә, аның рәисе – Люция Хәмитова, Люциянең Семейда яшәүче бертуган абыйсы Ринат Хәмитов бөтен районның татар хәрәкәте җитәкчесе, ул туган авылына багышлап берничә диск чыгарган, фәнни конференцияләрдә катнашып, шул темага докладлар ясаган, Башкүл турында китап язган. Кыскасы, биредә татарлар бик актив тормыш белән яшиләр. Ярты гасырга сузылган атом афәтенә дә бирешмәгән, дала уртасында берьялгызы татарлыкны саклап яшәгән бу авылның киләчәгенә мин ышанам, чөнки аның халкында әле милли рух сүнмәгән, әхлак бетмәгән, аның әле Эльдар Байканов, Ринат Хәмитов кебек уллары, милләт, дип, җан атып торалар!

Көнчыгыш Казакъстанның Жезкент шәһәреннән ерак түгел, Россия чигендә, Ивановка дип аталган бер авыл бар. Бу авылда элек гел алманнар гына яшәгән, немецлар бирегә Екатерина II заманында килеп урнашкан-

нар, дип сөйлиләр. Сөрген вакытында да Ивановкага җибәрелгән алманнар булган. Инде узган гасырның 90-нчы елларында күпчелек немецлар Германиягә күчеп киткән. Авылда хәзер алманнар, казакълар, руслар һәм... берничә бөртек татар да яши. Авылның Ак әбие Хәйфә апа Галиевага мин бирегә килгәндә 88 яшь иде. Хәйфә апа – Ырынбур өлкәсенең Иске Котлымәт авылыннан, бала чакта ук әнисе белән Таҗикстанга күчеп киткән булалар, ул шунда үсеп, кияүгә чыгып, анда 58 ел яши. Кызы Римма Ивановка авылының алман егетенә кияүгә чыккач, бу якларга килеп йөри башлый. Әби авылны ярата һәм ире үлгәч, улы, оныклары белән монда күчеп кайта. Кызы Римма ире һәм балалары белән Германиягә күчеп киткәч, Хәйфә әби 5 тапкыр анда барып кайта, аларга якын булырмын, дип, Калининградка күчә. Әмма эзләп-эзләп тә анда мөселман зиратын таба алмагач, мине үлгәч ничек күмәрләр, дип бик елый һәм тагы авыру улын, оныгын, оныкчыгын алып, Ивановкага кайтып урнаша, чөнки анда казакъларның мөселман зираты бар. Бу хәл 2004 елда була. Әби теге вакытта йорт-җирен, мал-мөлкәтен сатып киткән була, монда кайткач, тагы алманнардан калган өйне сатып ала һәм улы, оныкчыгы белән анда яши башлый. Ивановкада хәзер аның ире ягыннан туганы Флера һәм аның ире Айдар Туйкиннар да яши.

2016-нчы елда Казакъстанга баргач, мин Хәйфә апа белән махсус таныштым, авылларында, өйләрендә булдым, безнең янга башка татарлар да килде. Хәйфә апа – чын мәгънәсендә бу алман авылының Ак әбие, киңәшчесе, биредә барлык җыеннар, милли-дини чаралар аның катнашында уза. Аны казакълар да, алман-руслар да бик хөрмәт итәләр, хәтта район җыеннарына да чакырып сүз бирәләр. Нәүруз бәйрәмендә исә Хәйфә апа пешергән татар ризыклары табынның түрендә була. Хәзер Хәйфә апа авылда мәчет ачтыру артыннан йөри, моның өчен ул берәр йортны сатып алырга җыена, инде районда бу хакта әйткән. Хәйфә апаның үзенең дә тормышы мул, алар абзар тутырып мал-туар, кош-корт тоталар, бакча тулы яшелчә-җимеш, өстәлдә исә ризыкның ниндие генә юк!

Әйе, татарны кайда да татар иткән, яшәткән төп сыйфатлар – аның гаять тырышлыгы, тәвәккәллеге һәм иман-әхлагы икән, дала уртасында 88 яшьлек татар әбие белән очрашкач, мин әнә шундый фикергә килдем. Хәйфә апаның төп ярдәмчеләре – янындагы улы, Жезкентта хакимияттә эшләүче оныгы һәм Чыңгыз исемле оныкчыгы. Ә рухи, милли яктан төп ярдәмчесе, киңәшчесе – Жезкент шәһәренең имамы, милләттәшебез Рамил хәзрәт Рәхимбаев, алар даими аралашып, күрешеп торалар. Рамил хәзрәт бу төбәктәге һәр татарны белә, аларны барлап, хәлләрен белеп тора, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын! Узган ел бөтен авыл белән Хәйфә апаның 90 яшен билгеләп үткәннәр, юбилейга аның Себердәге

һәм Германиядәге балалары һәм оныклары, татарлар һәм казакълар, алманнар һәм урыслар – барысы да җыелган. Намазлы, иманлы, булдыклы, милли рухлы бу татар әбиенә бар халык җыелып рәхмәтен әйткән. Озак, бәхетле яшә, Хәйфә апа, син милләтебезнең Ак әбие, догачысы бит...

Алай да, минем Казахстанда ачыклап бетермәгән берничә соравым калды. Аның беренчесе – танылган язучы Чыңгыз Айтматовның татар әбисе Газизәбану турында. Аның турында мәгълүмат бик аз, хәтта оныкларында да юк, дип әйтерлек. Шунысы гына билгеле – Газизәбану Семипалатинск каласында туган, кыз фамилиясе – Шаһиева, себер татары, бай кызы булган, дигән сүзләр дә йөри. 1886-нчы елда аны җизнәсе, Җидесу төбәгенең иң зур татар бае Исхак Габделвәлиев абыйсының улы Хәмзәгә кияүгә бирә. Болар – Кукмара төбәгенең Мәчкәрә авылыннан килеп урнашкан сәүдәгәрләр. Исхак Габделвәлиев үзе Верный, хәзерге Алматы каласында яши, анда зур-зур кибетләр тота, Кытай, Россия һәм башка илләр белән сәүдә итә, хәйриячелек белән шөгыльләнә.

Хәмзә Хәсән улы Габделвәлиев исә гаиләсе белән Каракол каласына урнаша, ул да тиздән төбәкнең иң зур баена әйләнә, хәйриячелек белән шөгыльләнә. Хәмзә белән Газизәбануның сигез балалары туа, Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә – бишенче бала. Нәгыймә әнисенә охшаган була – ак йөзле, зур яшькелт күзле, туры борынлы, холкы бик сабыр һәм тыйнак. Моның өстенә, Газизәбану бик дини дә була, исән чагында хәтта фотога да төшми. Аның бердәнбер фотосы – үзе үлгәч төшерелгән. Эш шунда, хакимияткә большевиклар килгәч, Хәмзә байның бөтен байлыгы талана, йорт-җирләре тартып алына, нәтиҗәдә уллары Сабирҗан, революциягә кадәр Европада югары белем алган зоотехник, ата-анасын үзе белән Үзбәкстанга алып китә. 1931-нче елда Газизәбану Нәманган шәһәрендә үлә, шунда җирләнә. Нәгыймә ул вакытта икенче улы Илгизгә авырлы була, Фрунзе шәһәреннән әнисен соңгы юлга озатырга килә алмый, моңа бик борчыла, елый. Нәгыймәгә әнисенең җеназасыннан бердәнбер фотоны төшереп җибәрәләр (Бу фото моңа кадәр бер генә җыентыкка да кермәде, бирedә фәнни кыйммәте булганга тәкъдим ителә). 1932-нче елда Нәгыймәнең әтисе Хәмзә дә үлә, ул Ташкент шәһәрендә җирләнә. 1934-нче елда, халык дошманы, дип, Сабирҗан Габделвәлиевнең үзен дә судсыз-нисез атып үтерәләр...

Чыңгыз Айтматовның кыргыз әби-бабалары турында фәнни хезмәтләр, истәлекләр, китаплар язылган, ә татар әби-бабасы турында хезмәтләр бик аз, юк дәрәҗәсендә. Гәзизәбану Шаһиева-Габделвәлиева тармагы бөтенләй өйрәнелмәгән. Дөрес булса, аны Казакъстанның элеккеге башлыгы Динмөхәммәт Кунаевның татар әбисе белән бертуган булган, дип тә сөйлиләр. Кунаев үзе Айтматовка: «Без бит синең белән әбиләр

ягыннан туганнар», – дип әйтә торган булган. Кызганычка каршы, Россиядә 1897-нче елда уздырылган беренче халык саны алу мәгълүматлары Каракол-Пржевальск буенча юкка чыккан. Казакъстанда һәм Кыргызстанда яшәүче милләттәшләребез шушы юнәлештә эзләнүләр алып барсалар яхшы булыр иде.

Ачыклап бетермәгән икенче соравым – Исхак Габделвәлиевнең үзе турында. Халык арасында аны «Исхак хаҗи» дип атап йөрткәннәр, 1858-нче елгы ревизия материалларыннан күренгәнчә, ул Мәчкәрә авылында 1841-нче елда туган булырга тиеш, күп хезмәтләрдә язылганча, 1839-нчы елда түгел. Ул яшьтән үк Казан, Оренбург, Троицк, Эрбеттә сәүдә тирсендә эшләп байый, Семипалатинскида һәм Кызылъяр-Петропавелда үзенең сәүдә үзәкләрен ача, соңыннан Верныйга килеп урнаша. Исхак хаҗи 1880-нче елларда Мәчкәрәгә кайтып, абыйсы Хәсәннең балалары Хәмзә, Әхмәтгали, Галияне үзе белән Урта Азиягә алып китә, шулай итеп, Габделвәлиевләр Караколда урнашып калалар. Дөньяга даһи тудырасы татар анасы шушы нәселдән чыга. Әйткәнемчә, Исхак хаҗиның хатыны да Җидепулат татары була, ягъни, Гәзизәбануның бертуган апасы. Боларның да алга таба язмышлары билгесез.

Хәзерге Алматада татар бае Исхак Габделвәлиевның зур-зур таш кибетләре, «Пассаж» биналары сакланып калганлыгын беләбез, ул үзе 1911–нче елда үлә һәм Верный шәһәренең мөселман зиратына җирләнә. «Татары Казахстана» энциклопедиясендә Исхак Габделвәлиевкә аерым мәкалә багышланган, анда Исхак хаҗиның уллары Йосыф, Котдус, Габделхак, Габдрәүфнең этиләре эшен дәвам итүләре турында язылган. Бүген Алматада бу танылган нәселнең дәвамчылары яшиме, алар ата-бабаларының кемлекләрен беләләрме икән? Бу теманы аерым өйрәнүчеләр бармы икән? Сорауларым хәзергә ачык кала...

«Татарские купцы Габдулвалиевы внесли значительный вклад в развитие народного просвещения татар и других тюркских народов Семиречья, – дип яза галимнәр. – На их средства в г. Верный было построено медресе «Исхакия», в котором преподавали выпусники лучших новометодных медресе Казани, Оренбурга и других городов России. Благотворительность Габдулвалиевых проявилась и в другой сфере. Во время русско-японской войны 1904–1905 гг. И. Габдулвалиев, как и другие татарские предприниматели, весной 1904 г. выделил для выдачи пособий российским воинам и раненным на Дальнем Востоке 500 руб.[1], для того времени это была огромная сумма» [Татары Казахстана: 2017. С. 67–68].

Әйе, татарлар Казакъ иленең үсешенә, аның икътисадына, мәдәниятенә, мәгарифенә, тарихына искиткеч зур өлеш керткәннәр. Буш далада беренче

[1] Бер атның бәясе 25 сум булган (Ред.).

таш калалар, беренче мәктәп һәм мәдрәсәләр, беренче китап-дәреслекләр, мөгаллим һәм муллалар, беренче завод-фабрикалар, флотилияләр һәм юллар – болар барысы да милләттәшләребезнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Бүгенге көндә Казакъстанда 200 меңнән артык татар яши, алар да илнең үсешенә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Дөрес, күп өлкәләрдә – диндә, мәгарифтә, фәндә казакъларның үз белгечләре дә өлгереп-үсеп җитте инде, әмма алар янәшәсендә җилкә куярлык, киңәш бирерлек татарлар да бар. Дала өстендә ислам кояшын күтәргән, мәгърифәт нурын тараткан тарихи остазларыбыз, аңлаган, кадерен белгән кешегә авыр вакытларда таяныр terәгебез бар. Татар халкы бар.

*2011–2016–2019 еллар*

**Әдәбият**


1. Баймуратова Хадича. С любовью к людям. Семей, 2011.
2. Бәйрәмова Фәүзия. Ана. Казан, 2015.
3. Бәйрәмова Фәүзия. Милләтемә хезмәт иттем. Казан, 2013.
4. Государственный архив Кировской области. Ф. 172. Оп. 2. ДД. 1670–1153.
5. Кашляк В. Н. Храмы Семипалатинска: прошлое и настоящее. Семипалатинск, 2004.
6. Киляоглова С. Р. Летающий татарин: мечта и действительнось. // Тюрко-татары в современном мире: прошлое, современность, пути развития. Семей, 2009.
7. Пресняков Сергей. Хроника событий в истории татар. // Татары на севере Казахстана. Петропавловск, 2004.
8. Салихов Р. Р. Служилая Ура: рождение татарского капитализма. Казань, 2015.
9. Таиров Н. Габдулвалиев: Татарский купец и благотворитель // Гасырлар авазы–Эхо веков. 2003, № 1–2.
10. Татары Казахстана. Казань, 2017.

## ПИСЬМО СООТЕЧЕСТВЕННИЦЫ-СТУДЕНТКИ ЗАРУБЕЖНЫХ УНИВЕРСИТЕТОВ В НАШУ РЕДАКЦИЮ

Меня зовут Милана, я выпускница Американского Университета в Болгарии по двум специальностям: Бизнес Администрирование и Психология. Мой учебный путь начался с языковой школы при Американском университете в Болгарии. Проучившись год и подтянув свой уровень английского языка, я с успехом сдала проходной экзамен в американский вуз. В течении 4-х лет учебы я накопила опыт общения с ребятами из разных стран, посетила множество интересных мест и набралась важных для жизни навыков.

Я активно участвовала в студенческой жизни университета. Каждый год я представляла свою страну на «Международной неделе»–время, когда студенты рассказывают и делятся традициями своих стран. Будучи татаркой, я предложила представить Россию некоторыми блюдами татарской кухни: чак-чак, вак беляши, кыстыбый. Иностранные студенты охотно угощались и спрашивали у меня рецепт.

Помимо организаций различных мероприятий, я также участвовала в студенческих клубах. Одним из самых популярных является бродвейское шоу, которое студенты ежегодно проводят как в университете, так и в разных городах Болгарии. Я прошла кастинг и попала в команду танцоров. За два года занятий и работы, успела выступить десятки раз, гастролируя по всей Болгарии.

Учеба зарубежом открыла для меня много возможностей! Я успела поучится и поработать в Штатах и пройти учебный обмен в Германии. Первый визит в Америку произошёл после первого курса через программу Work&Travel, которая даёт возможность иностранным студентам работать в сфере обслуживания в любом штате страны и заработать на дальнейшую учебу. Моя мечта оказаться в Америке зародилась еще в раннем детстве, во время просмотров американских фильмов под Новый Год. Меня тогда заинтересовала далекая жизнь на Западе со всем ее укладом. Тогда я не могла себе представить, что через несколько лет моя мечта осуществится. Я провела в Штатах два лета выполняя разного вида работы, такие как официант, хостес и прочие. Меня очень впечатлила американская жизнь и я пообещала себе вернуться туда снова, но в следующий раз в качестве студента.

На третьем курсе учебы я была выбрана представителем своего университета в Штатах. Так семестр я проучилась в государственном университете Сан-Диего, Калифорния.

## ПИСЬМО СООТЕЧЕСТВЕННИЦЫ-СТУДЕНТКИ ЗАРУБЕЖНЫХ УНИВЕРСИТЕТОВ В НАШУ РЕДАКЦИЮ

После окончания учебы в США, у меня появилась возможность поехать по обмену в Европу. Мой выбор пал на университет города Аугсбург, Бавария.

Вернувшись в свой родной университет, окончила четвёртый курс. Благодарна своему университету за опыт общения в международной среде и хороший багаж знаний, который, надеюсь, поможет мне в будущем.

*Милана Мухаметшина, Болгария*



*Фотография, полученная от М.Г. Мухаметшина, деда Миланы. По правую сторону находятся Шаехзада Бабич и Зуфар Исхаков (преподаватель медресе Троицка). Дата – скорее всего до 1914 г.*

## Шәхесләребез

## Известные личности

# МИЛЛӘТ ХӘДИМӘСЕ



Ошбу елның азагында, тәгаен әйткәндә декабрьнең бишесендә язучы, танылган җәмәгать эшлеклесе, галимә Фәүзия Бәйрәмовага 70 яшь тула. Фәүзия Әүхади кызы Бәйрәмова 1950 елның 5 декабрендә Саба районының Сабай авылында ишле гаиләдә, ун баланың бишенчесе булып дөньяга килгән. Гаиләдәге җиде кызның алтысы, шул исәптән Фәүзия дә Казан дәүләт университетында белем алган. Ф. Бәйрәмова 1958–1962 елларда – Сабай авылы башлангыч мәктәбен, 1962–1966 елларда – Олы Шыңар авылы сигезьеллык мәктәбен, 1966–1968 елларда – Саба урта мәктәбен, 1968–1971 елларда – Казан театр училищесының режиссерлык бүлеген, 1983–1989 елларда, читтән торып, КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган. 2006 елда ТФАнең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында тарихчы Михаил Худяков эшчәнлеге турында кандидатлык диссертациясе яклаган.

1966–1968 елларда Сабада нәшер ителүче «Җиңү байрагы» район газетасында – әдәби хезмәткәр, 1973–1975 елларда – Казан телевидениесендә режиссер ярдәмчесе, (1976–1978 елларда гаиләсе белән Монголия Халык Республикасында яши), 1979–1987 елларда – «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында, «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарында, 1987–1998 елларда Татарстан китап нәшриятында эшли. 1986 елдан – СССР Язучылар берлеге әгъзасы, 1998 елдан – профессиональ язучы, илле китап авторы.

1990–1995 елларда – Татарстан Югары Советы депутаты, 1991 елдан «Итифак» татар милли бәйсезлек партиясе рәисе, 1994 елдан – Татар халкы Милли Мәҗлесе башлыгы, 2002–2017 елларда – Бөтендөнья Татар конгрессының идарә әгъзасы, 2016 елдан Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, Бөтентатар иҗтимагый үзәге президиумы әгъзасы, Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясының рәис урынбасары.

Төрекләрдә, яше җитмеш, эше бетмеш, дигән әйтем бар. Шәт язучы кешенең, сәламәтлеге какшап китмәсә, язарга ниятләгән бәян-романнары әле, алдадыр. Шулай да узган җиде дистә елны беркадәр күз алдыннан кичерик әле дип, әдибә ханым белән әңгәмә кордык.

***– Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек, дигән гыйбарә кайбер шәхесләребезнең тормыш юлына бигрәк тә туры килеп тора. Тәрҗемәи хәлегездән, көтү көтеп үстек, дигән юлларны укыгач, шундый фикергә киләсең.***

– Әти фин сугышыннан яраланып кайткач, авылда колхоз председателе итеп куйганнар. Ватан сугышы вакытында авылда яшәүче ач халыкка икмәкне күбрәк биргән өчен, корткычлыкта гаепләп, 1943 елда хөкем иткәннәр, партиядән чыгарганнар. Әти (Бәйрәмов Әүһади) Свияжск төрмәсендә утырган. Төрмәдән кайткач, «халык дошманы»на җитәкче эшләр бирмәгәннәр, көтү көтәргә генә рөхсәт иткәннәр. Без, ун бала, кечкенәдән көтү көтеп үстек, шуңа карамастан, шушы гаиләдән алты кыз бала Казан дәүләт университетын тәмамлады, бу нәсел милләткә татар язучылары һәм укытучыларын бирде. Мин халык күргән бөтен авырлыкларны да күрдем, «уфалла» арбасына җигелеп, черәшеп йөк тә тарттым, яланаяклап чыклы таңнарда, җәйге чилләләрдә, көзге яңгырларда көтү дә көттем, чулак әти белән пычкысын да тарттым, җирен дә казыдым, печәнен дә чаптым... Мин милләт тормышын кечкенәдән ялан тәпиләрем белән тоеп, авылымның шифалы һавасын күкрәк тутырып иснәп, аның җырлап торган саф татар телендә сөйләшеп үстем. Әле ярый шулай булган! Бөтен язганнарым – туган туфрактан, бөтен язганнарым – милләтемә...

***– «Мин бөтен барлыгым белән галиҗәнап китапка бурычлы, яраткан китапларым мине шәхес итеп күтәрде»***, **– дип әйткәнегез бар.**

–Кечкенәдән китап укырга яраттым. Көтү көткәндә дә кулымда китап була иде... Безнең авыл кечкенә, аның клубында китап укылып беткәч, күрше Олы Шыңар авылыннан ташый идем–кышларын агач чанага арыш капчыгын тутырып китап салам. Аның авызын мунчала бавы белән бәйлим һәм өч чакрым тартып кайтып китәм... Ул вакытта электр юк, көндез китап укып утырырга вакыт юк, кичләрен лампа яктысында укый идем... Әти, керәчин бетереп утырасың, дип аны сүндергәч, тәрәзә янына килеп, ай яктысында укып бетерә идем... Әни, күзеңне бетерәсең, дип кызгана иде... Чыннан да, ул күзләр тор-бара бетте инде, әмма үкенмим–мин китап аша дөньяның зурлыгын һәм матурлыгын танып калдым. Әйе, мине китап кеше итте–уйланырга, хыялланырга, көрәшергә өйрәтте. Ул вакытта тәрҗемә китаплар күп була иде. Фантастиканы үлеп яраттым, «Андромеда томанлыгы»н ун тапкыр укып чыкканмындыр... «Овод» китабы өстәл китабыма әйләнде. Татар язучыларыннан Әмирхан Еники, Фатих Хөсниләрне укып, телебезнең байлыгына, сүзнең кодрәтенә таң калдым.

***–Димәк, Уленшпигель турында да укымый калмагансыз. Хәтерлисездер: Клаас көле йөрәгемне кага... Газиз халкының тарихына кереп чумган, бигрәк тә бәйсез дәүләтен югалткан милләт вәкиле булган шәхесләрдә, нигә без мондый хәлдә соң, элеккеге шанлы исемебезне ничек кайтарырга, гадел тарихыңны кайдан, ничек белергә, дигән сораулар тумый калмый. Шундый уйланулар нәтиҗәсендә фәнгә, милли хәрәкәткә кереп киткәнсездер, дим.***

–Әйе, фәнгә шундый уйланулар китерде. Дөресен генә әйткәндә, татар халкының, Казан ханлыгының гадел тарихын өйрәнүгә бинаһая зур өлеш керткән, нәтиҗәдә халыклар дошманы Сталин иярченнәре тарафыннан «халык дошманы» дип җаны кыелган Михаил Худяковның язганнары, язмышы белән кызыксынып киттем дә, шушы эзләнүләремнең сыгынтысы Мәрҗани исемендәге Тарих институтында якланган «Роль М.Г.Худякова в исследовании истории и культуры народов Среднего Поволжья» дигән темага кандидатлык диссертациясенә әйләнде. Фәнни эзләнүләргә кереп китүемә университетта диплом җитәкчем–Миркасыйм Госманов, институтта фәнни җитәкчем Равил Әмирхановларның тәэсире булмый калмагандыр, әлбәттә. Милләтемнең шушындый зур шәхесләре белән аралашу мине рухи яктан баетты, алган белемемне ныклы системага салырга ярдәм итте, милли-мәдәни юнәлешемне билгеләде.

Үзгәртеп кору сәясәте башлангач, милли хәрәкәт уянды. Табигый, мин дә читтә кала алмадым. 1989 елдан бирле Казан шәһәрендә үткән барлык милли митингларда диярлек катнашып киләм, милләт белән эшләүнең бөтен чараларын файдаланам. 1989 елның 15 октябрендә Казан Кремлен-

дә беренче тапкыр Хәтер көне уздыруны оештырдым, шуннан бирле һәр елны диярлек бу чарада катнашам. 1989 елда Бөтентатар иҗтимагый үзәген оештыруда катнаштым, аның рәис-координаторы булып сайландым, алга таба да бу милли оешманың бөтен корылтайларында һәм эшендә катнаштым. 1990–1995 елларда үзем туып үскән Саба районыннан Татарстан Югары Советы депутаты булып сайландым. Депутат вакытта Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итүдә (1990), Татарстанның яңа Конституциясен кабул итүдә (1992) катнаштым, үземнең проект вариантларын тәкъдим иттем, 1992 елда Референдумны Татарстан файдасына уздыруда актив эшләдем. 1991 елда, Татарстанның дәүләт суверенитетына куркыныч янагач, республикада Россия Президентын сайлауларга каршы сәяси ачлык игълан иттем, аңа егермедән артык кеше кушылды. Нәтиҗәдә, Татарстанда Россия Президенты сайлаулары рәсми рәвештә үтмәде һәм ул бездә сайланмады.

Милли-иҗтимагый юнәлештә дә эшчәнлегемне дәвам иттем. 1990 елда Татарстанда беренче милли партия төзүдә катнаштым. 1991 елның апрелендә узган корылтайда әлеге «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясенең рәисе итеп сайландым, бүгенге көндә дә аның рәисе булып торам. 1993–1998 елларда «Иттифак» партиясе үзенең «Алтын Урда» дип аталган газетасын чыгарды, 1995 елда Татарстан Парламенты сайлауларында катнашты. 1992 елда татар халкының Милли Мәҗлесен оештыруда катнаштым, 1994 елда аның рәисе итеп сайландым, үзем җитәкчелек иткән чорда, 1997 елга кадәр «Татар кануны», «Гаилә кодексы», «Милли мәхәллә» кебек мөһим документлар кабул иттек. 2008 елда яңадан Милли Мәҗлес рәисе итеп сайландым һәм бүгенге көндә дә аның рәисе булып торам.

***– Милли-иҗтимагый эшкә шушылай бирелә торып, иҗаттан читләшмәвегез гаҗәпләндерә. Әйтергә генә ансат: бу елларда илле хезмәтегез дөнья күргән. Күпме йокысыз төннәр...***

– Иҗатым күпкырлы – анда романтик повестьлар да, тарихи романнар да бар, шулай ук балалар өчен әсәрләр дә, фәнни-популяр хезмәтләр дә шактый. Соңгы вакытта тарихи романнар язам. Себер татарлары тарихына караган «Күчем хан» (2007, 2011), «Һиҗрәт» романнары (2017) – шундыйлардан. Шулай ук репрессия корбаннары турында «Кырык сырт» романын яздым (2005), атом радиациясенә дучар ителгән татарлар турында «Караболак» романым дөнья күрде. Татарның бөек шәхесләре турында шактый фәнни-популяр китаплар яздым. Һади Такташ турында «Мишәрнең бөек улы» (2001), Батырша турында «Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше» (2005), «Батырша явы» (2012), «Бәһадиршаһ» (2006), Һади Атласи турында «Соңгы туранчы» (2016), Чыңгыз Айтма-

товның әнисе турында «Ана» (2015), «Татарская мать Чингиза Айтматова» (2018) китаплары, шулай ук урыс халкының бөек тарихчысы Михаил Худяков турында «Михаил Худяков и история татарского народа» (2003), «Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Среднего Поволжья» (2007) китапларым дөнья күрде. Хезмәтләрем һәм иҗатым Казанда басылып чыккан Татар энциклопедиясендә, шулай ук Чаллы шәһәре, Пенза өлкәсе, Пермь крае энциклопедияләрендә яктыртылды, себер татарларының библиографик китапларына кертелде.

Драматург буларак, Казан шәһәренең Яшьләр дәүләт театрында, Минзәлә дәүләт театрында, шулай ук халык театрларында төрле елларда пьесаларым куелды. Казанда, Чаллыда, Әлмәттә, Мәскәүдә, Германиядә һәм Төркиядә 46 китабым татар, урыс, немец һәм төрек телләрендә дөнья күрде.

***– Сезнең иҗатны, эшчәнлекне беләләр – укыйлар, карыйлар, тыңлыйлар, тараталар, дип уйлыйсызмы?***

– Аллага шөкер, әсәрләремнән өзекләр балалар һәм үсмерләр өчен мәктәп дәреслекләренә кертелде, шулай ук алар югары уку йортларында да өйрәнелә. Проза әсәрләрем буенча диплом эшләре язылды, кандидатлык диссертацияләре якланды. Татарстанның барлык шәһәрләрендә диярлек язучы буларак халык белән күп санлы очрашулар уздырдым, берничә тапкыр «Ел китабы» бәйгесендә җиңеп чыктым. Татар тарихы, милли сәясәт һәм әдәбият буенча 1990 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр күп чит илләрдә, шул исәптән Германия, Америка, Голландия, Бельгия, Төркия, Кипр, Дания, Балтыйк буе илләрендә, Кавказ республикаларында фәнни конференцияләрдә катнаштым, докладлар ясадым. Шушы эшчәнлегемне күреп, 2005 елда «Казанның 1000-еллык медале» белән бүләкләделәр. 2001 елда – Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләген, 2004 елда Бөгелмәдәге «Һади Атласи фонды»ның Һади Атласи исемендәге бүләгенә лаек булдым. Мәгариф өлкәсенә керткән зур өлешем өчен 2000 елда Кэмбридж университетының Халыкара Биографик Үзәге «XX гасырның 2000 күренекле галиме» исемле Халыкара биографик энциклопедиягә кертте һәм диплом белән бүләкләде.

***– Билгеле, артыңда ышанычлы тылың булмаса, эшләү, иҗат итү өчен шартлар тудырылмаса, мондый хезмәтләрне башкарып чыга алмаган булыр идегез. Кыскача гына гаилә хәлегез белән дә таныштырып китегез инде.***

– 1991 елдан Чаллы шәһәрендә яшим. Ирем Җәмил Сафиуллин – юрист, 1990–1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты, Чаллы татар милли хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе һәм ул елларда аны җитәкләүче; «Алтын Урда» һәм «Историко-культурное наследие»

газеталарын гамәлгә куючы һәм нәшер итүче, шулай ук үз хисабыбызга чыгарылган барлык китапларымның нәшире.

Балаларым Зөлфия Кадыйр белән Альберт (Сөләйман) Кадыйров Казан шәһәрендә яши. Кызым Кипрда Халыкара мөнәсәбәтләр институтын тәмамлады, Әнкарада аспирантурада, Америкада докторантурада белем алды, сәясәт белгече. Улым Малайзиядә социология һәм журналистика буенча белем алды, Казанда Ислам университетын тәмамлады, чит телләр буенча белгеч һәм татар, урыс, инглиз, төрек, гарәп телләре буенча күп китапларның тәрҗемәчесе.

***– Үзегезне бәхетле дип саныйсызмы?***

– Тормышымда иң сагынып искә ала торган чагым – Татарстанның дәүләт бәйсезлеге өчен көрәш еллары! Милләтнең уянган чагы, үз хокукын даулап, мәйданнарга чыккан чагы... Беренче татар мәктәпләре, мәчетләр, Милли университет ачылган вакытлар... Халыкның һәм хакимиятнең, мәйданның һәм парламентның бер булып, бәйсез Татарстанга нигез салган еллары... Үземнең шушы тарихи вакыйгаларда катнашуымны зур бәхет дип саныйм, моның белән горурланам, без нинди катлаулы елларда яулап алганнарның берәм-берәм юкка чыга баруына җаным әрни...

***– Иң зур хыялыгыз, максатыгыз нидән гыйбарәт?***

– Милләт өчен эшләүдә бер канатым милли сәясәт булса, икенче канатым – милли әдәбият. Максатым – татар халкының дөрес тарихын тергезү, милләткә үзенең үткәндәге бөек һәм фаҗигале тарихын күрсәтү; шулар аша анда милли горурлык хисләре уяту, әсәрләрем аша әхлак тәрбиясе бирү, гамәлләрем аша халыкны үз-үзен сакларга һәм көрәшергә өйрәтү, аңа үрнәк булу. Бурычым – милләтне саклап калу һәм аны дөньяга таныту. Хыялым – татар халкының бәхетле һәм бәйсез көннәрен күрү. Әлбәттә, иң зур хыялым – Татарстанның бәйсезлеге, милләтемнең азатлыгы. Шуны балаларыма, нәселемә, милләтемә дә аманәт итеп әйтеп калдырам. Һәм ышанам: гаделлек барыбер җиңәчәк, чөнки татар халкының бәхетле булырга да, бәйсез булырга да тулы хакы бар!

*Әңгәмәдәш – Рәшит Минһаҗ*

## Татар рухы

## Татарский дух

*Айдар Хәйретдинов*

# МУСА ҖАРУЛЛАҺ (ЯРУЛЛА УГЛЫ МУСА БИГИЕВ): ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ МИРАСЫ

Аллаһның олуг рәхмәте йөзеннән кешеләргә юл күрсәтүче һәм үрнәк буларак җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-саләт вә-с-сәламнең әйтеп калдырганнарына күрә, мөселманнарның диннәрен тергезү өчен Аллаһ Тәгалә һәр йөзьеллыкның башында бер мөҗәддид, ягъни яңартучы җибәреп тора икән. Хәдисче галимнәрнең уртак фикерләренчә, әлеге хәдис ышанычлы дип табылган. Гасыр саен килеп торган мөҗәддидләр арасында татарлардан да галимнәр булган. Андыйларның берсе – Ярулла углы Муса Бигиев – мөселманнарны озак гасырларга сузылган рухи һәм фикри йокыларыннан уятуга үзенең гомерен багышлаган, җанын фида кыйлган бәндә, – какшамас иман иясе, олуг галим, югары әхлак сахибы...

Муса әфәнденең исламияткә кагылышлы гыйльми әсәрләренең саны йөздән артык. Аның әсәрләре Русиядә һәм башка бик күп илләрдә нәшер ителеп, дөнья буйлап таралган. Компьютерлар, информацион технологияләр, интернет мөмкинлекләре белән файдаланучы бүгенге кеше кимәле белән үлчәсәң, гади каләм-карандаш белән кәгазьдә язган бу галимебезнең акылга сыймаслык дәрәҗәдә зур, күләмле вә тирән мәгънәле дини, гыйльми, фәлсәфи, әдәби, иҗтимагый мирас калдырган булуын аңлыйсың. Боларның барысын да галим үзенең эш бүлмәсендә утырган көе генә эшләмәгән. Ул гомере буе бертуктаусыз җир йөзен гизгән, сәфәрләр кылган. Муса әфәнде Алмания, Финляндия, Ләхстан, Япония һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге колонияләр, Госманлыны дәүләтенең Хиҗаз, Шәм Шәриф, Гыйрак, Анадолу, Мисыр кебек биләмәләре, Иран, Әфганстан, Кытай, Һиндстан кебек илләрне зиярәт иткән, анда үз күзләре белән күргән хәл-әхвәлләрне китап-мәкаләләрендә, куен дәфтәрләрендә чагылдырган.

Муса Яруллаһ (бу сүзне ул гарәпчәләштереп Җаруллаһ, ягъни *Аллаһның күршесе* шәкелендә яза торган була), әйтерсең, «җанлы университет» булган, һәм, әгәр бүгенге көндә эшләнсә, йөзләгән белгечләрнең киеренке хезмәтен таләп итәчәк эшне ул берүзе башкарып чыккан. Аның мира-

сы гаять күпкырлы. Галим ислами фикер тарихы вә фәлсәфә белән шөгыльләнгән, исламияткә мәхәббәт уяту гына түгел, аны тирәнтен аңлап башкаларга да өйрәтү юлларын салган, динебезнең үткәнен тирәнтен өйрәнеп, аның киләчәктәге язмышын уңай якка үзгәртүне кайгырткан. Аның әсәрләре халыкка рухи-интеллектуаль яңарыш юлларын, борынгылыкка тарткан тәкълиднең үтергеч богауларыннан котылу юлларын күрсәткән. Үзенең хезмәтләрендә галим хак иман вә тугры гамәл, фикер иреге, калеб сафлыгы, ихсан вә ихлас кебек төшенчәләрнең асылын ачып күрсәткән, әхлакъ вә тәрбия мәсьәләләрен хәл итү ысулларын, ислам дөньясын торгынлыктан, бөлгенлектән коткару турында сүз йөрткән.

Гомумән алганда, Муса әфәнденең гыйльми иҗатының яссылыклары бихисап һәм дини тематика аның мирасы аша иң мөһим үзәк тема булып уза. Әлбәттә, беренче чиратта галимнең мирасы турында сөйлисе килә, әмма, табигый ки, аның туган яклары, нинди гаиләдә туып, нинди тәрбия алган булуы, тормыш юлының башка мөһим вакыйгалары турында да әйтмичә узу – дөрес булмаячак. Бу йөздән, аз гына булса да, биографиягә дә урын бирәм – галимнең мирасы турында мәгълүмат толымнарын аның тормыш юлында күргәннәре белән үреп барачакмын.

Ярулла углы Муса Бигиевнең туган елы 1875 ел дип санала, әмма 1923-нче елда алынган допрос протоколларының берсендә ул туган елын 1871-нче дип күрсәткән. Аның туган яклары әүвәлге Алтын Урда җирләре, аннан соңрак дәвердә барлыкка килгән Казан ханлыгы биләмәләренә карый. Муса әфәнде туган заманда бу җирләр Пенза губернасының Чембар өязенә кергән Алты-авыл исемле татар авыллары төркеменең берсе булган. Мусаның әтисе Ярулла агай Дәүлекам угыллары нәселеннән була. Ул сәүдәгәрлек итеп көн күргән, гомере азагында мулла вазифаларын башкарган. Аллаһ хозурына 1881-нче елда кичкән. Мусаның әнисе Хәбибулла кызы Фатыйма ханымның бабасы Биктимир ага Биги угыллары нәселеннән булганга күрә, Муса әфәнденең Бигиев дигән фамилиясе аны әнисе ягыннан бабалары белән бәйли. Фатыйма ханым максатына ирешеп, ягъни угылы Мусаның дин галиме булып җитешүен күреп, бу дөньядан бакыйлыкка 1908-нче елда күчә.

Гомеренең зур бер өлешен Муса әфәнде Санкт-Петербург, Петроград һәм Ленинград исемнәре белән аталган пайтәхет калада үткәргән. Бу шәһәрдә ул гаилә корып җибәргән, 1905-нче елдан башлап Советлар илен ташлап киткәнче, ягъни 1930-нчы елга кадәр яши. 1905-нче елдан башлап Муса әфәнде дини, әдәби, фәлсәфи иҗат белән мәшгуль булган, Петроград Җәмигъ мәчетендә имамлык та иткән. Монан тыш Русия һәм бөтендөнья мөселманнарының хәләтен, рухи вазгыятьләрен яхшырту өчен фидакяр иҗтимагый эшчәнлек кыйлган.

Муса әфәнденең гаиләсенә килгәндә, Чистай имамының кызы булган хәләл җефете Әсма ханым белән Муса әфәнде алты бала үстереп аякка бастырганнар. Мал-мөлкәтенә килгәндә, Муса әфәнденең үз сүзләренә күрә, аның исәпкә алынырлык мал-мөлкәте, сәүдә-фәләне булмаган. Инде искә алынган протоколларда үзе язган китапларны сату исәбенә көн күрүен белдергән.

Менә шундый тыйнак табигатьле, мал, байлык, кыйнтар-кыйнтар көмеш-алтыннар тупламаган Муса әфәндебез бөтендөнья ислам дини фикеренә һәм фәлсәфәсенә бик зур тәэсир ясаган санаулы галимнәрнең берсе, тиңдәшсез фикер иясе булып тора. Русия мөселманнары гына түгел, дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче мөселман кардәшләре дә мөхтәрәм галимне шатланып каршы ала торган, олылап кунак итеп, аны озата барган минутларында, аерылышу яшьләре түгеп, елап кала торган булганнар. Ислам галәменең абруйлы галимнәре Муса әфәнде белән фикер алышуны, гыйльми сөхбәт кылуны, фикер алышу вә гыйлем алуны үзләре өчен мәртәбә вә зур дәрәҗә итеп санаган. Ил башлары, хан вә падишаһлар бу галим алдында мәгърур башларын иеп, аны олылый торган булганнар. Галимнең никадәр абруйлы булуына ишарә итә торган берничә мисал китереп узыйм: 1930-нчы елда Муса әфәнде Советлар Берлегеннән качып китәргә мәҗбүр була. Юлы Әфганстан аша узганда аны бу илнең падишаһы Мөхәммәт Надиршаһ кунак итә, шөһрәтле галимне Кабулда калырга, дәүләт исәбенә хосусан аның өчен мәдрәсә ачып җибәрүне вәгъдә итеп, шунда җитәкчелек итәргә һәм укытырга тәкъдим иткән була. 1939-нчы елда Муса әфәнде Һиндстанда Бөек Британия колониаль идарәсе тарафыннан кулга алына. Колониаль идарә зинданыннан аны Бһопал вилаятенең губернаторы Мөхәммәт Хамидулла-хан йолып ала һәм Икенче Бөтендөнья сугышы беткәнче ирекле хәрәкәт итү хокукыннан мәхрүм ителгән Муса әфәндене үзенең сараенда мәртәбәле кунак итеп тора. Муса әфәнденең Каһирәдә үткән соңгы көннәрендә аны багып торучыларның берсе булып, соңыннан Мисыр солтаннары каберлегендә урын хәстәрләп, мәрхүмне шунда дәфен кыйлдыручы Мисыр хөкемдарлары нәселеннән булган ханбикә (принцесса) Фәхренниса Хәдичә Хилми Габбас ханым була.

Муса әфәнде үзе исән чакта ук аның ислам диненең мәгънәсенә, эчтәлегенә, киләчәгенә карата булган карашлары күпләргә юл күрсәткән, әмма, асылда, мөселманнарның борынгылыкка ябышып яткан күпчелеге аны аңлый алмаган (биредә, әлбәттә, Муса әфәнденең әсәрләре белән таныш булган кешеләр күздә тотыла). Бу йөздән, Муса әфәнде үзенең заманы өчен иртә туган кеше булган, дип әйтергә дә мөмкин. Менә алга таба ул язган әсәрләрнең, аның әйтеп калдырган фикерләренең йогынтысы көннән-көн көчәя генә барачак. Муса әфәнденең фикер

мирасының мөселманнарның динне аңлауларын, тормышларын, дөньяга карашларын уңай якка үзгәртә алачак кайбер җәүһәрләрен генә атап узам: илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы белем, җәһәннәм җәзасының мәңгелек булмавы турындагы тәгълимат, озын көннәрдә ураза мәсьәләсе, усул-е фикһы гыйлемен яңарту, исламда хатын-кызның урыны һәм әһәмияте, мөселманнарның фикерләүләрен мөстәкыйль һәм бәйсез итү мәсьәләләре, азык-төлектә хәләл вә хәрам мәсьәләләре, исерткеч эчемлекләрнең хәрәмлеген раслау, аяусыз тәкълид кыйлуның яман нәтиҗәләре, шигый мәзһәбенең карашларын тәүхид күзлегеннән тәнкыйть, Коръән аятьләрен дөрес аңлау һәм куллану үрнәкләре, мөселман дөньясының Көнбатыш колына әйләнүенең сәбәпләре, ирекле иҗтиһадның әһәмияте һәм кирәклеге, ислам мәгарифен үзгәртеп кору мәсьәләләре, бөтендөнья мөселман берлеген булдыру, ислам диненең матур киләчәге, Ахырзаман, имам Мәһди, Гайсәнең иңүе һәм бик күп башка актуаль, әһәмиятле дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр.

Әлбәттә, боларның һәммәсе турында аерым-аерым мәкаләләр язып чыгарга була һәм, бәлки, иншаллаһ, язылыр да. Ә хәзер игътибар үзәгенә яңадан галимнең тормыш юлын алыйк та, укучыларыбызны шул турында кулыбыздан килгән кадәр мәгълүматлы итик.

Мусаның әтисе иртә үлеп киткәнгә күрә, баланы тәрбияләү аның әнисе Фатыйма-ханымның җилкәсенә ята. Унбер яшендә Фатыйма-ханым әле балалыктан чыгып өлгермәгән Мусаны Ростов-на-Донудагы реаль лицейга укырга кертә һәм шул ук вакытта аңа ислам дине турында башлангыч белем бирә. Соңрак, әнисенең үгетләвенә күнеп, Муса Казанга, киләчәктә татар әдәбиятының йолдызына әйләнәчәк абыйсы Мөхәммәт-Заһир янына, дин сабагы алырга китә.

Казанда кечкенә Муса Апанай мәчете каршындагы «Күл буе» мәдрәсәсендә сабак ала. Әмма мәдрәсәдәге фикер торгынлыгы, наданлык, биредә хөкем сөргән урта гасыр мохите дөньяви уку йортында белем алу тәҗрибәсенә ия булып өлгергән Мусаның күңелен бик тиз кайтара. Тумыштан ук бик кызыксынучан, кыю җанлы, сизгер кеше буларак, Муса биредә укытылган гыйлемнәрнең тормыштан бик ерак булуын күреп ала да, анда укуның файдасын тапмыйча, мәдрәсәне ташлап, кире Ростов-на-Дону шәһәренә кайтып китә. Биредә ул лицейда укуын дәвам итеп, бу уку йортын тәмамлап чыга.

Фатыйма-ханым лицейны тәмамлаган яшь Мусаны Бохарага барып дини белем алырга өнди. Болай булуы табигый, чөнки, беренчедән, Мусаның әнисе улын укымышлы мулла итеп күрергә тели. Ә икенчедән, дәрәҗәле мулла булып кайту өчен Бохара вә Сәмәркандның ислам дөньясында дан казанган мәшһүр мәдрәсәләре борынгыдан ук менә дигән

урын булып торалар. Муса әнисенең үгетләүләренә күнә һәм ерак якларга юл тота. Әмма Муса биредә дә чал тарих дәверләреннән бирле үзгәрми калган уку-укыту методикаларына юлыга. Ни җаны, ни рухы булмау сәбәпле, акылны саектыра торган, кешене күз нуры сүнгән томанага әйләндерә торган сабак алудан Муса бик тиз арада тәмам интегеп бетә. Әмма Бохара–Казан арасы ерак, кисәк кенә кубып, кайтып китеп булмый. Моны Муса, әлбәттә, аңлый. Шуңа күрә биредәге вакытын заяга үткәрмәс өчен чаралар күрә башлый. Беренчедән, мәдрәсәләрдә гасырлар дәвамында үзгәрешсез калган укыту программаларының җитешсезлекләрен татып караган Муса үзе өчен мөстәкыйль уку прогаммасы кирәклеген аңлап ала. Шуны гамәлгә ашыру йөзеннән, Муса, үзе телəгән фәннәрне өйрәнер өчен, җәдидчеләр буларак танылган остазларга мөрәҗәгать итеп, үтенечен белдереп, алардан белем ала башлый. Укыту бәясен кайтару өчен ул остазларына урыс теленнән алар теләгән төрле гыйльми һәм фәнни китапларны тәрҗемә итә.

Шул рәвешле, Бохарада үткәргән еллары дәвамында Муса гарәп, фарсы, госманлы, үзбәк телләрен камил дәрәҗәдә үзләштерә, Коръәнне яттан өйрәнеп, Коръән-хафиз булып җитешә. Моннан тыш ул математика, астрономия, антик һәм заманави фәлсәфә кебек фәннәр белән якыннан таныша.

XIX гасырның 80-нче еллары азагында Муса әфәнде Русиягә кайта һәм Санкт-Петербургтагы университетка укырга керергә тырышып карый, тик латин телен белмәү аның өчен бу юлны яба. Әмма Муса югалып калмый: зур хыялын тормышка ашыру өчен, ягъни ышанычлы, нык һәм төпле дөньяви белем алу өчен Истанбулга юл тота. Биредә ул данлыклы Хәрби-инженерлар көллиятенә (Mekteb-i Fünun-ı İdadiye) укырга керә. Ниһаять, яшь егетнең яхшы дөньяви белем алу турындагы хыяллары тормышка аша башлый кебек. Әмма нәкъ менә шушы вакытта Мусаның тормышы, мөгаен, иң кызыклы, серле, кискен борылыш ноктасына килеп җитә: бер яктан караганда, аның иң көчле нияте, матур хыялы, ниһаять, тормышка аша, чөнки аңа дөньяви уку йортында укыячак студент булырга насыйп була. Икенче яктан, Аллаһның язмыш-тәкъдир юллары яшь Мусаны татарның тагын бер мәшһүр Мусасы белән – Муса Акъегет-задә белән күрешү ноктасына китерә...

Муса Акъегет-задәнең Истанбулда булуы сәер түгел – бу мәшһүр кала күптәннән башлап татар халкының үз иткән олуг шәһәре булып тора. Шуңа күрә биредә бик күп милләттәшләребез ризыгын да, насыйбын да тапкан була. Танылган шагыйребез Муса Акъегет-задә (1864–1923) дә шундыйлардан берсе иде. Акъегет-задә 1888-нче елдан башлап Истанбулда яшәгән була. Акъегет-задә Госманлы империясенең дәүләт учреждениеләре өчен 1859-нчы елдан башлап хезмәткәрләр әзерли торган

Мәктәбе Мөлкиядә (Mekteb-i Mülkiye) белем алып, аны 1891-нче елда тәмамлаганнан соң, Госманлы империясенең гаскәренә хәрби кадрлар әзерли торган Хәрби көллияттә (Mekteb-i Harbiye) урыс теле һәм икътисад укытучысы булып эшли башлый.

Муса Акъегет-задә белән яшь Муса Бигиевнең Истанбулда күрешүләре вә танышулары табигый күренеш, чөнки татарлар кайда булсалар да, милли диаспора хәлләрен, килгән-киткәннәрне, ил яңалыкларын, әлбәттә, белеп торганнар. Муса әфәнденең Истанбулга юл тотачагы билгеле булгач, анда аның якташы Муса Акъегет-задәнең яшәве турында хәбәрдар ителүе дә бик ихтимал. Ике якташ танышып киткәннән соң, Муса Бигиевнең тормышы кисәк кенә үзгәрә. Акъегет-задә яшь Муса белән сөйләшкән-аралашкан арада ипләп кенә аңа дини гыйлемнәрне өйрәнүне дәвам итәргә киңәш итә. Гаҗәп, әмма «хакыйкый дини белем алу мөмкинлегеннән өметем өзелде», дип әйтер дәрәҗәгә җиткән яшь Муса бу киңәшкә күнә… Соңрак язган китапларының берсендә ул тормышының әлеге сәхифәсенә нокта куйгандай: *«Кодрәт иясенең кулы илә калебемә динне сөю орлыклары салынмыш булганга күрә, соңгы мизгелдә Акъегет-задә әфәнденең сүзенә күндем»*, – дип яза. Мөгаен Акъегет-задә аша яшь Мусага, Аллаһ Тәгалә үзе нәсыйхәт биргән. Нәкъ менә күңеле түрендә посып яткан ихлас теләгенә ияреп, дини белем юлын сайлаганга күрә, Муса Бигиев олуг дин галиме, фикер иясе булып җитешә дә инде. Әгәр ул күңеле түрендә яңгырап торган бу илаһи авазны санга сукмыйча, аны тыңламыйча, ул кушканча эшләмичә һаман да шул дөньяви белем эстәү юлыннан баруны сайлаган булса, без, бәлки, Муса Бигиев дигән кеше турында белмәс тә идек.

Шулай итеп, Муса Бигиевнең тормышы дини белем, ислам фәлсәфәсе, дини яңарыш юлларына кереп китә дә, олуг галим булып җитешәчәк Муса гомере буе сайлап алган шушы юлдан чыкмый, соңгы сулышына кадәр исламга, ислам дөньясының алгарышына, мөселманнарның дини һәм иҗтимагый тормышларын яхшыртуга аяусыз рәвештә хезмәт итә.

Тормыш агымын борып җибәргән Мусаны Истанбулның дини белем-мәгариф системасы да канәгатьләндерә алмаганга күрә, ул Госманлы дәүләтенең башка өлкәләренә юл тота. Берничә ел дәвамында кылынган бу гыйлем сәфәрендә ул Каһирәдәге мәшһүр әл-Әзһар университетында укый, анда Мисырның данлыклы мөфтие, алдынгы карашлы галим Мөхәммәт Габдеһү (1849–1905), күренекле дин эшлеклесе, дини реформатор Рәшит Рида (1865–1935) белән таныша, алардан сабак ала. Шулай ук нәкъ менә Мисырда Муса Бигиев үзенең фәнни эшен дә башлап җибәрә. Биредә ул Мисыр Милли китапханәсендә Коръән тарихын ныклап һәм тирәнтен рәвештә өйрәнә башлый һәм Изге Китапка багышлан-

ган беренче гыйльми хезмәтен яза башлый. Мисырдан соң Муса Хиҗазга китә һәм ике ел буе Мәккә белән Мәдинә галимнәре белән аралашып, белемен арттыра. Аннары Һиндстанга китә, анда данлыклы ислам университетларында, шулар исәбеннән Диюбәнд шәһәренең ислам университетында да белем ала башлый. Әмма, киң ачылып киткән мөмкинлекләрдән файдаланып, ислам динен генә түгел, борынгы санскрит телен һәм жирле диннәр белән якыннан таныша. Һиндстаннан ул янә Мисырга юнәлә, анда тагын өч ел буе белем туплый, аннары Лүбнән белән Сүрия мәдрәсәләрендәге хәлләр белән таныша.

Муса Җаруллаһ Истанбулда булып алган хәлиткеч очрашудан соң күп илләрне гизеп чыккан, күпне күреп, зур тәҗрибә һәм белем туплагач, 1904-нче елда, ниһаять, туган иленә кайтып төшә. Үзенең гыйлем эстәүгә, ислам дөньясы белән, мөселманнар тормышы белән якыннан танышуга багышланган берничә еллык сәфәренә йомгак ясап, ул болай дип яза: *«Зур өметләр баглап, мин унбиш ел дәвамында дини гыйлем эзләп ислам дөньясын гиздем. Бохара, Сәмәрканд, Төркия, Мисыр, Хиҗаз, Һиндстан, Шам-Сүрияләрне айкап бөтен дини мәдрәсәләрне күрдем. Аяныч, әмма туган илемә кайтканда минем ислами гыйлемгә баглы хыялларым сүнгән иде»*.

Ерак илләрне гизеп ватанына әйләнеп кайткач ук Муса әфәндегә Ростов-на-Дону каласында имам булырга тәкъдим итәләр, тик ул имамлык вазифаларын башкаруга ризалыгын бирми. Яшь галим үзенең ниятләрен тормышка ашырыр өчен Петербургка китеп, башкаладагы университетның юридик факультетына ирекле тыңлаучы буларак укырга керә һәм, мавыгып, белем дөньясына чума.

Әмма шул вакытта Русия тетрәндергеч инкыйлаблар дәверенә килеп керә. 1905-нче елда башланган Беренче урыс революциясе Мусаның тормышына тәсир итми калмый, аңа бөтенләй яңа юнәлеш бирә. Университетта уку белән бергә Муса әфәнде Русия мөселманнарының сәяси хәрәкәтендә бик эшлекле рәвештә җиң сызганып катнаша башлый. Бу елларда ул танылган прогрессив дин иясе, казый, дәгъватчы, матбугатчы Габдрәшит Ибраһим (1857–1944) хәзрәт белән берлектә «Өлфәт» гәзитен чыгара, аның сәхифәләрендә ислам дине, әдәп, әхлак, тәрбия турындагы мәкаләләрен бастыра. Шул ук елда Петербургта аның Мисырда яшәгән дәверендә үк яза башлаган «Тарих аль-Корьән вә-л-Мәсахиф» («Коръән һәм аның тупламнары тарихы») исемле гарәп телендә язылган беренче китабы дөнья күрә. Бу язма чит ил мөселманнарының да игътибарын җәлеп итә: әлеге әсәрне Мусаның Мисырдагы остазы Рәшит Рида әфәнде үзенең «әл-Мәнар» исемле журналында бастыра. Моннан тыш Муса әфәнде Русия мөселманнарының сәяси хәрәкәтләренең югары ноктасын тәшкил иткән корылтайлар эшендә катнаша һәм, бу олуг иҗтимагый

җыеннарның рәсми кәгазь һәм документларын туплап, берничә җыентык бастырып чыгара. Биредә кызыклы бер хәл турында әйтмичә узып китеп булмый: Русия мөселманнарының Беренче корылтаен үткәрүнең кирәклеге турындагы фикер беренче мәртәбә Муса Җаруллаһның Чистай имамы Закир ишанның кызы Әсма туташка өйләнеп туй иткән вакытында туа. Сабантуе кадәр халыкны, татар зыялыларының йөзек кашларына тиңнәренең бергә җыелуларына сәбәпче булган бу олы туй 1905-нче елның май аенда Чистайда үткәрелә. Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – юк, әмма яшь парны котларга дип бирегә татар милләтенең абруйлы, өметле, алдынгы фикерле затлары, зыялылары – барлыгы 500-гә якын кунак җыелган була. Илнең төрле почмакларыннан җыелган туй кунаклары үзара аралашып фикер алышканда мөселман корылтае үткәрүнең кирәклеге һәм Русия мөселманнарының иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләрен яңа баскычка күтәрү идеясе барлыкка килә дә инде.

1908-нче елда Муса Җаруллаһ Казанга килеп, күпмедер вакыт биредә яшәп ала. Җәдиди юнәлештә эшләп килгән «әл-Ислах» гәзитенең редакциясе урнашкан бинаның икенче катында фатир яллап, Муса әфәнде җирле мөселманнарның дини, сөяси, мәдәни тормышларына чума, матбугатчы Әхмәт Исхакый белән танышып, кыска гына вакыт эчендә байтак кына китапларын бастырып чыгара. Муса Бигиевнең 1908–1909-нчы елларда Казанда чыккан китаплары аның гыйльми иҗатының мөһим һәм үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итә. Ул китаплар арасында урта гасыр мөселман дөньясының мәшһүр фикер иясе әл-Мәгаринең «әл-Лүзүмият» исемле фәлсәфи поэмасы һәм фарсы шагыйре, суфичылык тарафдары Хафиз хәзрәт Ширазиның «Диван-е Хафиз» дип аталган шигырьләр җыентыгы да була. Бу ике олпат әдипнең фикер азатлыгы һәм рухи бәйсезлек идеяләре белән сугарылган мирасы белән танышу нәтиҗәсендә укучылар үзләрен борчыган байтак кына мөһим сорауларга җаваплар табалар.

1909-нчы елның башында әле һаман да Казанда иҗат итеп яткан Муса әфәнде үзенең Русиядә чыккан Коръән басмаларында, мәшһүр «Казан басмасы»нда да күп санлы хәреф хаталары табуы турында игълан ясый. Башта яшь галимнең дәгъвасы Казан мөселманнарының ачуын чыгыра, төрле имеш-мимешләр йөри башлый, хәтта милли шагыйребез Тукай да, Мусадан көлеп, шигырь язып өлгерә. Тавыш-гауга чыгырдан чыга башлаганны күреп алган Казан бае Юнысов, әлеге киеренке мәсьәләне хәл иттерү өчен, Муса әфәндегә һәм аңа каршы чыгучы танылган дин әһелләренә үзенең өендә җыелышырга һәм махсус гыйльми җыен үткәрергә тәкъдим итә. Җыен дәвамында Муса әфәнде галим-голәмәгә Казан басмасындагы язылыш хаталарын берәм-берәм күрсәткәннән соң, динчеләр башта аптырап калалар, аннары, мәсьәләнең җитдилеген

аңлап алалар да, аны хәл итү өчен махсус комиссия оештырып, ачыкланган бу хәлне тирәнтен өйрәнү һәм хаталарны төзәтү эшенә тотыналар. Комиссия Коръәндәге басма хаталарын шулай ук Истанбулда, Каһирәдә, Һиндстанда чыккан Коръән басмаларында да табып, чит илләрдәге дин галимнәренең игътибарын бу җитди мәсьәләгә җәлеп итәр өчен рәсми мөрәҗәгать юллый.

Шулай итеп, Муса Җаруллаһ татар дөньясына үзен тирән белемле Коръән белгече буларак таныта һәм шулвакыттан башлап аның исеме татар дини һәм иҗтимагый фикер мәйданында үзенә лаеклы мәртәбәле урын яулап ала.

Муса Җаруллаһның тормыш юлы белән таныштыруны аның дини-фәлсәфи карашлары белән үреп бару дөрес булыр иде дә, мәкалә кысаларына барысын да сыйдырып булмас. Монысын алдагы киләчәккә калдырыйк. Шулай да, Муса әфәнденең Ислам тәгълиматын элеккегә караганда тирәнрәк аңлауга зур өлеш керткән фикер иясе булуын ассызыклап әйтү кирәк. Бу йөздән, биредә аның иң мөһим әсәрләреннән бере булган «Рәхмәт илаһия борһаннары» исемле рисаләсе, һәм анда күтәрелгән мәсьәләләр белән кыскача гына булса да таныштырасым килә. Минем фикеремчә, галимнең ошбу әсәрендә, аның тарафыннан Ислам дине фәлсәфәсенә кертелгән үтә дә әһәмиятле, бүгенгә кадәр үзенең актуальлеген югалтмаган төшенчәләр бәян ителә.

«Рәхмәт илаһия борһаннары» дигән гыйбарәне хәзерге татар теленә «Аллаһ мәрхәмәтнең дәлилләре» дип тәрҗемә итү мәслихәт. 1911-нче елда басылып чыккан бу китапта Аллаһ мәрхәмәтенең үзенчәлекләре, аның асыл сыйфатлары, ул мәрхәмәтнең адәм балаларына кагылышы турында, тәмуг газапларының кайчан да булса бетәчәге һәм диненә-фәләненә карамастан, барлык адәм балаларының Аллаһ тарафыннан кичерелеп, җәннәткә кертеләчәкләре турында сүз бара.

Мондый карашларга Муса әфәндене тормыш тәҗрибәсе дә, тынгысыз акылы да, җанының ризасызлыгы да, ислам дөньясы буйлап озакка сузылган гыйльми сәфәре дәвамында туплаган белеме дә этәргән. Гомумән алганда, Муса әфәнде гомере буе Мөхәммәт пәйгамбәрнең: *«Гыйлем эстәп Чинга булса да барып җитегез»*,–дигән васыятен үтәп яшәгән. Үзенең сәфәрләрендә ул кешеләрнең нинди генә дин ияләре булуына, нинди генә телдә дога кылуларына карамастан, араларында игелекле һәм явызлар, юмарт һәм саранннар, күркәм холыклы һәм яманнар булуына кат-кат инанган. Тормыш тәҗрибәсе, күргән-кичергәннәрдән сабак алу нәтиҗәсендә Муса Бигиевнең фикер офыклары гаять киңәя, аңарда тормыш агымына башка күз белән карый алу сәләте уяна, галим ислам тәгълиматының әлегә кадәр билгеле булмаган якларын күрә алу дәрәҗәсенә күтәрелә.

«Рәхмәт илаһия борһаннары»нда Муса әфәнде болай дип язган: *«Мөселманнарның инануынча, Аллаһ адәм баласын җирдә хәлифә кыйлуы белән иң югары дәрәҗәгә күтәргән. Тик кешеләр бетмәс-төкәнмәс бәла-казалар, кайгы-хәсрәтләр кичереп яшиләр. Аерым алынган бер кешенең гомере чиксез мәңгелек белән чагыштырганда, сизелмәслек бер мизгел генә булып тора, аның шул мизгел дәвамында күргән михнәтләре рәхәттән күпкә артык, өстәвенә, шул михнәтләрдән соң аны әле мәңгелек җәһәннәм көтеп тора. Бу кадәр мескен, бу кадәр кадерсез мәхлукларны барлыкка китергәндә Аллаһ нинди максатны күздә тоткан икән? Әшләр болай булганда үзен Мәрхәмәтле, Рәхимле дип атаган галәмнәр Раббысының чиксез мәрхәмәте һәм мәгъфирәте кайда? Ул нидән гыйбарәт?»*

Бу сорауларга җавап эзләп Муса Бигиев кәламчеләр буларак танылган фикер ияләренең әсәрләренә дә, суфилар язгын китапларга да мөрәҗәгать итә, кат-кат Коръәнне укып чыга. Ниһаять, яшь галим рухи могҗиза кичерә: хикмәтле аятьләрнең нуры аның тормыш тәҗрибәсенең тирәнтен мәгънәви асылы белән кушыла да, Муса әфәнде мөселманнарның күптәннән инде Аллаһның Коръәндә әйткән сүзләрен түгел, ә бары тик дин әһелләренең аңлатмаларын ишетүләрен, шулар буенча гамәл кылуларын аңлап ала да, исе китеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килә: «әл-Гаср» сүрәсендә Аллаһ: ***«Хакыйкатьтә иман итеп игелек кылучылардан булмаган кеше – олуг хәсрәттәдер…»****– дигән. Гаҗәп, әмма биредә кулланылган «кеше» сүзе мөселманны яки христианны белдерми! «Ниса» сүрәсендә:* ***«Аллаһ иман ияләре өчен беркайчан да кяферләрне үрнәк итмәс»****, – диелә. Биредә «кяферләр» – инглизләрне, ә «иман ияләре» – Һиндстан һәм Мисыр мөселманнарын белдерәмени? Хак Тәгалә Коръәндә:* ***«Мөэминнәрнең җиңүгә ирешүләре чынлыкка ашты»****, – диелә. Биредә «мөэминнәр», дигәндә, Аллаһ берничә инглиз гаиләсенең колларына әйләнгән Һиндстан мөселманнарын күздә тотамы? Бәлки ул Һолландиянең кулында хезмәтче булып калган Ява мөселманнарын күздә тотадыр?»* – дип яза ул.

Нәтиҗәдә, Муса әфәнде Аллаһ мәрхәмәтенең чынлыкта нинди булуын өр-яңа бер ноктаи нәзардән күрә башлый. 1909-нчы елда Оренбургтагы – Хөсәения мәдрәсәсендә дин тарихын укыткан чагында Муса әфәнде үзенең ачышлары белән шәкертләрен таныштыра. Мөгаллимнең бу фикерләре башта шәкертләргә, аннары бөтен мөселман җәмәгатьчелегенә аяз көнне суккан яшендәй тәэсир итә. Русия мөселманнары шаккаталар, уйлап карасаң, аңлашыла да: мөселманнарның Аллаһ каршында аерым бер дәрәҗәгә ия булулары турындагы ышаныч тарихта беренче мәртәбә кискен һәм үтемле рәвештә тәнкыйть утына тотыла. Татарларның алдынгы фикерле зыялылары Муса Бигиевнең бу фикерләрен яклап чыксалар да, иҗтимагый фикер мәйданында аның белән риза булмаганнары, һәм

һич тә риза була алмаганнары күбрәк була. Дини фанатиклар гына түгел, хәтта зыялы милләтпәрвәрләр дә Бигиевнең башына каргышлар ата башлыйлар. Муса өчен катлаулы булган киеренке бу вакытта, көтелмәгәндә, аны яклап мәшһүр дин галиме, тарихчы һәм «Шура» журналының мөхәррире Риза-казый Фәхреддин хәзрәтләре чыга. Риза хәзрәт Бигиевнең илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы фикерләрен «Шура» журналы сәхифәләрендә мәкаләләр буларак бастыра башлый.

Муса әфәнденең «Шура» сәхифәләрендә басылып чыккан фикерләре урыс шәркыятьче галимнәренең дә кызыксынуын җәлеп итә: ул заманда Петербургта чыгып килгән «Мир ислама» исемле журнал болай дип язган: *«Русия мөселман матбугатының алдынгы-милләтчел вәкилләре Бигиевнең һәр яңа китабын алкышлап кабул итә. Муса Бигиевнең әсәрләре кисәк кенә игътибар үзәгендә урын алдылар. Татар фәлсәфәчесенең фикерләре Төркия мөселманнары арасында киң тарала башладылар. Аның иске карашларны кыю рәвештә тәнкыйтьләве бик күпләргә ошый башлады»*.

Муса әфәнде кузгатып җибәргән матбугат туфанына Госманлы дәүләте Галиясенең матбугаты да кушылып китә. Мәсәлән, Истанбулда чыгып килгән «Түрк Йурду» исемле журнал[1] болай дип язган: *«Ниһаять, Русиядә үзенең китаплары илә дан казанган зур галим пәйда булды. Ул – галим Муса Җаруллаһ. Аның исламны чынлап яңартучы булуында бер генә дә шик юк»*.

Муса әфәнденең әсәрләре Госманлы дәүләте Галиясе мөселманнарының башлыгы шәйхелислам Мостафа Сабри Тукади хәзрәтләренең (1869–1954) дә игътибарын җәлеп итә: тәкълид тарафдары буларак шәйхелислам Муса әфәнденең китапларының Госманлы Дәүләте Галиясендә сатылуын ясак кыйлып фәрман чыгара. Бу фәрман Госманлы иленең алдынгы фикерле зыялыларының шау-шулы ризасызлыгын уятканга күрә, Мостафа Сабри хәзрәтләре бераздан ул әмерен кире ала. Соңрак Мостафа әфәнде Сабри Муса Бигиевнең дингә кагылышлы фикерләре белән, аеруча илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы тәгълиматы белән ризалаша алмавына карамастан, татар галименең ислам дөньясында дин хакында бәхәстәш була алырлык бердәнбер галим булуын ачыктан-ачык таный.

---

[1] *«Түрк Йурду»* – 1911-нче елның 30 ноябреннән 1918-нче елның 15 июленә кадәр Истанбулда айга ике мәртәбә чыгып килгән 32 сәхифәле гомумтөрки миллиятчел рухлы журнал. Журнал нәшер ителгән җиде ел дәвамында аның 161 санын үз эченә алган 14 җилде (тупламы) дөнья күрә. 1-нче, 2-нче җилдләр һәм янә 5-нче җилдтән дәвам итеп, 12-нче җилдкә кадәр журналны җаваплы сәркатип вазифаларын башкарган Йосыф әфәнде Акчура (1876–1935) чыгара. 1918 елда чыгышы тукталган журнал кабат 1923–1931-нче елларда, 1943-нче, 1954–1957-нче елларда, 1959–1968, 1970, 1987–2001-нче елларда нәшер ителеп тора. 1989 елдан бүгенгәчә Анкарада нәшер ителә.

Язмыш диген: әлеге ике олуг галимнең соңгы көннәре Каһирәдә үтә һәм алар икесе дә бер зиратта күмелгәннәр. Тик Сабри әфәнденең кабере каралган, аны Төркия хөкүмәте багып тора. Муса әфәнденең кабере исә әлегә табылмады. Зират, дигәннән дә, бер авыл яки шәһәр зираты кадәр генә түгел, әлеге «Каберләр шәһәре» дип аталган каберстан үзе бер шәһәр кадәр: буйга 11 километрга сузылган, киңлеге иң тар җирдә ярты километр тәшкил итеп, иң киң урында километр ярымга кадәр җитә. Насыйп булса, анда барып, күреп йөргәннәрем турында да язармын, иншәАллаһ.

Муса әфәнде күтәргән илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турында чыгышы белән сүрияле Тауфыйк әфәнде Ибраһим, бүгенге Русиянең күренекле шәркыятьче галиме, фәлсәфә фәннәре докторы, болай ди: *«Илаһи мәрхәмәтнең гомумилеге турындагы тәгълимат–ул бик тә дөрес һәм заманча тәгълимат. Бары тик шундый тәгълимат нигезендә генә башка дин ияләре белән тату яшәп була. Дин тотучыларның башка дин тотучы күршеләре турында: «Алар һәммәсе дә җәһәннәм утында яначаклар! Алар балалары, хатыннары белән бергә мәңгелек газапка дучар ителәчәкләр!»–дип әйткән чакта алар белән дуслыкта, бергәлектә яшәп булмый. Болай уйлаганда, ничек күршеләрчә тату яшәп булсын?! Мондый күренеш, динне болай аңлау бөтен традицион диннәргә, ягъни дин тотучыларга хас нәрсә. Мөселманнар да, шигыйлар белән сөнниләр үзара бер-берсе турында шулай уйлыйлар, төрле дини агымнарга караган христианнар да бер-берсен шулай куркыталар. Муса-әфәнденең илаһи мәрхәмәт тәгълиматын аңлатуына күрә, Аллаһның безне яратуы бер ананың баласын яратуыннан чагыштыргысыз дәрәҗәдә артык. Аллаһның безгә карата ачулануы никадәр генә булмасын, ул безне никадәр генә кире какмасын, ахырда, ул үзенең баласын кабул иткән анадай безне дә кичереп кабул итәчәк. Әлбәттә, ул күпмедер вакыт безне җәзага дучар итәр, әмма азакта, барыбер, безне үз мәрхәмәте илә кочып, җәһәннәмнән коткарачак»*.

Беренче Бөтендөнья сугышы туфанында һәм аннан соңгы иҗтимагый тетрәнүләрдә Муса әфәнде дәһшәтле киләчәкнең аҗаганын алдан ук күреп-белеп, ул турыда китапларында яза. Илаһи кануннарны үтәмәүнең яңа коточкыч югалтуларга китерәчәген белеп, ул болай дип фаразлый: *«Әйе, бүгенге көндә Бөтендөнья сугышы тәмамланды, әмма иң куәтле илләр арасында кораллану бәйгесе башланды. Моның аркасында алдагы елларда тагын да куркынычрак сугыш башланачак. Шул сугыш башланганчы ислам дөньясы, Көнбатыш казанышларыннан файдаланып, тиз арада көч туплап, дөнья күләмендә зур куәт иясе буларак аякка басарга тиеш. Шулчакта гына сугыш түгел, иминлек җиңәчәк тә барлык кешеләр Аллаһ диненең бөеклеген һәм кадерен аңлаячаклар»*.

Үктәбер инкыйлабыннан соң Муса әфәнде, башта большевикларның вәгъдәләренә ышанып, алар белән бергәләп эш итү мөмкинлекләрен эзләп карый. Бу дәвердә ул Төркестан мөселманнарының милли азатлык өчен сәяси көрәшләрендә катнаша, һәм яңа Совет хөкүмәтен җирле төрки мохтариятләр белән килештерергә теләп, хәрәкәт итә. Тик бу дәвердә Совет хөкүмәтенең, урыс большевикларының башбаштаклыкларын, мөселманнарга карата дошмани мөнәсәбәтләрен, явыз җинаятьләрен күргәннән соң, бу хыялларыннан тәмам ваз кичә, коммунистик тәгълиматтан тәмам бизә. Нәтиҗәдә, инде 1923-нче елда Берлинда дөнья күргән «Ислам милләтләренә» исемле китабында ул марксистик тәгълиматның нигезе черек булуын бәян итә. Әмма «Ислам милләтләренә дини, әдәби, сәяси мәсьәләләр, тәдбирләр хакында», дип аталган бу китапта марксизмны тәнкыйтьләү сүз уңаеннан гына әйтелә. Асылда, автор тарафыннан «Исламият әлифбасы» дип тә аталган бу китапта Муса әфәнде шул заман мөселман тормышының, ислам дөньясының никадәр булса шулкадәр проблемаларын, кыенлыкларын, фаҗига һәм бәлаләрдән котылу чараларын бәян итә һәм ислам дөньясын артка тартучы берничә гасыр дәвам иткән кризистан чыгу юлларын күрсәтә, дини, рухи, мәдәни, икътисади тәрәккыят үрләрен яуларга чакыра. Бу китабында да, аннан алдагы әсәрләрендә дә Муса әфәнде, шәригатьтә каралган дини йолаларны үтәү белән генә чикләнмичә, кешеләрдә фикер вә ихтыяр иреген уятырга чакыра һәм шул нигездә иҗтиһад һәм ирекле иҗат юлына чыгарга дәгъват итә. Шулай итеп, галим ислам динен җанландырып җибәреп, аны югарырак баскычларга күтәрергә, мөселманнарны алдынгы, фән вә техник прогресстан файдаланучы җәмгыятькә әверелдерергә чакырган. Аның фикеренчә, шундый ирекле акыл ияләре генә мөселман җәмгыятен алга таба, бөтен кешелек дөньясы атлаган юнәлештә үстерә алачаклар. Шушы чаралар ярдәмендә Муса Бигиев ислам диненең дөньякүләм абруен һәм әһәмиятен арттырырга, аны бөтен кешелек дөньясын үзенә җәлеп итә алырлык алдынгы, матур, әхлакый бер яшәү рәвешенә әверелдерергә теләгән.

«Ислам милләтләренә» исемле китабында Муса Бигиев болай дип яза: *«Кешелек дөньясының бүгенге халәтен тәнкыйть иткәндә Карл Маркс, әлбәттә, хаклы. Әмма киләчәкне юраганда ул һәр ноктада ялгышкан. Цивилизацияне күмәк фәкыйрьлеккә нигезләп кору мөмкин түгел. Җәмгыятьне тәшкил иткән кешеләрнең хокукларын һәм иреген аяк астына салып таптап, киләчәкне төзеп булмый. Мондый фикерләр сабыйларча зәгыйфь акылга гына хас була ала. Халыкның фикерләвен, калебләрен, иманнарын һәм әхлагын үзгәртмичә башланган революция тетрәнешләре фәкыйрьләргә һәм эшчеләргә файда һәм игелек китермәячәк».*

Коммунистик идеалларны тар-мар итүе, Русиядән һиҗрәт кылып Берлинда яшәгән вакытында, «Исламият әлифбасы»на мөхәррирлек кылган больше-

визм дошманы Гаяз Исхакый белән аралашуы аркасында, Муса әфәнде шул ук 1923-нче елның көзендә ОГПУ тарафыннан кулга алына. Чит ил татарларының протестлары һәм төрек дипломатиясенең тырышлыгы нәтиҗәсендә генә ул өч айга якын вакытын төрмәдә үткәргәннән соң, тоткынлыктан азат ителә һәм 1924-нче елның башында Мәскәүгә өч ел дәвам ителәчәк сөргенгә җибәрелә. Әмма 1927-нче елга кадәр дәвам ителәсе сөрген тоткыны булуга карамастан, Муса әфәнде шактый ирекле шартларда яши: 1925-нче елда ул Кырымга барып ял итәргә рөхсәт алуга ирешә, ә 1926-нчы елда Совет хөкүмәте аңа Беренче Хилафәт корылтаенда катнашырга рөхсәт бирә.

Хилафәт мәсьәләсе ислам дөньясы тарихында да, Муса әфәнденең биографиясендә дә мөһим урын алган булганга күрә, әлеге мәсьәләгә махсус тукталыйк.

1517-нче елдан башлап Госманлы солтаннар кулы астында яшәп килгән Хилафәт 1924-нче елда юкка чыгарыла. Бу фаҗигадән соң дөнья мөселманнары яңа Хилафәт канаты астында берләшеп яшәү теләген белдерә башлыйлар. Мисырда, Сүриядә, Фәләстыйнда, Фарсыстанда, Гарәпстанда, Төркиядә, Кәшгарда, Һиндстанда, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә һәм хәтта Советлар Союзында да мөселман җәмәгатьчелеге, әлеге проблема бәхәс үзәгенә куеп, яңа хәлифә сайлау һәм Хилафәтнең язмышын хәл итү турында ныклап уйланалар. Мәсәлән, Бөекбритания империясенең колониясе булган Һиндстанда җирле мөселманнарның сәяси хәрәкәтен җитәкләүче Һинд хилафәт комитеты оештырыла. Ә Муса әфәнде Бигиев инде 1923-нче елда ук Хилафәткә кагылышлы фикерләрен «Ислам милләтләренә чакыру» исемле китабында бәян иткән була.

Хилафәт мәсьәләсен чишүдә империалистик державаларның катнашуын да истә тотканда, бу мәсьәлә глобаль проблемага әверелә. Мәсәлән, Хилафәт мәсьәләсен хәл итәргә тиешле булган Бөтендөнья мөселман Корылтайларын оештыру процессында Бөекбритания, Франция һәм Советлар Союзы да актив катнашалар. Гомумән алганда, XX гасырның 20-нче елларында Совет хөкүмәте Якын Көнчыгышта һәм мөселман дөньясында үзенең сәясәтен үткәрү өчен совет мөселман дин әһелләрен актив кулланган була. 1924-нче елда Советлар Союзы, Хиҗаз мәмләкәте белән дипломатик мөнәсәбәтләр корып, Җәддәдә дипломатик миссия ачып җибәрә. Ә 1926-нчы елның 16 февралендә Советлар Берлеге хөкүмәте инде Ибне Сөгудне рәсми рәвештә Хиҗаз, Нәҗед һәм кушылган вилаятьләрнең короле итеп таный. Совет дипломатиясе вәкиле – вәкаләтле вәкиле (полномочный представитель) буларак Ибне Сөгуд белән мөнәсәбәтләр кору милләттәшебез Габдерәүф углы Кәрим Хәкимовка йөкләнә.

Кәрим Хәкимовның шәкерт чагында Муса әфәнде белән күрешкән булуы ихтимал, чөнки ул 1908–1910-нчы елларда «Хөсәения» мәдрсәсендә

укыган була. Соңрак дәвердә тормыш җилләре аны Совет иленең дипломатик даирәләренә китереп кертә. 1924-нче елдан башлап Кәрим Хәкимов Советлар Союзының Хиҗаздагы вәкаләтле вәкиле вазифаларын башкара. Ул чакта Хиҗазның мәлиге (короле) булып пәйгамбәр нәселеннән булган Хөсәен ибне Гали әл-Һашими торган. Гарәп дөньясында Советлар Союзының беренче дипломаты булган Кәрим Хәкимов тырышлыгы белән алга таба Согуд Гарәпстаны СССРның стратегик партнеры дәрәҗәсенә күтәрелә, совет товарлары өчен Гарәпстанга һәм Якын Көнчыгышка юл ачыла. Тарихчы Р. Вәлиев язуынча, нәкъ менә К. Хәкимов тырышлыгы белән Одесса–Җәддә арасында хаҗилар өчен пароход рейслары оештырыла. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Муса әфәнде үзенең 1927-нче елгы хаҗнамәсендә әлеге Одесса-Җәддә пароход юлының уңайлыкларын мактап телгә ала.

Талантлы дипломат, милләттәшебез Кәрим әфәнде Хәкимовның бәрәкәтле арадашлыгы аркасында Советлар Союзы белән дустанә мөнәсәбәтләр оештырган Ибне Сөгуд, Якын Көнчыгышта үзенең сәяси уенын алып барган Бөекбритания өчен бик үк ятышлы илбашы булмый, әлбәттә. Англиянең дөньяның бу төбәгендәге асыл максаты – үзенең сәяси-икътисади тәэсирен саклап калу һәм үстерү булып тора. Бөекбританиянең колониаль идарә әһелләре мөселманнарның берләшү омтылышларын үз мәнфәгатьләренә файдаланып, шул омтылышның сәяси җимешләрен, ягъни барлыка килә алган структураларын үзләренең ихтыярларына буйсындырырга тырышалар. Шул сәбәпле, державалар арасында Бөтендөнья мөселман корылтаен үткәрү урыны турында бәхәс куба. Бу шартларда Мисырның Англиягә буйсынган дин әһелләре Конгрессны Каһирәдә үткәрү идеясен алга сөрә башлыйлар. Әмма дөнья мөселманнары бу тәкъдимне хупламыйлар. Аерым алганда, Һиндстан һәм Советлар Союзы мөселманнары бу фикергә каршы чыгалар. Мәсәлән, 1926-нчы елда мөфти Ризаэддин Фәхреддин СССР хөкүмәтенә: «Корылтай империалистик дәүләтләрнең тәэсирендә булмаган илдә үткәрелергә тиеш», – дигән телеграмм суга. Шунда ук мөфти Корылтайны инглизләр карамагында булган Мисырда һич тә үткәрергә ярамаганны ассызыклый. Әлеге киңәшләргә таянып булса кирәк, Совет хөкүмәте Корылтайны һәр мөселман өчен изге булган һәм Кәрим Хәкимов тырышлыгы белән Мәскәүгә якынаеп өлгергән Ибне Сөгуд кулы астында булган Мәккәдә үткәрүне хуплап чыга.

Мондый вариант Англия белән Франциияне, әлбәттә, канәгатьләндерми. Әлеге ике илнең Якын Көнчыгышта тәэсире Советлар Берлегенекеннән күпкә артык булганга күрә, Бөтендөнья мөселман корылтае (аны шулай ук Каһирә хилафәт корылтае дип тә атыйлар) үзенең эшен 1926-нчы елның 14 маенда Мисырның башкаласы Каһирәдә башлый. Бу чараның максаты булып Англиягә буйсындырылган бөтендөнья

мөселман оешмасын булдыру торган. Корылтайны оештыру комитеты мөселманнарны Корылтайда катнашырга дәгъват итеп бөтен мөселман илләренә, шул исәптән Советлар Союзының Өфе Диния нәзарәтенә, һәм, аерым алганда, Муса Бигиевкә да чакырулар юллаган була. Әмма, Корылтайга әзерләнү процессын игътибар белән күзәтеп торган инглизләр, оештыру комитетының теләгенә каршы чыгып, Муса әфәндегә Мисырга килергә рөхсәт бирмиләр. Нәтиҗәдә, Каһирә Корылтаена нибары 25ләп делегат килә, һәм аларның азлыгы (кворум җыелмавы) сәбәпле, аның карарлары юридик көчкә ия булмыйча кала.

Мөселман корылтаеның Каһирәдә үткәрелүенә ризасызлык күрсәтү йөзеннән, 1926-нчы елның 7 июнендә үз эшен Мәккә мөселман Корылтае башлый. Советлар Союзыннан бу Корылтайда катнашучы рәсми делегация катнаша. Аның составында мөфти Ризаэддин Фәхреддин, аның урынбасары Кәшшафетдин Тәрҗемани һәм башкалар була. Әлеге делегациядә Мәскәү шәһәре мөселманнары вәкиле Муса Җаруллаһ Бигиев тә була. Делегатлар 1926-нчы елның 6 маенда юлга чыгып, бер айдан Хиҗазга барып җитәләр. Әмма, ниндидер сәбәп белән, Муса әфәнде ул чакта делегатлар арасында булмый.

1926-нчы елгы Мәккә Корылтае протоколларыннан күренгәнчә, Мәккәгә Муса әфәнде Төркия делегатлары белән бергә егерме көнгә соңарып килеп төшкән була. Чыннан да, Корылтайның беренче утырышы эшен башлаган көнне, ягъни 1926-нчы елның 7 июнендә, СССРдан килгән делегатлар исемлегендә аның исеме әле булмый. Шул ук протоколлардан күренгәнчә, Муса әфәнде Корылтай эшчәнлегенә июнь аеның 27сендә генә кушыла. Бу көн Корылтайның унынчы утырышы башланган көн була. Димәк, Муса әфәнде өч атнага якын вакытын Истанбулда, шул җөмләдән югарыда искә алынган «Мөскират» исемле китабын бастыру мәшәкатьләренә багышлап үткәргән булса кирәк. Бу фаразның ныклы дәлиле Г. Баттал-Таймас китабында табылды. Авторның язуынча, Аның Муса әфәнде белән икенче очрашуы 1926-нчы елның язында була: «Бу Истанбулда булды. Шул елның язында [1926. – А.Х.] хәзрәтебез Истанбулның Чагалоглыдагы Җәридханә[1] урамындагы Габдерәшит Ибраһимның кызы өендә очраштык[2]. Чәй

[1] Басмада хата киткән. Урамның исеме Җәридханә түгел, Җәридәханә (Ceridehane) булырга тиеш.

[2] Җәридәханә урамындагы Габдерәшит хәзрәт Ибраһимның кызы Фәүзия ханым Ибраһим (Fevziye Abdürreşit Dorgul, 1887–1985) яшәгән 5 номерлы йортта шулай ук ул чыгарган «Хатын-кыз язмалары» (1925-нче елның гыйнварыннан башлап «Asar-ı Nisvan» исемле, 1926-нчы елның сентябреннән «Kadın Yazıları») исеме белән журналның идарәханәсе дә урнашкан булган. Фәүзия ханым әлеге журналның хуҗасы һәм җаваплы мөдире булган. Әлеге айлык журнал 1925 елдан башлап 1926 елга кадәр чыккан булса кирәк, чөнки, матди кыенлыклар сәбәбеннән, аның

эчтек»[1]. Димәк, 1926-нчы ел Мәккә корылтаена барышлый Муса әфәнде чыннан да өч атнага якын вакытын Истанбулда үткәргән була.

Гомумән алганда, Муса Җаруллаһ Бигиев үзенең хаҗ юлъязмаларын язганда Гарәп ярымутравының сәяси вазгыятенең нинди булуын югарыда язылганнардан күзаллап була. Ул гына да түгел: хаҗнамәдән күренгәнчә, Муса әфәнде Мәккәдә булган вакытында, Ислам дөньясы корылтаеның эшчәнлегендә турыдан-туры катнашуын дәвам итә, аңа булдырган кадәр өлешен кертә һәм аның карарларын кабул иткәндә үз сүзен, фикерен әйтеп XX гасыр ислам дөньясының сәяси тарихын язучыларның берсе була.

Совет хөкүмәте үзенә теләктәшлек эзләп мөселман илләре белән сәяси уен уйнаган елларда кулга алынып азат ителгән Муса әфәнде, үзенең абруена таянып, СССРда тагын берничә ел яши алган. Әмма большевиклар исламга карата чын йөзләрен күрсәткәч, Муса әфәнде 1930-нчы елның кара көзендә туган иленнән качып китәргә мәҗбүр була.

Горбәтлектә Муса әфәнде беркайда да тамырлана алмыйча гомер кичерә. Башта ул Шәркый Төркестанда, уйгырлар яшәгән җирләрдә мәдрәсә ачарга тели, әмма бу илне басып алган Кытай хөкүмәте аны илдән китәргә мәҗбүр итә, чөнки ул Муса Бигиевне җирле уйгыр халкын дини идеяләргә таянулы милли-азатлык көрәшенә күтәрә алуыннан курка. Муса әфәндене Кытайдан махсус конвой белән Әфганстанга таба озаталар. Муса Бигиевнең үзе язуынча, «балта тимәгән урманнар аша дүрт ай дәвамында» Памир таулары аша Әфганстанга юл тота.

1931-нче елның язында Әфганстан солтаны Надиршаһ остазы Муса Бигиевне бик олылап каршы ала, Кабул шәһәрендә мәдрәсә ачып төпләнергә тәкъдим итә, тик Муса әфәнденең ниятләре башка була. Мәртәбәле кунагының үтенечен үтәп, Надиршаһ аңа чит ил паспорты ясатып тапшыра. Моннан соң Муса әфәнде өчен юллар да ачыла – ул Әфганстан гражданины буларак олы сәфәргә чыга. Кабулдан Муса әфәнде башта Һиндстанга китә, аннан соң Төркиядә, Финляндиядә яшәп ала. Шул ук 1931 елда Анкарада Муса әфәнде белән Русиядән Октябрь инкыйлабына кадәр күчеп киткән Йосыф Акчура күрешә. Бигиевнең күптәнге дусты булган Йосыф әфәнде ул чакта Төркия президенты Мостафа Кемал Ататөрекнең киңәшчесе вазифаларын башкарган була. Муса әфәнде Акчура ярдәме белән Ататөрек белән күрешеп сөйләшү ниятен тормышка ашырырга тырыша, әмма бу эш барып чыкмый, чөнки ислам динен җәмгыять һәм дәүләт тормышыннан мөмкин кадәр аерырга тырышкан

---

берләштерелгән 27–28-нче саны (1926 елның 7–8-нче саны) соңгысы була (кара: Türkoğlu İ. İdil-Ural Tatarlarının İstanbul’daki Neşriyat Faalıyetleri // Milliyetlerin Kesişme Noktası: İdil-Ural Çalıştayı Bildiri Kitabı. 12–13 Nisan, 2014 / Kırklareli. S. 43–50).

[1] Баттал-Таймас Г. Муса Ярулла Биги. Казан: Издательство «Иман», 1997. Б. 37.

Төркия хөкүмәте ул диннең олылыгын һәм бөеклеген раслаучы идеолог белән көрәшүне кирәксез дип таба.

1932–1933-нче елларда Муса әфәнде Берлин белән Финляндия арасында хәрәкәт итеп яши. Алман башкаласында ул нәшрият оештыра һәм байтак кына китапларын бастырып чыгара, ә чыгымнарны аңа Финляндия татарлары капларга ярдәм итәләр. Бу йөздән Муса әфәнде фин татарларының кунагы да була. Алга таба ул Иран белән Гыйракка юл тота. Бу елларда ул биредә киң таралыш тапкан шигыйлек мәзһәбен өйрәнә һәм аңа багышлап махсус китап яза.

Ерак Япон илендә мөселман мәркәзен оештырган Габдерәшит Ибраһимов 1938-нче елда Муса әфәндене Японияне зиярәт итәргә дәгъват итә. Токиода беренче мәчет ачу тантанасында катнашканнан соң, ике фикердәш бер ел дәвамында бергәләп Япония мөселманнарын ислам дине белән таныштыралар.

Муса әфәнденең горбәтлектәге хәяте, күргән вә кичергәннәре аерым зур китап булып язылырлык. Бу эшне киләчәккә калдырып, аның мирасында зур урын алып торган тагын бер мәсьәләгә күз салыйк.

Муса Бигиев күтәргән иң мөһим мәсьәләләрнең берсе исламияттә хатын-кыз проблемасы була. Бу темага багышлап ул 1933-нче елда Берлинда «Коръән- Кәрим аять кәримәләре нурлары хозурында хатын» исемле бер китабын нәшер итә. Бу әсәрен ул сөекле хатыны Әсма ханымга багышлаган һәм үзен Ибн Фатыйма, ягъни Фатыйма углы, дип атаган.

Инде искә алынган Тәүфыйк әфәнде Ибраһимның фикеренчә, исламияттә хатын-кыз мәсьәләсе Муса әфәнде мирасының иң матур, иң күркәм сәхифәсен тәшкил итә. Тәүфыйк әфәнде болай ди: *«Муса Бигиев мөслимәләрне ир-ат дин галимнәре тарафыннан динебезнең ялгыш аңлатылган хөкемнәреннән шулкадәр тырышып яклаган! Бу хакта Муса әфәнде нәрсә ди? Безнең диндә, яһүд, христиан диннәреннән аермалы буларак, хатын-кыз шайтан тозагы буларак сурәтләнми. Коръәндә мондый карашларның эзе дә юк. Безнең диндә җәннәтне ялгышып югалтучы Хәва түгел, Адәмдер, ә Хәва хәзрәтләре җәннәтне үзенең иренә тугры калуы аркасында югалта. Адәм Хәвага ияргәнгә түгел, нәкъ киресе – Хәва ирен ялгызлыкта калдырмый. Коръәндә беренче кешеләрнең җәннәттән мәхрүм ителүләренең гаебе тулаем Адәм җилкәсенә ята!»*

Муса әфәнде ислам тарихында беренче булып ир-атның хатын-кызга карата булган мөнәсәбәтен тәнкыйть утына тота. Аның фикеренчә, ир-атның күзен һәм калебен күркәм әхлак һәм ихтирам хиҗабы капламыйча, хатын-кызны тукыма астына яшерүнең һәм аның дүрт дивар тоткыны булуының мәгънәсе юк. Ул болай дип язган: *«Исламият хатын-кызның мәчетләрдә, уку йортларында, мәҗлесләрдә ачык йөз илә йөрүенә каршы*

*тормый. Әмма исламият ханым вә туташларның әдәпсезлек, азгынлык кылуларын кискен рәвештә тыя. Бу максатка ул хатын-кызның иреген чикләү юлы белән түгел, бәрәкәтле үгет-нәсыйхәт юлы белән ирешә. Хатын-кыз белән ир-ат арасында чын мәхәббәт булмыйча, бер-берсенә карата мәрхәмәтле вә тигез мөнәсәбәт булмыйча ни гаилә, ни куәтле дәүләт, ни сәламәт милләт булмаячагын аңлар вакыт җитте инде»*.

Муса әфәнде гаиләне чын мәгънәдә кешечә яшәүнең иң кыйммәтле башлангычы, иң кадерле казанышы итеп таныган. Ул болай дигән: *«Хәлакәтнең максаты–гаиләви тормыштыр. Гаилә–җәннәткә таба беренче адым. Адәмне җирдә хәлифә итеп торгызганда Аллаһ Тәгалә гаилә иминлеге дигән бер генә максатны күздә тоткан. Адәм тулы бербөтеннең яртысы гына. Бары тик хәләл җефете илә бергәлектә ул камил бербөтенгә әйләнә ала. Хатының булмаганда ни гаилә юк, ни Аллаһның әмерен үтәү юк, ни җәннәт юк»*.

Горбәтлектә Муса әфәнде гаиләсе белән аерылышуны бик авыр кичереп интегүдән туктамый. Бу еллар дәвамында ул газиз хатыны илә балаларын коткармакчы булса да, бу эш барып чыкмый. Ул болай дип яза: *«Читтә, ят илләрдә япа-ялгызым сабыр кылып, гомер елларымны үткәрәм. Агыладыр айлар. Күр имди: һич тә чыдар хәлләрем калмады!»*

Муса әфәнде тормышының соңгы айларын Каһирәдә үткәрә. Бу шәһәргә ул әле яшь чагында башлаган бер эшне тормышка ашыру нияте белән Төркиядән килеп төшә. Сүз 1912-нче елда кара эчле муллаларның мөфтигә язган шикаятьләре аркасында Казанда басылмый калган Коръән тәрҗемәсе турында бара. Әлеге хезмәтнең кульязмасын Муса әфәнде гомере буе үзе янында йөртә. Ниһаять, 1948-нче елда аны Истанбулда бастырып чыгару мөмкинлеге барлыкка килә. Әмма ул чакта, Төркия латин әлифбасына күчкән булу сәбәпле, анда Коръән тәрҗемәсенең гарәпчә текстын җыю мөмкинлеге булмый. Бу эшне башкарыр өчен Муса Бигиев 1948-нче елның ноябрь аенда Истанбулдан Каһирәгә китәргә мәҗбүр була. Биредә аны дуслары һәм шәкертләре каршы алып, кайгыртып торалар: Йосыф Уралгирәй, Галимҗан Идриси һәм башкалар. Алар арасында Габдрәшит Ибраһимовның кызы Фәүзия ханым Ибраһим да була. Ул чакта Фәүзия ханымның ире Нәфиз Догрул Төркия дипломаты сыйфатында Каһирәдә консуллыкта хезмәт иткән була.

Каһирәдә Муса әфәнденең Коръән тәрҗемәсе белән никадәр шөгыльләнүе, бу эшнең нинди хәлдә булуы әлегә кадәр ачыкланмаган һәм хәтта өйрәнелмәгән. 1949-нчы елның көзе җиткәч, олы яшькә җиткән галимнең хәле начарая башлый һәм шул елның үктәбер аеның 28ендә аның газиз җаны Аллаһ хозурына юл тота.

Мисырда чыгып килүче иң мәртәбәле «әл-Әһрам» гәзите 1949-нчы елның 29 үктәбер санында Муса Җаруллаһның җеназасы Каһирәнең Сәйидә Нәфисә исемле мәчетендә укылуы һәм олуг галимнең Мисыр падишаһлары дәфен кылына торган Хәдивләр зираты дип аталган борынгы мазарда күмелүе турында игълан бастыра.

Төрек галиме, берничә ел дәвамында Төркия Җөмһүриятенең Дини эшләр министрлыгын җитәкләгән Мехмет бәй Гөрмәзнең фикеренчә, Муса әфәнде Бигиев Җәмалетдин Әфгани, Мөхәммәт Габдүһ кебек галимнәрдән күпкә өстен тора. *«Аның матди мөмкинлекләре чикле булганга күрә генә бүгенге тарих фәне Муса Бигиев турында түгел, ә Җәмалетдин Әфгани, Мөхәммәт Габдүһ турында сүз йөртә, – ди ул, һәм дәвам итә. – Муса әфәнденең мирасы өйрәнелсә иде, соңгы елларда дөньяның һәр почмагында үзенең барлык ялгышу-саташулары белән дан тоткан ваһһабилык тәгълиматы кебек чирнең дәвасы тиз табылыр иде. Башкача әйткәндә, Муса әфәнденең фикерләре, ачышлары белән таныш булган кеше беркайчан да үзен вак һәм сай тәгълиматлар кысалары белән чикләтергә юл куймаячак»*.

Тәфыйк әфәнде Ибраһим исә болай ди: *«Татар халкыннан үз вакытында бөтендөнья ислами фикерен яңартучыларның иң бөеге булган дөнья күләмле фикер иясе чыккан. Татарлар, әлбәттә, моның илә горурлана алалар. Мин моңарчы да әйтә килдем, алга таба да әйтеп торачакмын: Әгәр Русия мөселманнары (беренче чиратта сүз татарлар турында бара), бөтен ислам дөньясына чын ислам диненең нинди булырга тиешлеген, ягъни аның иң алдынгы, камил акыл ияләре өчен иң ятышлы, башкаларга карата иң түземле һәм аралашу өчен иң ачык дин булуын күрсәтмәсәләр, бу эшне кайдан булса да башка җирдән, башка милләттән көтмәгез! Мөселман булмаган халыкларга һәм, аеруча, мөселманнарның үзләренә егерме беренче гасырда исламиятнең нинди булырга тиешлеген күрсәтү вазифасын бары тик сез генә башкарып чыга аласыз! Башка беркемнән дә көтмәгез! Моның өчен сездә бөтен шартлар тудырылган. Олуг дин галимнәренең мирасына иясез. Алар арасында Муса Бигиев – иң югарысыдыр. Менә шушы мирасны алып, башкаларга ирештерергә кирәк»*.

Муса Җаруллаһ... Аның сөйләгән теле Хакыйкать иясенең безнең яныбызда торуын сизәргә мөмкинлек бирә. Аның калебеннән балкып чыккан нурда шәрыкның вә гарепнең Раббысы иңдергән сүзләрнең өряңа гаҗәп мәгънәләре ачыла. Сайлап алырга мөмкин булган күптөрле сукмаклар арасыннан ул дөреслеккә таба илтәчәк бердәнбер дөрес юлны сайлап ала алган…

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

## Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

### ХРОНИКА

Исходя из особенностей этого года, редакция журнала решила провести серию семинаров, посвященных динамике татарской нации в XX–первых десятилетиях XXI вв. В работе семинаров принимали участие общественные деятели и ученые. В дальнейшем наиболее важные итоги этих обсуждений предполагается опубликовать на страницах журнала «Туган җир. Родной край».

Тематика обсуждений была следующей:

11.06.2020. Тема: Ключевые категории татарской культуры.

23.06.2020. Тема: От старого концепта татарского «миллета» к татарской советской «автономной» нации.

30.06.2020. Тема: Татарская советская нация: свет и тень социалистического бытия татар в СССР (1930–сер. 1980-х гг.).

15.07.2020. Тема: Татарские мечты и историческая реальность первого этапа постсоветской трансформации татар (конец 1980-х–1990 гг.).



## ЯРКАЯ ЗВЕЗДА ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ

«Она – татарская Ахматова» – именно так оценил творчество татарской поэтессы Сажиды Сулеймановой известный поэт Хасан Туфан. Её трижды выдвигали на соискание Государственной премии им. Габдуллы Тукая, но республиканские чиновники её кандидатуру так и не утвердили. Её стихи, овеянные неиссякаемой любовью к жизни, одновременно и окрыляют молодые сердца, и в то же время заставляют задуматься. Имя Сажиды ханум всегда будет сиять яркой звездой в небе татарской поэзии.

В честь дня рождения поэтессы в стенах гимназии № 5 Казани (директор Альфред Вагизович Рагимшин) 11 октября 2019 г. был проведен потрясающий музыкально-поэтический вечер. Идея данного вечера принадлежит учительнице татарского языка и литературы этой гимназии Галие Михеевне Гайнетдиновой. Она же составила программу, разработала сценарий и провела это чудесное мероприятие. Член Союза писателей Республики Татарстан, лауреат литературной премии им. Ангама Атнабаева поэтесса Галия Гайнетдинова и знаменитая на весь мир Сажида Сулейманова – земляки. Галия – уроженка с. Сараштыбаш Татышлинского района Башкортостана, а Сажида родилась в с. Янаул, который находился всего в 30 км от с. Сарашты. Затем она с 4-х лет следом за отцом, которого партия сначала направила на руководящую работу в колхозы, а позже – в райсовет Татышлинского района, последовательно проживала в сёлах Урады, Сараштыбаш, Аксаитово и Верхние Татышлы.

Актовый зал гимназии был битком набит учениками старших классов. Сюда были приглашены именитые и важные гости, которые выступили с вдохновенными речами по поводу творчества поэтессы Сажиды Сулеймановой. А также каждый выступающий подчеркнул значимость знания детьми татарского языка: «Вы же богаче тех детей, которые знают только один язык – русский».

А вот и имена приглашённых гостей: заместитель председателя Союза писателей Республики Татарстан Раил Гатауллин; поэт Рифат Салах; журналист газеты «Мәдәни җомга» Хамза Бадретдинов; певец, народный артист Татарстана Искандер Биктагиров; баянист, заслуженный артист Татарстана Ахмат Карим; методист Казанского ГорОНО Раиф Зиннатуллин; методист Авиастроительного и Новосавинского РОНО Илгиза Ильясова, член Союза журналистов РТ и РФ Томас Нигаматзянов.

Но, пожалуй, гвоздём программы, изюминкой вечера стало активное участие в нём сына прославленных поэтов Адиба Маликова и Сажиды Сулеймановой, журналиста Анвара Маликова – обаятельного, очень скромного, интеллигентного человека. Сегодня Анвар Маликов работает

главным редактором Информагентства «Девон», освещающего новости нефтяной и смежных с ней отраслей Волго-Уральского региона. Он занимается также переизданием трудов своих именитых родителей, пишет о них биографические книги. Так вот, в этот славный вечер Анвар Адибович подарил гимназии огромную книгу о своей матери «Саҗидә Сөләйманова. Шигъриятнең күкчәчәге», написанную им в соавторстве с супругой Асией Маликовой. Кроме того, гимназия в дар от него получила и сборники стихов Адиба Маликова и Сажиды Сулеймановой на татарском и русском языках.

Но и сам Анвар Маликов не остался без подарка – педагог Галия Гайнетдинова торжественно вручила ему памятный знак, называемого сегодня в народе «тугрой», с именем Сажиды Сулеймановой – каллиграфическую картину известного художника-каллиграфиста Нажиба Наккаша.

Конечно, что это за мероприятие без концерта. Школьники проникновенно декламировали стихи Сажиды Сулеймановой. Звучали песни поэтессы в исполнении певца Искандера Биктагирова и детского школьного хора. Сама ведущая, поэтесса Галия Гайнетдинова прочитала прекрасные стихи собственного сочинения, посвящённые жизни и творчеству Сажиды Сулеймановой. А Томас Нигаматзянов прочитал собственный перевод этого стихотворения и вдобавок, артистично вышагивая по сцене, продекламировал стих Ангама Атнабаева «С. Сулеймановой». Всех присутствующих в шикарном зале удивил ученик родом из Таджикистана Мухаммедали Додобаев, который без всякого акцента прочитал наизусть стихотворение Сажиды Сулеймановой. Анвар Адибович не удержался – после окончания концерта он взял у 9-ти классника интервью.

Двухчасовой вечер татарской поэзии прошёл на одном дыхании. Все выступающие – дети и взрослые – свободно и красиво говорили на татарском языке, потому что они ещё наследуют то время, когда татарский язык в школьном образовании не ущемлялся и он всеми детьми, независимо от их национальности, изучался в обязательном порядке.

*Томас Нигаматзянов*

## ФЕСТИВАЛЬ ПОЭЗИИ НА РОДИНЕ АНГАМА АТНАБАЕВА

21 февраля 2020 г. В СДК села Старый Курдым Татышлинского района Башкортостана прошёл Открытый районный фестиваль-конкурс поэзии «Күрдем чишмәләре – 2020», посвящённый дню рождения народного поэта Республики Башкортостан Ангама Атнабаева, 125-летию со дня рождения башкирского и татарского поэта Шайхзада Бабича, 75-годовщине Победы в ВОВ 1941–1945 гг. и 85-летию образования Татышлинского района.

Глава администрации Татышлинского района Республики Башкортостан, кавалер ордена Дружбы народов Гараев Рушан Кадимович снова отдал дань светлой памяти видному татарскому и башкирскому поэту Ангаму Атнабаеву, поручив своей команде в очередной раз провести на родине Поэта поэтический фестиваль.

На этот светлый праздник поэзии пригласили и нас двоих казанцев – меня и поэтессу Галию Гайнутдинову. Галию Михеевну здесь все знают – но не потому, что она член Союза писателей Республики Татарстан и лауреат литературной премии им. Ангама Атнабаева, а по очень простой причине: Галия уроженка соседнего села Сараштыбаш и окончила Курдымскую среднюю школу. Её как профессионала в поэзии включили в состав жюри.

Это же надо случиться такому чуду! – говоря популярной фразой киноактёра Владимира Машкова из кинофильма «Ликвидация» – «Картина маслом»: яркое зимнее солнце, на улице обилие белого снега и высоких сугробов. Невольно подумаешь, в этом далёком от Казани татарском селе никто не нарушает свои укоренившиеся традиции: ни Всевышний, ежегодно даря селянам настоящую зиму, ни администрация сельсовета и СПК, предоставляя людям радость поэтической сказки.

Конкурсанты от мала до велика – самой младшей участнице было 4 года, а самой старшей – 97 лет – беспрестанно, но артистично и в нарядных татарских и башкирских костюмах выступали в течение всего дня. Они соревновались друг с другом в мастерстве и надеялись на первые места и даже на Гран-При. География конкурса также была представлена широко – чтецы и поэты прибыли сюда не только из селений Татышлинского района, но и из соседних Аскинского и Янаульского, даже из Свердловской обл.

Чаще всего со сцены сельского Дома культуры звучала татарская речь, были выступления на башкирском и русском языках. Не возбранялось читать стихи ни на каком языке. К примеру, в прошлые годы стихи Ангама Атнабаева звучали и по удмурдски. А нынче наооборот – марий-

ка из единственной в районе марийской деревни Башкибаш прекрасно на чистейшем татарском языке продекламировала стих любимого всеми Атнабая.

По условию конкурса на суд жюри взрослые участники (старше 16 лет – II возрастная группа) должны были представить мастерство чтения либо стиха собственного сочинения, либо стихов Ангама Атнабаева и Шайхзада Бабича. Дети могли выйти на сцену клуба и с одним стихом.

В этот приезд я не был прикреплён к жюри, поэтому вёл себя совершенно свободно – то фотографировал выступающих на сцене и присутствующих в зале, пришедших поболеть за своих и просто послушать настоящие стихи, то выходил на улицу подышать свежим морозным воздухом. Из репродуктора минарета мечети, имамом которой является родной брат Ангама Атнабаева Магдан хазрат, приятно звучал пятничный намаз.

Между прочим, аяты сур Корана – это тоже стихи, то есть эта священная книга мусульман написана в поэтической форме. Уникальным переводом смыслов Корана на русский язык считается перевод в стихах Иман Валерии Пороховой, принявшей ислам русской жены араба Мухаммада, сына сирийского шейха. Интересно получается, Магдана и Ангама Атнабаевых роднит не только общая кровь, но и поэзия – божественные молитвы священного писания и прекрасные стихи, написанные поэтом.

На поэтическом конкурсе из стихов Ангама Атнабаева чаще всего звучали такие, как «Ул болытлар» («Эти облака»), «Туган җирем» («Родной край»), «Чияле тау» («Вишневая гора»), «Кара икмәк» («Чёрный хлеб»), «Унбер малай үстек» («Мы росли одиннадцать мальчишек»), а из произведений Шайхзада Бабича – «Курай».

Когда конкурс чтецов завершился, жюри в полном составе из концертного зала СДК перебралось в уютную комнату сельской библиотеки, которой заведует Элида Карамова, женщина доброй и светлой души. Элида Фанисовна – главный библиотекарь модельной библиотеки села Старый Курдым. Она блестящий организатор культурного досуга односельчан. Вот и для членов жюри Элида Фанисовна создала приятную рабочую обстановку – тут тебе и «круглый стол», и бумаги, и авторучки, и чистые бланки дипломов, и компьютер с принтером, и даже чай с её собственной выпечкой.

Несмотря на продолжительное обсуждение результатов конкурса, всё-таки члены компетентного жюри успели до 7 часов вечера, до начала гала-концерта, из 62 участников выбрать единственного чтеца, завоевавшего Гран-При, и несколько призёров, занявших первые, вторые и третьи места, а также заполнить многочисленные дипломы победителей и лучших участников, отобранных для награждения специальными призами.

Зрительный зал СДК был набит битком. Гала-концерт получился блистательным благодаря стараниям начальника отдела культуры муниципального района Татышлиснкий район Шайнуровой Альфии Ураловны. Она привлекла сюда художественные коллективы районного Дворца культуры и органично, как нанизывают жемчужины на нить ожерелья, включила в программу концерта выступления чтецов, отличившихся своей артистичностью и выразительностью чтения стихов. После окончания концерта началась церемония награждения победителей конкурса дипломами. Отличившимся участникам вручали специальные призы. Так, например, 97-летняя Накия Цой за выразительное чтение стихотворения Ангама Атнабаева «Кара икмэк» («Чёрный хлеб») заслужила специальный приз Айдара Галимова. Примечательно, что 4-летняя Аиша Шамсутдинова в группе до 16 лет (в I возрастной группе) заняла 2 место. Специальные призы учредил и председатель СПК им. К. Маркса Ульфат Фоатович Габсалямов для детей, родители которых работают в колхозе.

Гран-При получил гость из Качканара Свердловской обл. Данис Бадретдинов, в глазах членов жюри затмивший всех выступивших наилучшей выразительностью чтения произведений Ангама Атнабаева и Шайхзада Бабича, а также чтением стихотворения собственного сочинения. Немаловажную роль, как мне сказали, на положительное решение жюри сыграл и его выход на сцену в татарском национальном костюме.

Из протокола заседания жюри Открытого районного фестиваля-конкурса поэзии «Күрдем чишмәләре – 2020» от 21.02.2020:

Жюри в составе:

1. Зиянгиров Фарит Абзалович – режиссер народного театра «Илхам» МБУК МКДЦ, лауреат премии им. А. Атнабаева, председатель жюри.

2. Абдульманова Зиля Закиевна – заслуженная артистка РБ, чтец-мастер художественного слова в Нефтекамской государственной филармонии.

3. Ахунова Халида Мухаматсалямовна – главный методист Управления культуры Татышлинского района.

4. Шарафиева Зинира Давлетяровна – заведующая читальным залом МБС.

5. Гайнутдинова Галия Михеевна – поэтесса, педагог, член Союза писателей РТ, лауреат премии им. А. Атнабаева.

Обладателями ежегодной районной премии имени Ангама Атнабаева стали народный артист Республики Татарстан и Республики Башкортостан Айдар Галимов и член Союза журналистов Республики Татарстан и Российской Федерации Томас Нигаматзянов.

Рассмотрев итоги Открытого районного фестиваля-конкурса поэзии «Күрдем чишмәләре–2020», места распределились следующим образом:

Признать обладателем Гран-При – Бадретдинова Даниса – г. Качканар Свердловской области;

Признать победителями и присудить звание лауреатов конкурса в I возрастной группе (собственного сочинения):

I степени (1 место) – Шамсиеву Юлию – с. В. Кудашево;
II степени (2 место) – Габдулхакова Арлиана – с. В.Татышлы;
Шаехову Гульшат – с. В.Татышлы;
III степени (3 место) – Хизамутдинова Рамиса – д. Ст. Сикияз;
Исламову Анисью – с. Старокальмиярово;
Гаязову Альфию – с. Шулганово.

Признать победителями и присудить звание лауреатов конкурса во II возрастной группе (собственного сочинения):

I степени (1 место) – Файзрахманову Ларису – с. Ялгыз-Нарат.
II степени (2 место) – Фатхутдинову Сылу – с. Шулганово;
Арсланову Альбину – с. Гарибашево.
III степени (3 место) – Ахметову Миляушу – д. Юсупово;
Зуфарову Муршиду – с. Ст. Курдым;
Исламову Елену – д. Уразгильды.

Признать победителями и присудить звание лауреатов конкурса чтецов на лучшее исполнение стихотворений А. Атнабаева и Ш. Бабича в I возрастной группе:

I степени (1 место) – Ибатуллину Галию – с. В. Татышлы.
II степени (2 места) – Шайсултанову Аишу – с. Ст. Курдым;
Дахиева Эмиля – с. Ст. Курдым.
III степени (3 место) – Асрарову Регину – с. В. Татышлы;
Аскарова Артура – с. В. Татышлы;
Джамолову Гульнозу – с. Аксаитово.

Признать победителями и присудить звание лауреатов конкурса чтецов на лучшее исполнение стихотворений А. Атнабаева и Ш. Бабича во II возрастной группе:

I степени (1 место) – Кашапова Ильсура – Янаульский район.
II степени (2 место) – Хисматуллину Розалину – с. Шулганово;
Хабибрахманову Василю – Аскинский район.
III степени (3 место) – Шабутдинову Гульшат – с. Беляшево;
Хузину Филарису – с. Аксаитово;
Ахметову Рауману – с. Гарибашево.

В финале фестиваля-конкурса поэзии заместитель главы администрации по социальным вопросам и кадровой политике Татышлинского района Республики Башкортостан Рахимов Ралиф Сагитович торжественно вручил мне диплом лауреата и премию им. Ангама Атнабаева, а также на

лацкан моего пиджака прикрепил нагрудный знак лауреата. Популярному эстрадному певцу Айдару Галимову премия им. Ангама Атнабаева за 2019 г. была вручена на сцене Татышлинского Дворца культуры 30 января 2020 г. в торжественный вечер празднования 85-летия со дня образования Татышлинского района.




*Томас Нигаматзанов вручает приз победителю*

Надо отдать должное и главе сельского поселения Курдымский сельсовет Нисаповой Ларисе Хамисовне за достойную организацию обеда и праздничного ужина членам жюри, организаторам и гостям фестиваля поэзии.

*Томас Нигаматзянов*

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

### ТАЙЧИ: ОТ ПЕРВЫХ ПОСЕЛЕНЦЕВ ДО СЕГОДНЯЩНИХ ДНЕЙ…

***(об историко-краеведческой книге краеведа-исследователя и этнографа Н. Ф. Галеевой «Тайчи: история таежной деревни» – Омск. Полиграфист, 2020. Тираж 500 экз. 263 с.***

В Омске увидела свет новая историко-краеведческая книга, рассказывающая об одной из татарских деревень Тевризского района Омской области, написанная ее уроженкой Наилей Галеевой на основе воспоминаний старожилов, дневниковых записей, архивных документов и научной литературы. В ней описывается история сельского поселения с момента его основания и до периодов активного развития деревни в XIX–XXI вв., рассказывается о традициях, быте, религии и этническом составе жителей, а также о природе, фольклоре, биографии и родословных тайчинцев.



Рецензентами изданного труда стали известные татарстанские ученые и краеведы, авторы многих краеведческих трудов – председатель РОО «Общество татарских краеведов» при Всемирном конгрессе татар, историк-археолог и востоковед, кандидат исторических наук А. А. Бурханов, доктор исторических наук, почетный работник Общего образования РФ, профессор кафедры теологии Российского исламского института Ф. Г. Ислаев и краевед-исследователь, почетный работник Общего образования РФ, ветеран педагогического труда Р. З. Салиев.

Древняя, средневековая, новая и новейшая история сел и деревень Тебризского района и сопредельных территорий Омско-Тарского Прииртышья являются неотъемлемой частью прошлого татарского и других коренных народов Западной Сибири и всей Евразии. Тюрко-татарские памятники в Прииртышье представлены в разных районах Омской области – Саргацком, Большереченском, Тарском, Тевризском, Усть-Ишимском и др. На селищах, расположенных по берегам Иртыша и его притоков, обнаружены керамика и другие предметы тюрко-татарской культуры, рядом с ними открыты татарские кладбища. Однако большинство объектов пока изучены слабо. Неизученность татарской истории в историко-археологическом отношении традиционно объяснялась наличием письменных источников, а также тем, что локальная (региональная) история регионов, в том числе Западной Сибири, не считалась в историографии «исторической» темой. Лишь отдельные эпизодические исследования ученых-археологов, этнографов и историков, а также местных краеведов постепенно заполняют «белые пятна» исторической карты Омско-Тарского Прииртышья. История населенных пунктов региона пока изучалась силами небольшой группы ученых и местных краеведов, но эти работы носят ещё ограниченный характер, некоторые из них слабы методически и с точки зрения сбора, анализа исторического материала. Благодаря труду и поискам местных краеведов регионов Западной Сибири, постепенно собираются новые данные по истории региона, издаются новые историко-краеведческие книги, открываются все новые краеведческие музеи и школьные уголки местной истории, что становится фундаментом для дальнейших исследований.

В связи с этим важным вкладом в изучение истории Тевризского района и Омско-Тарского Прииртышья является историко-краеведческий труд Н. Ф. Галеевой по истории татарской таежной д. Тайчи, находяшейся в Тевризском районе Омской области. Книга охватываетя динамику развития этого населенного пункта с момента заселения до сегодняшних дней.

Автор посвятила книгу юбилею деревни – 300-летию её основания. Работа состоит из предисловия (написано автором), вступительного слова А. А. Бурханова и 5 глав: «История деревни Тайчи»; «Деревня XIX – пер-

вой половине XX в.»; «Вторая половина XX в. – наши дни»; «Наши земляки»; «Фольклор тайчинцев». В качестве приложений помещены цветные и черно-белые фотоиллюстрации, даны топонимы д. Тайчи. Автор при написании этой уникальной книги использовала материалы 22 информаторов, архивные данные (8 наименований), научную и краеведческую литературу (39 наименований) и интернет-ресурсы (9 наименований).

Наряду с использованием имеющегося научного материала и архивных данных, автор во всех разделах широко использует в качестве важного источника воспоминания земляков и очевидцев исторических событий, связанных с историей села и региона.

При изучении истории появления деревни в таежном лесу, автор особо характеризует окружающую природу и историческую обстановку до возникновения и в период появления первых поселенцев в этих краях. Четко показана поэтапность появления сельского поселения на месте современного Тайчи, даются различные версии названия деревни, а также этнический и численный составы населения села в различные периоды. При этом в книге достаточно четко и глубоко характеризуются все формы хозяйственной деятельности жителей. Кроме этого особое место уделяется изучению религиозных воззрений местного населения и распространению ислама в этих местах.

Большое внимание в книге уделяется событиям, связанным с Гражданской войной и установлением Советской власти, а также годам репрессий и раскулачивания. Значительное место отведено истории села в годы Великой Отечественной войны и участию земляков на фронтах и работе их в тылу.

Автор детально характеризует объекты социально-культурного назначения, действовашие в течение XX в. (больница, почта, библиотека и др.).

Важное место в книге уделяется роли природы в жизни земляков. В книге дается также богатый фольклорный материал, связанный жизнью сельчан. Особый интерес представляют материалы, связанные с основными фамилиями и родами д. Тайчи.

Автор книги – краевед-исследователь и этнограф Галеева Наиля Фазыловна, родилась и выросла в д. Тайчи. В семье Галеевых всегда особое внимание уделялось к образованию детей, знакомству их с культурой и традициями татарского народа. Любовь к истории родного края зародилась у Наили с детских пор, благодаря рассказам ее бабушки и родственников о жизни в Татарстане и судьбе татарского народа, переживших трагедии и голод, о переезде многих татарских семей из Волго-Уралья и других регионов страны в Сибирь. Автору удалось передать тоску предков по Родине, а также свою безграничную любовь и уважение к односельчанам, сумевшим сохранить все национальные традиции и обычаи. Именно они и поддержали Наилю в

дальнейшей жизни – в годы учебы и работы. Учеба на историческом факультете Омского государственного педагогического университета помогла ей сформировать научный интерес к этнографии, в частности, к культуре и традициям татар Сибирского региона. Она поняла, что татары региона имеют богатые историко-культурные корни и предков, которые вышли из разных регионов огромной тюрко-татарской Евразии и при этом сформировались как особая и единая татарская общность Сибири, являющаяся важной составляющей частью большой тюрко-татарской нации.

О процессе работы над книгой по истории д. Тайчи и скором завершении процесса по подготовки ее к печати, автор объявила коллегам в своем выступлении с докладом в ходе работы Всероссийского форума татарских краеведов, который состоялся 12–13 сентября 2019 г. в Томске. Н. Ф. Галеева сделала все возможное, чтобы книга стала достоянием ученых, краеведов, земляков и всех любителей татарской истории. Важно отметить, что рассматриваемый труд по истории сибирской д. Тайчи станет определенным вкладом в дело развития всего татарского краеведения и значительным моментом в ходе подготовки следующего Всероссийского форума татарских краеведов, который планируется провести в Омске и Таре осенью 2020 г. Книга будет хорошим подарком для его участников.

Написать объемный труд по конкретной тематике, тем более по истории одного села, ни каждому по силам. Для этого прежде всего нужны исследовательский и жизненный опыт, а также долгие годы кропотливого труда по сбору и анализу многообразного материала. Несмотря на свой возраст, автор работы Н. Ф. Галеева взялась осуществить свою мечту и сумела подготовить к печати книгу по истории своего родного села.

Я с большим интересом прочитал электронный вариант рукописи и сейчас уже оригинал книги и считаю, что она получилась интересной и богатой благодаря скрупулёзно собранного разнообразного материала.

Мы не исключаем дискуссионность некоторых моментов, изложенных в данной книге. Однако её материалы несомненно станут базой для дальнейших фундаментальных исследований истории Тевризского района и сопредельных районов Омско–Тарского Прииртышья.

Надеемся, что данное издание вызовет интерес не только у специалистов, краеведов и жителей с. Тайчи, но и широкого круга читателей, интересующихся историей Прииртышья и в целом истории Сибири и татарского народа.

А сегодня, уважаемые читатели, в добрый путь, новая историко-краеведческая книга в просторы сибирской истории!

*Альберт Бурханов, кандидат исторических наук,*
*председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ*

# МАНСУР ГАНИЕВНЫҢ «АБДУЛ САЛМАН МОРЗАЛАРЫ» КИТАБЫ

2019-нчы ел тәмамланып килгәндә, Казанның «Яз» нәшериятендә, Мансур Корбангали улы Ганиевның Әлки районы, Абдул Салман авылының тулы тарихын эченә алган, авылдашларының хатирәләрен яңарткан, тарихи вакыйгаларны архив чыганакларына таянып яктырткан «Абдул Салман морзалары» дип аталган китабы дөнья күрде.

Милләте белән горурланган, аның якты киләчәге өчен хезмәт итүче, шуңа һәркемне чакыручы, үзенең һәм авылдашларының нинди нәселдән булуын, бүгенге һәм киләчәк буын әби-бабаларының кем булганлыкларын белеп үссен дигән омтылыш-теләк, 73 яшен тутырып 74кә үрмәләгәндә Мансур әфәндене бу зур хезмәтне язарга этәргән. XVII гасыр башыннан бүгенге көнгә кадәр чорны тасвирлап тарихи китап язу өчен аңа архивларда казынырга, күп белешмәләрне барлап укырга, фактик материаллар тупларга, бик күп өлкәннәр, замандашлар, галимнщр белән аралашырга, киңәш-табыш корырга, физик һәм финанс чыгымнарын (кыенлыкларын) уздырырга туры килгән. Китабын бастырып чыгару өчен аның авторы матди ярдәм сорап, беркемгә дә мөрәҗәгать итмәгән.

Бу китап – бик зур фәнни хезмәт, аны туып-үскән авылына, ата-бабаларына, кан кардәшләренә тарихи һәйкәл дип атарга тулы җирлек бар. Чын мәгънәсендә, әдәпле, күпкырлы белем иясе, җаны-тәне белән милләтебез өчен хезмәт итүче, иманлы кеше башкарганы аның һәр җөмләсеннән сизелеп тора. Автор барлык авылдашларын нәселдәшләребез, диеп атап яза. Шулай атап язар өчен фәнни ачышларга ирешә. Нәсел башында, якынча 1600-нчы елда туган Тимкәй бабалары тарихи шәхес икәнен ачыклый. Рәсәйнең тарихындагы шомлы «смутное время»дан соң көнбатыш чикләрен поляклардан саклау хезмәтен Белгород шәһәрендә 18 ел буе башкарган, патша тарафыннан күп өстенлекләр, ташламалар алган шәхес булган ул. Нәселдәшләре хәтерендә сакланмаган уртак фамилияләре – морза Чепкенеевлар икәнлеге ачыклана. Автор башта үз авыл халкы – нәселдәшләренең 13–15 буынан торган шәҗәрәсен эшләп, бүгенге буынга тапшыра. Шәҗәрә агачында (соңгы буыннарның барысын да исәпкә алмыйча) бер мең ярым кешенең исеме аталган. Үз авылының шәҗәрәсеннән тыш автор күрше 4 авыл халкының шәҗәрәләрен дә барлаган. Татарстанда беренчеләрдән булып, 2011-нче елдан башлап шәҗәрә бәйрәмнәре оештырып уздыруга ирешкән шәхес ул. Бәйрәмдә катнашучы һәр кешегә А-3 форматындагы кәгазьгә төшергән, 7 буыннан башлап 13 буынга кадәр булган шәҗәрәләрен тапшырган. Менә бу – чын шәҗәрә бәйрәме. Бернichә авылда гомер иткән 27 әбиләренең (кем кызы

икәнлеген), 53 бабаларының исемнәрен ачыклаган, аерым, үзе тапкан формага салган.

Мансур әфәнде әлеге тарихи китапны (әдәби әсәр генә түгел)–үзенең гомер буе хыялланган эшен, авылдашларына, әлкилеләргә бүләк итә. Тирә- яктагы авылларның өлешчә тарихын, күренелекле шәхесләре турында шактый мәгълүмат бирелә бу китапта.

Мансур әфәнде Әлки районы Абдул Салман (Морзалар Салманы) авылында туа. Базарлы Матак авылы урта мәктәбен тәмамлап, Казан финанс-икътисад институтына укырга керә. 1969-нчы елда бухгалтер-экономист белгечлеге алып, төзелеп килүче Түбән Кама шәһәренә килә. Һөнәре буенча эшләп планлаштыру бүлеге җитәкчесе дәрәҗәсенә ирешә. 1973-нче елда Совет Армиясе сафларына алынып Чита, Иркутск шәһәрләрендә хезмәт итә. Хәрби хезмәтен капитан званиесендә, дивизия финанс бүлеге җитәкчесе вазифасында тәмамлый. Армия хезмәтеннән соң Түбән Кама шәһәренә кайтып, кабат «Татэнергострой» берләшмәсендә барлыгы 21 ел хезмәт итә. Йортлар төзү берләшмәсенең (ДСК) җитәкчесе урынбасары эшен башкара. 1990-нчы елда Түбән Кама районы буенча салым инспекциясен оештырып, 16 ел буена, лаеклы ялга чыкканчы җитәкче булып эшли. Бүгенге көндә актив җәмәгать эшләре башкара. Түбән Кама мунипициаль районы җәмәгать советы әгъзасы, аксакаллар шурасы сәркатибе. 2018-нче елда туган төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыятен оештыручы булды һәм үзе аның актив әгъзасы. Нәсел шәҗәрәләрен төзү остасы буларак күргәзмәләр, очрашулар оештыра, укучы балаларга ел саен мәктәптән тыш күп санлы дәресләр бирә. Район гәҗитләрендә төбәк тарихына, тәрбия темасына багышланган мәкаләләре басылып тора.

Язмамда авторның 2015-нче елда язган шигыреннән өзек китерәсем килә:

Гомерләрне буш уздырмыйк,
Үткәннәрне белмичә,
Кем булганнар, ни кылганнар,
Белергә теләмичә.

И, кардәшләр, без өйрәник
Үткәннәрнең тормышын.
Кардәшләрен, кордашларын
Ничек яшәү кормышын.

Автор үзенең китабын халык гыйбәрәсен тормышка ашырып (үткәнен белмәгәннең–киләчәге юк) эзлекле рәвештә милләтебезнең телен, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, динен саклауда көрәшен та-

свирлый. Пётр патша башкарган явыз гамәлләренә халкыбызның, шул исәптән морза бабаларының каршы көрәшен атап үтә. Бүгенге көндә дә милләтебезне астыртын рәвештә юк итү сәясәтен куркусыз чагылдырып, уттан-судан исән калган милләтебез, телебез яшәячәгенә ышандырып һәм аның өчен көрәшкә чакырып яза китабын. Колониаль халәттә калган илебезнең күп кенә морзаларын куркытып, ташламалар биргән булып чукындыруга ирешкән патша властьлары, аларны үз ягына аудара алган.

Китапта автор гадел һәм туры сүзен каләм белән сырлый. Узган чорларда күренекле татар морзалары христиан динен кабул итү белән генә чикләнмәгәннәр, алар руслашып та киткәннәр, граф, князь дәрәҗәләренә ирешкәннәр, татар булудан туктаганнар. Шундый шәхесләрнең, нәселләрнең фамилияләре ошбу китапта бәян ителә.

Мансур әфәндегә тарихи китабы өчен рәхмәтләребезне белдереп, китабына хәерле юл телибез!

*Суфиян Минһаҗев,*
*Түбән Кама шәһәре Аксакаллар шурасы әгъзасы*

## Национальная кухня, пути сохранения здоровья

## РЕЦЕПТЫ ОТ ГУЛЬНАФИС ВАЛЕЕВОЙ

### *ПИРОГ С КАПУСТОЙ*

***Начинка.***

Капусту потушить на масленице с добавлением молока, соли и сахара.

***Тесто.***

Мука – 3 стакана,
Масло сливочное – 1 пачка,
Дрожжи – 50 гр (сырые)
Растит. Масло – 2 ст.л.
Молоко – ½ стакана
Соль по вкусу.

Дрожжи развести в теплом молоке.
Муку перетереть с маслом сливочным в крошку.
Добавить молоко с дрожжи, соль, растит. масло.
Хорошо вместить и поставить в холодильник на 30 мин.
После раскатать 2 сочня.
Один (низ пирога) – больше, другой (верх пирога) – поменьше.
Положить начинку. Закрыть пирог, наколоть вилкой верх пирога и выпекать 30 мин.

### *МЕД ИЗ ОДУВАНЧИКОВ*

400–450 шт. цветков одуванчика.
Залить водой. Настоять 8–10 часов (для удаления горечи).
Затем воду вылить. Залить снова водой 600–700 мл.
Добавить сахар и варить после закипания 30 мин. Остудить.
Процедить. Отжать через сито цветки.
Добавить нарезанный кусочками лимон и варить ещё 20 мин после закипания.
Употреблять с чаем 2–3 ч.л.
Очищает печень.

## ЭРТНИК – СЕБЕР ТАТАРЛАРЫНЫҢ БАЛЫК БӘЛЕШЕ

Эртник – бик үзенчәлекле камыр ризыгы. Ул бары тик җирле себер татарлары яшәгән төбәкләрдә, аеруча Төмән һәм Омск өлкәләре авыллларында, табан (карась) яки карп балыкларыннан пешерелә. Башка төрле елга балыкларыннан пешерүчеләр дә бар, әмма тәме инде икенче.

Себердә эртникне махсус ясалган урамдагы тыш мичендә пешерәләр. Өйгә алып керүгә өстен кисеп алалар, шулчак аш бүлмәсе хуш искә төренә.





***Камыр:***

Чүпрә (прессланган «Люкс-экстра», «Саф-момент»лар бармый) – 30 г;

Җылы су – 500 мл;

Шикәр комы – 1 чәй кашыгы;

Он – 1 кг;

Тоз – 1 аш кашыгы;

Көнбагыш мае – 1–2 аш кашыгы.

***Эчлек:***

Чистарган 2 уртача зурлыктагы табан балыгы (вак булса бу камырга 3 тә ярый);

Тоз тәменчә;

2 данә зур суган;

3–4 данә уртача бәрәңге.

Эртниккә балыкның симезен, майлысын сайларга кирәк. Пешкәндә балык мае камырга сеңеп, тәмле хуш исле була.

***Камыр әзерләү***: Бу ризык әче камырдан (Себердә «ацыткы», диләр) әзерләнә.

200 мл җылы суга 30 г чүпрә, 1 чәй кашыгы шикәр комы салып күпертергә куялар.

Күпереп чыгуга чиләккә чүпрәне, тагын 300 мл җылы су, 2 стакан он салып яхшылап болгаталар, каймак сыеклыгындагы масса барлыкка килә. Чиләкнең өстен каплап, җылы урынга куялар. Ул 5–6 сәгать әчергә тиеш.

Тиешле вакыт узгач, камыр ясарга тотыналар. Әчегән массага тоз, сыек май, он салып камыр басалар, артык каты булырга тиеш түгел. Камыр «җырлый» башласа – җитлеккән дигән сүз. Баса-баса камыр тавыш чыгара башлый, без аны җырлый башлады, дибез. Җитлеккән камырны каплап, тагын 1 сәгатькә җылы урынга куябыз. Ул кабат күтәрелергә тиеш.

***Эчлек әзерләү:*** Балыкны чистартып ике яклап тоз сылыйбыз. Бәрәңгене чистартып түгәрәкләп кисәбез һәм тозлыйбыз (эртникне ясар алдыннан суын салфетка белән киптереп алырга кирәк булачак). Суганнарны чистартып һәркайсын аерым түгәрәкләп (кольцами) турыйбыз.

***Эртникне ясау:*** Камырны тактада җәябез. Җәелгән камыр уртасына бәрәңге; аның өстенә 1 суган; аннан балык һәм тагын суган салына. Җәелгән камырны дүрт почмагыннан уртага җыеп (конверт кебек була) ябыштырабыз.

Эртникне ике кул белән алып, әкрен генә майланган противеньга куябыз. Табада пешергән кеше камырны башта ук шунда куя, ул күпкә җайлырак.

***Пешерү:*** Духовканы кабызып, әзер булганын көтәбез. Ул арада ясалган эртник камыры тагын күтәрелә. Духовка әзер булгач, куеп, 1 сәгатьтән артык, якынча 70–80 мин, пешерәбез.

Пешеп чыгуга эртникне мичтән алып махсус тактага куялар, өстен атланмай белән сөртеп, 5–10 минутка каплап тоталар.

Табынга чыгаргач, өстен түгәрәкләп кисеп алалар. Балыклары, бәрәңгесе тәлинкәгә салып бирелә. Пешкән камырын Себердә тыш дип йөртәләр. Тышларын сындырып ашыйлар.

*М.Х. Сәгыйдуллина*

## АЛМАЛЫ КӨЗЛӘРЕМ

Быел бөтен дөньяны алма басты. Бакча, өй, өстәл өсләре, урамнар алма белән тулды. Бирмәгән, ашатмаган, өлеш тимәгән кеше калмады кебек. Килеп тә алмыйлар, әле илтеп бирсәң дә, борыннарын җыералар. Нишләтергә дә белгән юк. Кайберәүләр урамнардагы чүп савытларына ташый башлады. Беркөнне алсу-алсу алмаларны күрдем дә исем китеп карап тордым, йөрәгем әллә нишләп китте. Йә, Аллаһ, кичер безне, көферлеккә төшермә.

Алар бит минем җиде төп. Берсеннән-берсе тәмле, эре, сусыл, татлы. Әле моңа кадәр җидесенең дә берьюлы мондый күп уңыш биргәне юк иде. Ә алар тып та тып берьюлы коелалар. Тавышлары өйгә ишетелә. Алдан йоклый алмый ятам. Йоклап китсәм, алма тавышына уянам. Нишләтергә белмәгәннән гаҗизләнәм, аптырыйм.

Җәй айларында мин күбрәк бакчачылар автобусында йөрим. Алар да шәһәргә алма ташый. Зур дөяләр кебек төянгәннәр. Берсе әйтә:

– Кичә килосын 20 сумнан саттым, – ди.

– Юлга акчаң җиттеме соң?

– Юктыр. Аның каравы, әрәм, исраф булмады...

Әйе шул, һәр исраф – хәрәм. Һәр хәрәм – тәмуг ачкычы. Бакчада картаеп, каралып беткән күп әбиләр исрафның да, хәрамның да нәрсә икәнен белми. Өченчесе, бик белдекле булып: «Как, кагыт ясагыз», – ди. Ә минем колакларым әйтерсең лә шуны гына көтеп торганнар, бу хәбәрне шунда ук күңелемә салып куям: кагыт ясарга... Эшкә тотынам. Әйтерсең лә гомер буе шул эш белән шөгыльләнгәнмен. Кайнатма, повидло, төрле-төрле алма бәлешләре пешереп тә туйган идем инде. Ә кагыт ясау – беренче мәртәбә. Ул яңа, кызык, рәхәт.

Иң беренче эш итеп, бер почмакта посып кына, бүген-иртәгә чыгарып ыргытырлар инде, дип куркып кына утыра торган, студент чагымда Ташкенттан алып кайткан алты литрлы казанымны алып кереп юып куйдым. Юк-юк та да үзендә елга ике-өч мәртәбә пылау пешерелә тагын. Бердән, яшьлекне искә төшерә, икенчедән, яндырмый, көйдерми. Бисмилла әйтеп, ике чиләк алманы җыйдым да, чирәмгә җәеп, шлангтан гына су сиптереп, гөжелдәтеп юдым. Өйгә алып кереп, чүпләп, тастымал белән сөрттем. Эчен, бәрелгән урыннарын кисеп алып, турап, казанга тутырдым. Бер стакан су салып, өстен ябып, газга куйдым. Өй эченә хуш ис таралды. Болгатып торып, йомшарганчы пешердем. Блендер аша үткәрдем. Тагын бер ярты сәгать кайнаттым. Төсе бер дә матур түгел, төссез, ак та түгел, күк тә түгел. И-и, кагыт шундый буламыни? Ничек матурайтырга, дип уйлыйм. Уйлый торгач, таптым тәки, подвалда минем төрле сиропларым

күп – чиянеке, карлыганныкы – кайнатма ясаганда бүленеп калган. 700 г чия суын алып менеп казанга салган идем, матурлыгын күрсәгез! Бу бит инде сыекланды, тагын 15–20 минут кайнаттым. Матур, куе, хуш исле массага әйләнде. Зур-зур дүрт табага җәеп, газ миченә тыктым. Мичне 90–100 градуска кадәр җылыттым да, ябып бетермәдем, кул ясуы ачык калдырдым. Монда һәр хәрәкәт, кылган эш әһәмиятле. Мин боларны үзем уйлап тапмадым, эшли-эшли өйрәндем, интернеттан да күп укыдым. Ләкин аннан укып кына кагыт ясап булмыйдыр. Бер кило алмага ярты кило шикәр салырга, дигәннәр, дөреслеккә бер дә туры килми, артык баллы була. Мин шикәр салмаска тырышам, тәме ачырак булганда, күп дигәндә, 200 г чамасы салам. Табага пергамент кәгазе җәеп, аз гына иссез май сөртсәң, көлеп тора, ябышмый.

Бу эш миңа шундый ошады, күңел таләбенә әйләнде. Мин моны иртә дә, кич тә ясый башладым. Ниләр генә кыландырмыйм. Күпме ясасам да, һөрберсе төрле-төрле килеп чыга. Тәме дә, төсе дә. Кич беләп эштән кайткач, турыйм, кайнатам. Кичке сәгать тугызларда мичкә тыгам. Төнге намазга торгач, сәгать 1–2ләрдә мичтән алам, шул ук кибет кәгазен кискәләп өсләренә җәям дә, ялт-йолт иттереп, яшен тизлеге белән астын өскә әйләндерәм дә мичкә куям, тагын йоклыйм.

